# ШУРА

№ 33
2021

عيد الأضحى

Корбан гаете мөбарәк булсын!

2000999959363

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . 5
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . 11

ВӘГАЗЬЛӘР . . . 15
Изгелеккә чакыруның фазыйләте . . . 16
Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре . . . 20
Аллаһыга якынайта торган гамәл . . . 28
Корбан гаете вәгазе . . . 45
Калеб катылыгы . . . 52
«Бу бит сөннәт кенә...» . . . 59
Мөхәррам аен каршылап... . . . 66
Гашурә көне . . . 71
Күрше хакы . . . 74
Гыйлем алуда дәвамчылык . . . 79
Сафәр – уңыш ае . . . 84
Садакалы һәр көн... . . . 88
Ислам – тынычлык дине . . . 92
Телеңнән дә, кулыңнан да зарар килмәгән зат... . . . 96
«Олыларны хөрмәт итмәгән бездән түгел» . . . 100

ӘҢГӘМӘ . . . 106
«Татар теле хакында бервакытта да шигем булмады» . . . 107

ҮРНӘК ЗАТЛАР . . . 115
Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе . . . 116

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . 120

ТАРИХ . . . 136
Хабибрахман Шакир: меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл . . . 137

КОРБАН . . . 144
Корбан ни дигән сүз? . . . 145
Корбанның шартлары . . . 149

Зөлхиҗҗә аеның ункөнлегендә ураза тоту . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157

ХӘДИС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Җомга намазы китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Ике гает китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Истиска намазы китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

ТӘФСИР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Әюб галәйһиссәлам кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Көнчелек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Кыямәт куркынычлары һәм рисвайлыклары бәяны . . . . . . . . . . . 194

**«ШУРА» дини альманах, №33**

*июль – сентябрь 2021*
*зөлхиҗҗә1442-сафәр1443*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров
Ленар Хамматов

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 02.07.2021
Чыгу көне: 16.07.2021

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ!۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

______________________________۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞ ______________________________

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдийййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

________________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галлләәми, кәмәә каалаллаһу тәбәәракә вә тәгаалә филкәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлийййи вәш-шәрафил галийййи сәйййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галийййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәйййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәйййидинәл Хәсәни вә сәйййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү'миниинә вәл мү'минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын[1]. Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары, элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

____________________________________________

[1] 3 тапкыр әйтелә.

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ____
________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

> **«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

> **«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа ияручеләргә

сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

**«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуүҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән,**

**[көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*2нче июль вәгазе*

*Зөлкагъдә аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Изгелеккә чакыруның фазыйләте

Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак Расүле, галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә, сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Әлеге вәгазебез изгелеккә чакыруның фазыйләтенә багышлана. Изгелеккә чакыручының төп бурычы: үз тирәсендәге кешеләрне туры юлга, ягъни дин юлына чакыру, башка төрле әйткәндә, күркәм әхлакый тәрбия бирү, кешеләрдә яхшы сыйфатларны тәрбияләү.

Шушы сүздән аңлашыла ки, имамның җәмгыятьтәге урыны бик зур. Күз алдыгызга китерегез, әгәр дә балалар бакчасында балалар була торып, тәрбияче булмаса, мәктәп була торып, укытучылары булмаса, университет, институт була торып, остазлары булмаса, ул биналардан үзләренә һәм җәмгыятькә файдалы кешеләр чыгарга мөмкинме?! Әлбәттә, юк. Шуның кебек, үзенең төп ролен җиренә җиткереп үти торган имамнар булмаса, рухи тәрбиядән өлешсез калган нәселләр һәлак булачаклар, көтүчесез калган көтү кебек таркалачаклар. Тәндә барлыкка килгән авырулардан котылырга ярдәмен күрсәткән табиб кирәк булган кебек, кешедә булган

кайбер кимчелекләрдән котылырга яхшы сыйфатларны үзләштерергә юл күрсәткән имамнар да, һичшиксез, кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَلۡتَكُن مِّنكُمۡ أُمَّةٞ يَدۡعُونَ إِلَى ٱلۡخَيۡرِ وَيَأۡمُرُونَ بِٱلۡمَعۡرُوفِ وَيَنۡهَوۡنَ عَنِ ٱلۡمُنكَرِۚ وَأُوْلَٰٓئِكَ هُمُ ٱلۡمُفۡلِحُونَ

**“Арагызда [дини һәм дөньяви] хәергә [файдалы эшләргә] чакыра, яхшы гамәлләрне [кылуны] әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – уңышка ирешүчеләр”.**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

Изгелеккә чакыру, кемне дә булса тәрбияләү иң әһәмиятле саваплы һәм файдалы эшләрдән санала. Раббыбыз Аллаһы болай дип әйтә:

وَٱلۡعَصۡرِ ﴿١﴾ إِنَّ ٱلۡإِنسَٰنَ لَفِي خُسۡرٍ ﴿٢﴾ إِلَّا ٱلَّذِينَ ءَامَنُواْ وَعَمِلُواْ ٱلصَّٰلِحَٰتِ وَتَوَاصَوۡاْ بِٱلۡحَقِّ وَتَوَاصَوۡاْ بِٱلصَّبۡرِ ﴿٣﴾

**“[Кешеләрнең эшләре күп булган вакытка туры килгән] Икенде намазы вакыты белән ант итәмен. Һичшиксез, кешеләр зарарда [чөнки гомерләрен Ахирәттә һич кенә дә файда китермәячәк бозык теләкләрен канәгатьләндерүгә сарыф итәләр]. Бары иман китергән, [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] изге гамәлләр кылган һәм бер-берләрен хакка өндәгән һәм бер-берләрен сабырлыкка өндәгән кешеләр булмасалар гына”.**

«Әл-Гаср / Икенде вакыты», 103

Әлеге аятьтән аңлашылганча, изгелеккә чакыручы кешеләр гомерләрен әрәм итми, заяга үткәрми. Алар күркәм нәсыйхәтләре, хәерле сүзләре белән кешеләргә ике дөнья бәхетенә ирешүдә ярдәм итә.

Бу рәвешле эш итүче кешенең Аллаһы каршында дәрәҗәсе арта, ул хисапсыз савапларга ирешә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Һидаятькә чакыручы, үзенә иярүче кешеләр саны кадәр савапка ия булыр. Әмма моңа карамастан, иярүче кешеләрнең дә савабы бер дә кимемәс”, – дип әйткән. Димәк, никадәр күп кешене һидаять юлына чакыра алсак, аларның дингә керүенә сәбәпче булсак, шулкадәр үзебез өчен дә яхшырак булачак. ИншәАллаһ.

Кешеләргә хәерле сүз сөйләп, аларны вәгазьләүче, нәсыйхәтләүче кешенең сүзләре бик тә күркәм. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَمَنۡ أَحۡسَنُ قَوۡلٗا مِّمَّن دَعَآ إِلَى ٱللَّهِ وَعَمِلَ صَٰلِحٗا وَقَالَ إِنَّنِي مِنَ ٱلۡمُسۡلِمِينَ
﴿٣٣﴾ وَلَا تَسۡتَوِي ٱلۡحَسَنَةُ وَلَا ٱلسَّيِّئَةُۚ ٱدۡفَعۡ بِٱلَّتِي هِيَ أَحۡسَنُ فَإِذَا ٱلَّذِي
بَيۡنَكَ وَبَيۡنَهُۥ عَدَٰوَةٞ كَأَنَّهُۥ وَلِيٌّ حَمِيمٞ ﴿٣٤﴾ وَمَا يُلَقَّىٰهَآ إِلَّا ٱلَّذِينَ صَبَرُواْ
وَمَا يُلَقَّىٰهَآ إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٖ ﴿٣٥﴾

**“Сүз белән [азан укып һәм вәгазь-нәсыйхәт кылып, кешеләрне] Аллаһыга дәгъват итүче һәм [Аллаһы хозурында кабул ителә торган] изге гамәл кылган һәм: «Һичшиксез, мин мөселманнардан», – диючедән дә күркәмрәк [сүзле] кем бар? Яхшылык белән явызлык тиң түгел. Син [кайбер дошманнарыңнан күргән явыз мөгамәләне күрмәмешкә салышып, яхшылык белән җавап кайтару белән түгел, явызлык кылганга игелек кылу кебек] иң яхшы мөгамәлә белән кайтар, шулвакыт сиңа дошман булган кеше гүяки шәфкатьле бер дус [булыр]. Әмма бу [шәрәфле сыйфат] сабыр иткән кешеләргә генә бирелер. Бу зур бер насыйп иясе булганнарга гына бирелер”.**

«Фуссыйләт / Аңлатылды», 41:33-35

Шулай ук Раббыбыз болай дип әйткән:

ٱدۡعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِٱلۡحِكۡمَةِ وَٱلۡمَوۡعِظَةِ ٱلۡحَسَنَةِۖ وَجَٰدِلۡهُم بِٱلَّتِي هِيَ أَحۡسَنُۚ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعۡلَمُ بِمَن ضَلَّ عَن سَبِيلِهِۦ وَهُوَ أَعۡلَمُ بِٱلۡمُهۡتَدِينَ

**“[Расүлем! Хикмәт белән һәм күркәм үгет белән Раббыңның юлына дәгъват ит. Һәм алар белән иң яхшы булган юл белән бәхәсләш. Һичшиксез, синең Раббың кем Аның юлыннан язганын яхшырак белә, һәм Ул һидаятькә ирешүчеләрне дә яхшырак белә”.**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:125

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Әгәр дә берәрегез начарлык күрсә – кулы белән туктатсын, кулы белән дә туктата алмаса – теле белән, теле белән дә туктата алмаса – калебе белән ризалашмасын, әмма калеб белән генә ризалашмау иманның иң зәгыйфь дәрәҗәсе”.

Шунысын да белик җәмәгать: без бары сәбәп кылучылар гына. Күңелләргә салучы – Аллаһы. Әмма әгәр безнең тырышлыклар берәүнең тугры юлга килүенә сәбәпче булса, без хисапсыз әҗер-савапларга ия булачакбыз. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Әгәр Аллаһы Тәгаләнең берәүне һидаятькә күндерүендә синең катнашың булса, бу синең өчен дөнья һәм анда булган бар нәрсәләргә караганда да хәерлерәк”, – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә безне изгелеккә чакыручы кешеләрдән кылып, үзебезнең дә күңелләребез изгелектә булуны, ике дөнья бәхетенә ирешүне насыйп кылса иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*“Саләх” мәчете имам-хатыйбы*

*9 нчы июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре

Раббыбыз яраткан колларын, изге гамәлләрен арттыра алсын өчен, үзенчәлекле көннәр белән бүләкли. Алар бу көннәрдә Аллаһыга якынайта торган гамәлләрне кылып калырга омтыла. Бу вакытны дөрес кулланып, аны заяга үткәрмәгән кеше бәхеткә ирешә.

Зөлхиҗҗә аеның ун көне дә үзенчәлекле көннәр булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, изге гамәлләргә өндәп, әлеге көннәрнең бу дөньядагы иң хәерле көннәр булуын әйткән. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу ун көн белән ант иткән, димәк, бу көннәр бик олуг.

Югарыда искә алынганнар, Ахирәт тормышыбызны тиешле дәрәҗәдә каршы алып, изге гамәлләр туплау өчен, тырышлык күрсәтүгә чакыра. Бу көннәрнең фазыйләтен һәм бу вакытта ниләр эшләү хәерлерәк икәнен карап үтик. Аллаһы Тәгалә, Үзенең ризалыгына ирешә алуыбыз өчен, файдасын күрүне насыйп итсен.

Бу көннәрне ни рәвешле каршы алырга соң?

1. Ихластан тәүбә кылып:

Мөэмин кеше ихластан тәүбә кылырга һәм Аллаһы Тәгаләгә кайтуына ныклап ниятләр кылырга тиеш. Тәүбә кылу – мөэминнең бу дөньядагы һәм Ахирәт тормышындагы котылуы ул. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

**«Ий мөэминнәр! Барчагыз бергә Аллаһыга тәүбә итегез! Бәлки, сез [ике җиһан бәхетенә ия булып] уңышка ирешерсез».**

«Ән-Нур», 24:31

2. Бу көннәрне заяга үткәрмәү карарына килеп:

Мөселман кешесе бу көннәрне изге гамәлләр һәм сүзләр белән бизәргә омтыла. Берәр кеше шулай ниятләсә, аңа Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр һәм изге гамәлләр юлын җиңеләйтер. Аллаһы Тәгалә Үзенә карата ихласлы булганнарга карата вәгъдәсендә тора. Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

وَالَّذِينَ جَاهَدُوا فِينَا لَنَهْدِيَنَّهُمْ سُبُلَنَا ۚ

**«Безнең өчен тырышлык күрсәткән кешеләрне Без [җәннәткә илтәчәк] юлларыбызга һидаять итәчәкбез».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:69

3. Гөнаһлардан ерагаерга тырышып:

Гыйбадәт кылу – Раббыбызга якынайта, ә гөнаһлар Аннан ерагайта, Рәхмәтеннән мәхрүм итә. Әгәр гөнаһларыбызның гафу ителүен һәм җәһәннәмнән котылуыбызны телибез икән, зөлхиҗҗә аенда һәм калган вакытта да гөнаһлар кылудан ерак булыйк. Үзенең нәрсә теләгәнен белүче кеше, максатына ирешер өчен, бар көчен кулланачак.

Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре:

1. Аллаһы Тәгалә бу көннәр белән ант итте.

Әгәр Раббыбыз нәрсә белән дә булса ант итә икән, әлеге нәрсәләр олуг була, чөнки Раббыбыз бары тик бөек нәрсәләр белән генә ант итә. Раббыбыз болай дип әйтә:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

**«[Иртән агарып килгән] Таң белән ант итәмен! [Зөлхиҗҗәнең башындагы] Ун төн белән дә [ант итәмен]!»**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:1-2

Ун төн – зөлхиҗҗә аеның ун көне ул. Коръәни Кәримне тәфсир кылучы галимнәрнең күпчелеге шундый фикердә. Моның хаклыгын үзенең тәфсирендә Ибне Кәсир дә раслый.

2. Бу көннәр Аллаһы Тәгаләне зикер кылу өчен билгеләнгән.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ فِي أَيَّامٍ مَّعْلُومَاتٍ

**«...билгеле көннәрдә Аллаһының исемен искә алсыннар».**

«Әл-Хаҗ», 22:28

Галимнәрнең күпчелеге (алар арасында Ибне Гомәр һәм Ибне Габбас радыяллаһу ганһүмә дә бар) «билгеле көннәрнең» зөлхиҗҗә аеның ун көне булуы хакында әйткән.

3. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге көннәрнең бу дөньяда иң хәерле көннәр булуына шаһитлык китергән.

Җәбир радыяллаһу ганһедән тапшырыла, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу дөньядагы иң хәерле көннәр – ул зөлхиҗҗә аеның ун көне». Аннан: «Бу көннәрдә гыйбадәт кылучыларга тиңнәр бармы?» – дип сораганнар. Ул: «Аллаһы юлында мәрхүм булучыдан, ягъни шәһит булып китүчедән тыш, Аллаһы юлында булучылар арасында аларга тиңнәр юк», – дип әйткән.[1]

4. Бу көннәр арасында Гарәфә көне дә бар.

Гарәфә көне – олы хаҗның иң бөек көне ул. Ул – гөнаһлардан, ут газабыннан котылу көне. Зөлхиҗҗә аеның ун көне олуг булып саналсын өчен, Гарәфә көне генә дә җитәр иде.

5. Бу көннәрдә корбан чалына.

Галимнәр әйтүенчә, корбан чалу көне – Расүлебез сөннәтенең иң хәерле көне. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы алдында иң хәерле көн – ул корбан чалу көне «Йәүм Нәһри»

1 Әл-Бәззар, Ибне Хиббән.

һәм аннан соң килгән «Йәүм әл-Карри» көне»[1]. «Йәүм әл-Карри» – бу Кәгъбәтулланы тәваф кылганнан һәм корбан чалганнан соң, хаҗиларның Мина үзәнлегендә тукталган көннәре ул.

6. Бу көннәрдә гыйбадәтнең иң мөһим төрләре башкарыла.

Әл-Хафиз бине Хәҗәр «Әл-Фәтх» китабында болай дип язган: «Зөлхиҗҗә аеның аерылып торуының сәбәбе: иң әһәмиятле гыйбадәтләрнең: намаз, ураза, садака, хаҗның бергә җыелуында. Башка көннәрдә мондый хәлне күзәтеп булмый».

Зөлхиҗҗә ае ункөнлеге гамәлләренең фазыйләте: Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять кылына, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы өчен зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә кылган гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәл юк (һәм олуграк әҗер-савап юк)». Аннан: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдән дә сөеклерәкме?» – дип сораганнар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдән дә сөеклерәк. Үзенең гомерен һәм малын куркыныч астына куеп, моннан бернәрсәсез кайткан кешедән кала», – дип җавап кайтарган.[2]

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Мин Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идем һәм аннан гамәлләр турында сорадым. Ул: «Аллаһы Тәгалә өчен бу ун көндә кылган изге гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәлләр юк», – дип әйтте. Сәхабәләр: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык куюдан да сөеклерәкме», – дип сорадылар. Ул: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык куюдан да. Аллаһы юлына чыгып, гомерен биргән кешене санамаган очракта», – дип әйтте.[3]

Бу ике хәдис, калганнары кебек, әлеге айларда кылган гамәлләрнең фазыйләтен ассызыклый. Бу көннәрдә изге гамәлләр кылучының Аллаһы

---

[1] Имам Әбү Давыд һәм имам Ән-Нәсаи тапшыра.

[2] Имамнар Әл-Бохари, Әбү Давыд, Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

юлында тырышлык куеп кайтучыдан да хәерлерәк булуы аңлашыла.

Зөлхиҗҗә аеның ун көнендә мөстәхәб булган гамәлләр. Зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлеге Аллаһының рәхмәте, бүләге һәм изге гамәлләр кылу өчен мөмкинлек булып тора. Гыйбадәтләрне арттырыр өчен, булдыра алганча ныграк тырышлык күрсәтергә кирәк. Элеккеге тәкъва ияләре өч ункөнлекне бөекли торган булган: Рамазан аеның соңгы ун көнен, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнен һәм мөхәррам аеның беренче ун көнен.

Нәрсәгә игътибар бирергә кирәк?

1. Хаҗ һәм гомрә йолаларын башкаруга.

Болар бу көннәрдә башкарырга мөмкин булган иң хәерле гамәлләр. Раббыбыз тарафыннан Үзенең Йортына килү һәм гомрә кылу мөмкинлеге бирелгән кешенең бүләге җәннәт булыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гомрә кылу моңа кадәр кылынган гомрәдән соң булган гөнаһларны юк итә. Ә дөрес итеп кылынган хаҗ өчен җәннәткә керү насыйп булачак», – дип әйткән.[1]

Кабул кылынган хаҗ – риядан, гөнаһлардан, начар сүзләрдән, абруй казану теләгеннән ерак булып, олуг нигъмәтләр һәм әҗер-саваплар белән тулы булган хаҗ ул.

2. Ураза.

Ураза – бу көннәрдәге иң хәерле гамәлләрнең берсе ул. Раббыбыз аны Үзе белән бәйләп, болай дип әйткән: «Адәм баласының барлык гамәлләре дә, ураза тотудан кала, аның үзе өчен. Уразаны ул Минем өчен тота һәм аның әҗерен Мин бирәчәкмен»[2].

Пәйгамбәрбез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гарәфә көнен ураза тоту белән аерып алды һәм бу көндә ураза тоту әһәмиятен аңлатты. Ул болай дип әйткән: «Аллаһы ризалыгы өчен тотылган Гарәфә көне ураза-

[1]Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

сын Раббыбыз үткән һәм киләсе елның гөнаһларының гафу ителүе өчен кылачак»[1].

ИмамӘн-Нәвави рахимәһуллаһи үзенең китабында зөлхиҗҗә аеның ун көнендәге уразаны гаять кирәкле эш дип тәкъдим иткән һәм болай дип әйткән: «Бу көннәрдәге ураза мөстәхәб гамәл булып тора».

3. Намаз.

Намаз – иң олуг гамәл. Бу көннәрдә җәмәгать намазларын вакытында укырга тырышыгыз. Мөселман кешесе Аллаһыга якынайта торган әлеге һәм мөстәхәб булган намазларының санын арттырыр. Кодси хәдистә болай дип әйтелгән: «Минем колым, Мин аны ярата башлаганчыга кадәр, мөстәхәб булган гамәлләрне кылып, Миңа якынаюдан туктамый»[2].

4. Тәкбир, тәһлил, тәхмид сүзләрен күпләп әйтү.

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Аллаһы Тәгалә өчен зөлхиҗҗә аеның ун көнендә кылган изге гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәлләр юк. Бу көннәрдә күбрәк тәкбир, тәһлил һәм тәхмид әйтегез»[3].

Имам Әл-Бохари тапшыра: Ибне Гомәр һәм Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһүмә зөлхиҗҗә аеның ункөнлегендә «Аллаһү әкбәр» сүзләре белән базарга чыга торган булганнар һәм кешеләр дә алар артыннан кабатлаган. Бу көннәрнең барысында да Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Мина җирлегендә намаздан соң, йокы алдыннан, үзенең чатырында, җыелыш һәм йөреш вакытында тәкбир әйткән.

5. Садака.

Бу хәерле гамәлне дә әлеге көннәрдә ешрак башкарырга кирәк. Раббыбыз садака таратуга чакыра. Ул болай дип әйткән:

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَنفِقُوا مِمَّا رَزَقْنَاكُم مِّن قَبْلِ أَن يَأْتِيَ يَوْمٌ لَّا بَيْعٌ فِيهِ وَلَا خُلَّةٌ وَلَا شَفَاعَةٌ

**«Ий иман китерүчеләр! Ни сәүдә, ни шәфәгать [һәм арадашчылык мөмкинлеге] булмаган Көн килмәс борын, Без сезне ризыкландырган нәрсәләрдән [кайберләрен зәкят итеп хәерле юлларда] сарыф итегез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:254

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака байлыкны киметми», – дип әйткән.[1]

Гомумән, Коръән уку, аңа өйрәтү, истигъфар, әти-әнигә яхшылык кылу, туганлык җепләрен саклау, кунакларны сыйлау, кешеләрне дуслаштыру, изге гамәлләр кылуга чакыру һәм начар гамәлләр кылудан тыю, телне һәм җенес әгъзаларын начарлыктан тыю, күршеләргә яхшы мөнәсәбәттә булу, гаиләне тәэмин итү, мөселман кардәшләребезгә булышу, күп итеп салават әйтү, ятимнәрне кайгырту, барлык мөселманнар өчен дога кылу кебек изге гамәлләрне кылырга кирәк.

Аллаһы Тәгалә зөлхиҗҗә аенда кылган изге гамәлләребезне кабул итсен.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мөхәммәд хәзрәт Хөсәенов,*

*Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы имамы*

*16 нчы июль вәгазе*

*Зөлхиҗҗә аеның 6нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Аллаһыга якынайта торган гамәл

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Корбан гаете (гарәпчә «Гыйд әл-Әдъхә», عيد الأضحى) – хаҗ тәмамлануын билгеләгән ислам бәйрәме. Ураза бәйрәме тәмамлангач, җитмеш көн узуга, зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә билгеләп үтелә. Мөселманнарның иң зур бәйрәме булып санала.

Корбан чалу гамәленең тарихын беләбез, билгеле. Раббыбыз ике олуг пәйгамбәрне зур сынау белән сынаган: Ибраһим галәйһиссәламгә улы Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итәргә әмер кылына. Әлбәттә инде, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтан үз эшен үтәргә тырыша – пәйгамбәрләргә вәсвәсә кыла. Ул Исмәгыйль галәйһиссәламгә килеп: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач тизрәк», – дип әйтә. Сөекле әтиәнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала: «Мин Аллаһы әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип, мәлгуньне ташлар атып куып җибәрә.

Колларының итагатьләренә күрә, Раббыбыз Үзенең киң рәхмәте белән Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кулындагы пычагы үтми, һәм күктән, корбан итәргә дип, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бәрән төшерелә.

Шул көннәрдән бирле Корбан гаете изге бер йола итеп билгеләп үтелә. Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул

ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһының киң кодрәтен күрәбез.

Безнең буынга әлеге бәйрәм төрле гадәт, әдәби әсәрләр аша да килеп җиткән. Гадәттәгечә, ул Мәккәдә хаҗ кылу белән туры килә. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, гает намазын уку өчен, мәчеткә бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир:

اللهُ أَكْبَرُ ، اللهُ أَكْبَرُ ، لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ ، وَاللهُ أَكْبَرُ ، اللهُ أَكْبَرُ ، وَللهِ الْحَمْدُ

«Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, ләә иләәһә илләллаһ. Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләәһил хәмде», – сүзләре әйтелә.

Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннары туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Корбан чалу хөкемнәре һәм, кешегә бу гамәл мәҗбүри булсын өчен, үтәлергә тиешле шартлар: байлыгы һәм мөмкинлеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл булып санала.

Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде мөмкинлеге булмаса – гөнаһ юк. Шулай да бу изге эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый. Корбан чалганда, хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук, чалучының гөнаһлары кичерелә.

Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният зур әһәмияткә ия. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә:

لَن يَنَالَ ٱللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَآؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ ٱلتَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә»,** – дип әйткән.

«Әл-Хаҗ», 22:37

Ягъни Раббыбызга безнең ихласлыгыбыз, Аның әмерен рәхмәтенә өмет итеп башкаруыбыз кадерле. Шуңа да белеп торыйк: әгәр без кор-

бан чалганда ниятебезне үзгәртәбез икән, Раббыбыздан биреләчәк әҗер-савапларыбызны да югалтырга мөмкинбез. Аллаһым сакласын.

Корбан ите таратылырга тиешле кешеләр: корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Әгәр дә корбан чалган кешенең үз әнисе тол хатын булса – аңа да бирелергә тиеш.

Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр – итне кисәкләргә бүлеп тарата, икенчеләр – табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл булып санала. Ничек эшләсәң дә, дөрес була.

Корбан итеп чалынасы хайванның кимчелекләре булырга тиеш түгел.

Әмма хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндәгеләр:

– хайванның күз күреме начар булу, кылыйлык;

– бер аягы аксак булу, әгәр бу аксаклык хайванның йөрүенә комачау итмәсә;

– тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;

– колаклары тишелгән булу;

– берничә теше булмау;

– койрыгының яки колагының зур әһәмияткә ия булмаган өлеше булмау.

Ләкин иң яхшысы – хайванның бу төр кимчелекләре булмаганын сайлау.

Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндәгеләр:

– бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булуы;

– аксаклыгы берәр урынга барып җитәргә комачау итүе;

– бер яки ике колагы да тулысынча киселгән булуы;

– күпчелек тешләре булмавы;

– бер яки ике мөгезе төптән сынган булуы;

– койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булу;

– имчәкләре булмау;

– бик талчыккан хәлдә яки хәлсез хайван булуы;

– тумыштан колаксыз яки койрыксыз булуы;

– көтүдәге хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булуы;

– нәҗес (чиста булмаган ризык) белән туклануы.

Корбан итеп чалырга лаеклы хайваннар: сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя.

Ә калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенестән дә, ана җенестән дә булырга мөмкин. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар берьеллык булырга тиеш. Әгәр хайван ярты еллык булып, әмма көр, таза һәм берьеллык кебек булса, андый хайванны да корбан итәргә ярый. Ләкин мөгезле эре терлек – ике яшьлек, дөя биш яшьлек булырга тиеш. Мөгезле эре хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Шуны да белик: бергәләп, ягъни берничә кеше җыелып, зур малны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһы ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә инде араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул булмаячак.

Корбан чалу рәвеше: иң элек тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары, газап кылмыйча, сул ягына яткырасы һәм башын кыйблага борып куясы. Вак хайванның, арткы уң аягыннан кала, өч аягы да бәйләнә. Корбан чалучы кеше ният кыла, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Аннары «Әл-Әнгам» сүрәсенең әлеге аятләре укыла:

قُلْ إِنَّ صَلَاتِى وَنُسُكِى وَمَحْيَاىَ وَمَمَاتِى لِلَّهِ رَبِّ ٱلْعَٰلَمِينَ ﴿١٦٢﴾ لَا شَرِيكَ لَهُۥ ۖ وَبِذَٰلِكَ أُمِرْتُ وَأَنَا۠ أَوَّلُ ٱلْمُسْلِمِينَ

**«[Расүлем!] Әйт: «Һичшиксез, минем намазым, [хаҗ һәм корбан кебек бөтен] гыйбадәтләрем, яшәвем һәм үлемем – барча галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы өчен. Аның һичбер тиңдәше юк. Миңа бу [ихлас] әмер ителде һәм мин – [өммәтемә карата] мөселманнарның беренчесемен».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:162-163

Гарәп телендә укылышы: «Әгуузү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль иннә саләәтии вә нүсүкии вә мәхъйәәйә вә мәмәәтии лилләәһи раббил гааләмиин. Ләә шәриикә ләһ. Вә бизәәликә үмиртү вә әнәә әүввәлүл-мүслимиин».

Аннары: بِسْمِ اللهِ، اللهُ أَكْبَرُ «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр», – дип хайван чалына, дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Корбан чалган кеше, пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса – Аллаһы Тәгалә аңа ни теләсә, шуны бирер».

Чалынган корбанның итен тарату тәртибе: итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе – ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалдырган кешенең гаиләсенә кала.

Корбан чалуның үз хикмәте һәм файдасы: беренчедән, корбан чалу Аллаһыга һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик корбан чалып, без Аңа якынаябыз. Икенчедән, корбан чалу Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Өченчедән, мөселманнарның кор-

бан чалуы – аларның Аллаһы юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Ә фазыйләтләренә килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһыга шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти, чалынган хайван Кыямәт көнендә корбан чалучыны Сират күпере аша алып чыга һәм аның котылуына сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Гадәттә, без һәр елны көчебездән килгәнчә, гает бәйрәмен олылап үткәрергә тырышабыз. Күпләребез бу йоланы авылларына, якыннары янына кайтып үти, ә андый мөмкинлекләре булмаучылар мәчетләргә мөрәҗәгать итә ала.

Раббыбыз Аллаһы чалган корбаннарыбызны кабул кылып, әлеге изге гамәлнең булган хата-кимчелекләребез, гөнаһларыбызның гафу ителүенә сәбәпче кылса иде.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы Корбан гаете хотбәләре*

# خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلَامُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّهَ اِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاٰيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّـهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّـهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللَّـهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللَّهِ، اِنَّ اللَّهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللَّهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللَّهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

## Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транскрипциясе

## Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-тауәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгааләә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әуҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгәтин вәд-дa’нү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә’ү вәл-гарҗәәә’ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әуҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт ли-гаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә’ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү’минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә әшһәду әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәлләӟиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә’и вәл-мүрсәлиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадыйн. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү’миниинә вәл-мү’минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә’и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә’әр-раашидиинә вәл-үмәраәа’әл-мәдыйнәл-ләӟиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаӟәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ’мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ӟил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиӟукум ләгәлләкүм тәӟәккәрүүн. Үӟкүруллааһәл-галиййәл-гаӟыымәл-хәййәл-каййүүм, йәӟкүрүкүм вәш-күрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләӟикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгӟаму вә әтәммү вә әкбәр.

# Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының Заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкъләр дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) – җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә корбанны: «Корбан чал!» – дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек – җиде кешедән һәм сарык вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар – Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрик көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыенабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә —аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки: Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәр салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәр салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә

һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син – догаларны кабул итүче, бәрәкәт индерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәләләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*20 нче июль вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн, әммә бәгъд: барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз, хәмде-сәналәребез галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә һәм дә салават-шәрифләребез Аның сөекле хәбибе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән, мөселманнарга һидаять юлын күрсәткән Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Аның әһле-бәйтенә, сәхабәләренә, табигыйн һәм тәбге-табигыйннәргә, галим-голәмәләргә, имамнарга, остазларга, шәехләргә, ислам юлында булган бәндәләргә Аллаһының рәхмәте һәм мәгъфирәте ирешсә иде. Безгә тәүфыйк-истикамәттә булып, киләчәктә дә шөкеранә һәм изгелек кылучылардан булырга Аллаһы Раббым насыйп итсә иде.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Газиз дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөселманнар бүген бөтен ислам дөньясы мәчетләрендә Гыйдүл-Әдха – Корбан бәйрәме көнен билгеләп үтә. Шушы күркәм бәйрәм көнендә күбрәк дога кылып, рәхмәт-шөкерләребезне әйтсәк иде, Раббыбыздан бер-беребезгә изгелек теләп, мәгъфирәт сорасак иде.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсен.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын, чалган корбаннарыбыз бәрабәренә, Аллаһы Тәгалә безгә Кыямәт көнендә Сират күпереннән яшен тизлеге белән үтәргә насыйп итсә иде!

Корбан – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әмер иткән әҗер-саваплы, Раббыбыздан бүләк буларак иңгән олуг гыйбадәт. Әлеге гыйбадәт вәҗиб (тиешле) гамәл булып санала. Бу чиксез нигъмәтләре белән куандырып торган Раббыбызга шөкераналар кылып, итагать итү билгесе.

Матди яктан тиешле нисабы булган теләсә кайсы мөселман кешесе корбан чалу йоласын үтәргә тиеш. Ул – Корбан бәйрәме көннәрендә (10, 11, 12 нче зөлхиҗҗә) хайванны чалу белән башкарыла. Белүебезчә, аңа хәтле чалынган корбан гади ит булып саналыр.

«Корбан» Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә, Аның ризалыгына, хайванны (кәҗә, сарык, тәкә, сыер, үгез, буйвол яки дөя) бугазлап, якынаю (әжер-саваплы эш) дигән мәгънәне аңлата. Корбанга сайланган хайван нинди сыйфатта һәм ничә яшьтә, нинди рәвештә булырга тиешлеген, бу йоланы кемнәргә башкарырга кирәклеген безгә шәригатебез аңлата.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Кайбер кешеләр корбанны: «Бу корбанны мәрхүм әти-әнием өчен чалам», – дип ниятли. Онытмыйк: корбан бары тик Аллаһы ризалыгы өчен генә башкарыла, ләкин әҗер-савабын мәрхүм «әти-әнигә»дә багышлап була, Раббыбызның рәхмәте киң. Иң мөһиме ихласлык белән Аллаһы Тәгалә рызалыгы өчен булсын. Шулай ук үзеңнең гаиләң исеменнән башкарганнан соң, башка кеше өчен дә бугазларга рөхсәт ителә. Коръәни

Кәримдә Раббыбыз болай дип боера:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«[Шулай булгач] Раббың өчен намаз укы һәм [Аның исеме белән] корбан чал [да, корбан итләрен юксылларга тарат]».**

«Кәүсәр», 108:2

Аяти кәримәдә: «Раббың өчен корбан чал», – дип китерелә. Гали бине Әби Талиб Расүли Әкрамнең әлеге хәдисен риваять итә: «Аллаһы Тәгалә Үзеннән башкага корбан чалган кешегә ләгънәт кылды!»

Мәшһүр хәдистә Расүли Әкрам Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гамәли сөннәте китерелә: ул үзе һәм бөтен мөселманнар исеменнән берәр корбан чалган иде. Корбан чалган вакытта: «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр (Аллаһының исеме белән, йә Аллаһы). Бу корбанны Мөхәммәдтән, аның гаиләсеннән һәм аның өммәтеннән кабул ит», – дип әйтте. Шуннан соң ул ике корбан чалды».

Теләгән кешегә шәригать ике корбан чалырга да рөхсәт итә: ихласлык белән үз исеменнән һәм башкалар исеменнән дә башкара ала.

Хәзрәти Гали радыяллаһу ганһе ике корбан чалып, шуның берсен Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышлый торган була. Моның сәбәбен сораганнарга: «Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзең исән чакта, минем өчен дә корбан чал», – дип васыять әйтеп калдырды. Аның бу васыятенә бервакытта да хилафлык китермәм», – дип җавап биргән.

Шушы хәдисләр безгә түбәндәгеләр өчен дәлил булып тора:

1) Корбан бары тик Аллаһы ризалыгы өчен генә бугазлана;

2) өстәмә сарыкны чалу, яки башка хайванны корбан китерүнең әҗер-савабын мәрхүм «әти-әнигә» дә багышлап була, Раббыбызның рәхмәте киң.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Гает намазыннан соң, гадәттә, без корбан чалырга ашыгабыз, ләкин корбан чалган вакытта да үзебезнең мөселман икәнлегебезне онытмасак иде, сабырлык белән бәйрәм көнендә башка бәндәләрнең дә хакларына кермәсәк, бәйрәмне бәйрәм итеп үткәрсәк иде.

Иң мөһиме – Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәү, корбанның хикмәтенә ирешү. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә».**

«Хаҗ», 22:37

Тәкъвалык – калебтә, тәкъвалык – Аллаһы Тәгаләдән курку, Аның кушкан әмерен үтәү, үзеңне эчке яктан тәрбияләү һәм яхшырту. Пәйгамбәребезнең хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә хәбәр иткән: «Гаиләдә ничә кеше булуга карамастан, гаилә исеменнән бер корбан чалсаң да була». Безгә йөкләнгән бер корбан чалу – тиешле (вәҗиб) булып тора, икенчесе – нәфел.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәменең нигез-тарихы Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһүмәссәлам белән бәйле. Бу вакыйгада зур гыйбрәт бар: беренчедән, нинди генә авыр боерык булмасын – Раббыбызның әмеренә буйсынырга кирәк; икенчедән, кешенең җаны, калган мәхлүкъларга караганда, Раббыбыз хозурында күпкә өстенрәк; өченчесе, авырлыктан соң, җиңеллек килә; дүртенчесе, шәйтан вәсвәсәсенә бирелмәсәк, дөньяви ва ахирәви бәхет-рәхәткә ирешә алырбыз; бишенчесе: әти белән баланың мөгамәләсе һ.б.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан бәйрәменең хикмәте бары тик гает намазы һәм корбан чалу белән генә чикләнми.

Корбан – ул:

1. Бәйрәмдә очрашып, туганлык жепләрен ныгыту;

2. Халыкка ярдәм күрсәтү (фәкыйрь-мескеннәргә, мохтаҗларга корбан итен тарату, саранлыктан саклану);

3. Корбан чалу аркылы Раббысының әмерен үтәү, итагать кылу;

4. Бәйрәмнәрнең иң олысы, пәйгамбәрләрдән килгән бәйрәм, аны саклап, башкаларга җиткерү;

5. Корбан чалу аркылы Раббысының ризалыгына ирешү мөмкинлеге;

6. Корбан сәбәпле Раббыбыз биргән нигъмәтләргә шөкеранә белдерү;

7. Корбан – гөнаһлардан пакьләнү.

Тирә-яктагы дусларыбызга карасак, күпме кеше дөньядан бәрзах (кабер) тормышына күчеп китте. Алар арасында мәчет салучылар, хаҗ кылучылар, корбан чалучылар, садака-зәкят биреп, намаз укучылар булса, сөенербез. Аллаһы Тәгалә кылган гыйбадәтләребезне кабул итсен, бөек җәннәтләренә керүне насыйп итсен. Ләкин араларында намаз уку авыр эш булып күренгән кешеләр дә бар иде. Яки аны шәйтан кыен бер эш итеп күрсәтте: «Намазның тәртибен дә белмисең, син мәчеткә йөрмә», – дип, икенче берсенә: «Әле сиңа монда килергә иртәрәк, картайгач, яки эчүеңне ташлагач барырсың», – дип вәсвәсә кыла иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Үлем – ул хак, Аллаһы – хак, җәннәт, җәһәннәм – хак. Изгелектә бер-беребезгә ярдәм күрсәтик. Үзебез белән бары тик эшләгән изгелекне генә ала алабыз, башкасы кала.

Мөхтәрәм җәмәгать! Мөмкинлеге була торып та, кеше намаз укымаса яки корбан чалмаса, зур гөнаһлы булыр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем дә кем (Корбан чалырга) мөмкинлеге була торып, корбан

чалмаса, безнең намаз укый торган җиргә якын килмәсен», – дип әйткән.

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Корбан чалганда, тәртипне сакларга кирәк. Хәдисләр җыентыгында Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе риваять итә: «Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер көнне мөгезле, таза ике сарыкны корбан итеп чалды. Ул, сарыкны суйганда, аягы белән сарыкның сыртына басып: «Бисмилләһи Аллаһү әкбәр», – дип суйганын күрдем».

Өстәмә дога кылып, корбан чалуны җиренә җиткереп башкарсак, Аллаһының бәрәкәте иңәр. Хәдис җыентыкларының берсендә Әбү Давыд радыяллаһу ганһедән түбәндәге риваять килә: Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһе исемле сәхабәдән хәбәр ителә: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике мөгезле, ак төстәге, печелгән тәкәне корбан итеп чалды. Ул, аларны чалырга дип яткыргач, түбәндәге сүзләрне әйтте:

«Инни вәҗҗәһтү вәҗһиилил-ләҙии фәтарас-сәмәәвәәти вәл әрдъ галәә милләти Ибраһиимә хәниифәә вә мәә әнә мин әл-мүшрикиин. Иннә саләәтии вә нүсүүкии вә мәхъйәәйә вә мәмәәтии лилләәһи Раббил гааләмиин. Ләә шәриикәләһ. Вә биҙәәликә үмиртү вә әнәә әүввәлүл-мүслимиин».

Мәгънәсе: «Дөреслектә, мин йөземне, Аллаһыга тиңдәш кылмыйча, Ибраһим пәйгамбәр динендә булган килеш, күкләрне, җирне барлыкка китергән Затка юнәлттем. Һәм мин Аллаһыга тиңдәш кылучылардан түгел. Дөреслектә, минем намазым да, корбаным да, тормышым һәм үлемем дә дөньяларның Раббысы – Аллаһы өчен. Аның тиңдәше юк. Мөселманнардан булган хәлдә, миңа шуны эшләү әмер ителде. Йә Аллаһы! Бу (корбан) Синнән (килгән ризык иде) һәм ул Синең өчен Мөхәммәдтән һәм аның өммәтеннән (чалына). Аллаһының исеме белән. Ул Аллаһы – иң бөек». Соңыннан ул аларны чалды».

الله أكبر، الله أكبر، لا إله إلا الله، والله أكبر، الله أكبر، ولله الحمد

Хәзер безнең янәшәдә бәйрәм намазында төрле шәһәр, илләр, хәтта төрле континентлардан килгән мөселманнар катнаша. Тышкы аермабыз тел, тән төсе һ.б. булса да, без бер-беребезне ихластан сәламлибез һәм бер Аллаһыга итагать итеп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде һәм барлык мөселманнарны бер-берсенә карата дин-кардәшләр итте. Киләчәктә дә дус яшик.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, татарстанлылар! Изге бәйрәмебез мөбарәк булсын! Раббыбыз һәммәбезгә дә иман байлыгы, саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете бирсен.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*23 нче июль вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Калеб катылыгы

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әлхәмдү лилләәһи раббил гааләмиин.

Галәмнәрнең бердәнбер Раббысы булган, барлык мәхлүкъларның Яратучысына, җирләрнең һәм күкләрнең Хуҗасына хәмед-сәналәребез булсын.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Дөреслектә, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул тәкъва булса, кешенең бөтен тәне тәкъва булыр. Әгәр ул бозылса, бөтен тән бозылыр. Һәм бу – йодрыктан да кечкенә булган йөрәк”[1].

Адәм баласының күңелендә нәрсә булса, тормышында, яшәү рәвешендә дә шул була. Тышкы кыяфәтебез белән барыбыз да бер төсле, әмма калебләребез һәм йөрәкләребез белән бер-берләребездән аерылып торабыз. “Йөрәге, бәгыре каты” дигән сүзне барыбызның да ишеткәне бардыр. Болай дип әйләнә-тирәдәгеләргә начарлык кылучы, “изгелек” дигән төшенчәне белмәүче кешеләр турында әйтәләр. Иң яманы шул: бу кешеләр үзләренең хаксыз булуын танымый, аларга никадәр генә аңлатырга тырышсалар да, моның нәтиҗәсе юк, чөнки бу кешеләргә шәйтан барлык начар гамәлләрне матур итеп күрсәтә. Болар хакында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

[1]Имамнар Әл-Бохари, Әл-Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

وَلَٰكِن قَسَتْ قُلُوبُهُمْ وَزَيَّنَ لَهُمُ الشَّيْطَانُ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ ﴿٤٣﴾

**"... ләкин бәгырьләре катты һәм алар кылган [начар] нәрсәне шәйтан аларга бизәде".**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:43

Киләсе аятьтә Аллаһы Тәгалә күңелләрне таш белән чагыштыра. Коръәндә болай дип әйтелгән:

ثُمَّ قَسَتْ قُلُوبُكُم مِّن بَعْدِ ذَٰلِكَ فَهِيَ كَالْحِجَارَةِ أَوْ أَشَدُّ قَسْوَةً

**"... күңелләрегез таш кебек катты яки тагы да катырак булды".**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:74

Галимнәр бу дөньядагы иң каты әйберне атаган. Бу тимер дә, таш та түгел. Бу – иман китермәгән, Аллаһыны танымаган кешенең йөрәге. Бу сүзләр хакында төптән уйласак, үзебез дә аңларбыз. Чыннан да, Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләрен күрмәүче, ишетмәүче, алар өчен рәхмәтле була белмәүче кешенең йөрәге нинди булырга тиеш икән соң?! Бу дөньяга яратылганнан бирле үзебезнең Аллаһының рәхмәте белән тереклек итүебезне тоябыз. Ул теләмәсә, хәтта сулыш та ала алмас идек. Әмма көчсез адәм баласы һаман тәкәбберләнеп, нәфесенә ияреп яши, Раббысын танымый, Аңа итагать итми, гөнаһлы гамәлләрдән арынмый. Моның сәбәбе – калеб катылыгы. Димәк, ул нәсыйхәтләнә, гыйбрәт ала, хакыйкатьне күрә алмый. Бар нәрсәдән дә катырак кеше йөрәге генә була ала.

Ә мәрхәмәт тулы йөрәкнең ачык мисалы – ул, әлбәттә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип сөйләгән: "Берьюлы Расүлебез оныклары Хәсән белән Хөсәенне үпкәнен бер кеше күреп торып: "Йә, Расүлуллаһ, минем дә балаларым бар. Әмма мин аларны үпмим", – диде. Пәйгамбәребез аңа: "Аллаһы синең

йөрәгеңнән мәрхәмәт хисләрен алгач, мин нәрсә эшли алыйм?” – дип җавап бирде.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять иткән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Иң начар йөрәкләр шулдыр, алардан Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтлелекне алган һәм бу йөрәкләр иң катылар”.

Йөрәкнең каты булуы, кешенең мәрхәмәтлелек хисләреннән мәхрүм калуы, иң беренче чиратта, кешенең үзе өчен авыр. Бәлки ул күпмедер вакыт аны сизмәс тә яки игътибар бирмичә яши алыр, әмма вакытлар узганнан соң каты калеб үзен сиздерәчәк. Бу кеше күңелендә бушлык хасил булуы, бернәрсәнең дә ямен тоя алмавы белән билгеләнәчәк. Бу бик авыр халәт. Бу кеше өчен газап. Мәлик бине Динар рахимәһуллаһи: “Кеше өчен йөрәге катыланудан да куркынычрак җәза юк”, – дип әйткән.

Әгәр кеше үзенең калебенең каты булуын тоя яки моны тануда аңа кемдер ярдәм итә икән, алга таба ни рәвешле эш итәргә соң? Моны дәвалау юллары бармы? Дәвалау дип әйтүебезнең сәбәбе шунда: без каты йөрәкле булуны бер чир кебек күрәбез. Иң баштан ул бу кешенең янәшәдәгеләренә генә зыян салса, күпмедер вакыт үтү белән бу адәм баласының үзенең дә тормышын авырайта.

Расүлебез кеше калебен чистартсын өчен бик күп нәсыйхәтләр биргән. Ул бер хәдисендә: “Дөреслектә, тимер тутыккан кебек, йөрәкләр дә тутыга”, – дип әйткән. Расүлебездән: “Йә, Аллаһының Расүле, ә аны нәрсә чистарта?” – дип сораганнар. Ул: “Үлемне еш искә алу һәм Коръән уку”, – дип җавап биргән. Тагын бер хәдистә: “Җеназа намазында еш катнашу”, – дип әйткән.

Хәтта диннән ерак булган кешеләр дә, җеназаны күреп, үзгәрәләр, дөнья тормышы турында уйланалар. Шуңа күрә җеназа намазларында катнашу, каберләрне зиярат кылу, еш Коръән уку һәм үлемне искә алу кешенең йөрәген үзгәртә, аңа тәэсир ясый.

Димәк, үлемне искә алу, Коръәни Кәримне уку һәм җеназа намазларында катнашу кешенең калебен йомшарта, бу гамәлләрне һәрдаим кылучы кешенең калебе катыланмый.

Йөрәкнең дәваланганын күрсәтә торган билгеләрнең берсе – ул күз яшьләре. Бер тәкъва иясеннән болар хакында соралгач: “Бердәнбер дәлил – ул Коръән укыганда, нәрсәне дә булса искә төшергәндә йөрәк чисталыгыннан, йомшаклыгыннан килгән күз яшьләре”, – дип әйткән.

Чыннан да, елау кешегә җиңеллек китерә. Күренекле татар мәгърифәтчесе, зыялы Каюм Насыйри: “Китап укып елый алганның күңелендә булмый каралык!” – дип язып калдырган. Йөрәге йомшак, күңеле чиста булган кешедә башка мәхлүкъларга карата мәрхәмәт, кызгану хисләре була, ул гафиллектән, битарафлыктан ерак.

Кешенең калебе катылануының тагын бер сәбәбе – дини вазифаларны үтәмәве, бу калебләрне гафиллеккә китерә. Имам Әт-Тирмизи рахимәһуллаһи Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәнен риваять иткән: “Хакыйкатьтә, Аллаһыдан иң ерак булучы кешеләр – ул калебләре каты булучылар”. Аннан сәбәбен сораганнар. Һәм ул: “Алар харам ризыкны күп куллана һәм хәләл булганнарын да исраф кыла”, – дип әйткән. Димәк, Аллаһыдан, Аның сүзләреннән, фәрманнарыннан ерак булучы кешеләрнең калебләре катылана. Алар Коръәнне дә, Раббыбызның әйткәннәрен дә танымый. Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

لَوْ أَنزَلْنَا هَٰذَا الْقُرْآنَ عَلَىٰ جَبَلٍ لَّرَأَيْتَهُ خَاشِعًا مُّتَصَدِّعًا مِّنْ خَشْيَةِ اللَّ

**“Әгәр дә Без бу [кадәрле әһәмиятле мәсьәләләрне эченә алган] Коръәнне бер тауга иңдергән [һәм аңа да сезгә биргән кебек акыл биргән] булсак, син аны Аллаһыдан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең”.**

«Әл-Хәшр / Җыен», 59:21

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән йөрәк тутыгуның сәбәбе турында сораганнар. Расүлебез йөрәкнең гафләттә булуының ике сәбәбе барлыгын әйткән – ул кешенең бу дөньяны яратуы һәм үлемне яратмавы. Әйе, берәү дә үлемне яратмый, аннан курка, билгеле. Әмма үлем хак. Үлем – ул бетү, юкка чыгу түгел. Гәрчә, Аллаһыга, үлгәннән соң терелүгә, Ахирәт көненә ышанмаган кешеләр шулай уйласа да. Үлем – бер халәттән икенчесенә күчү ул. Ягъни безнең җаныбыз бу дөньядагы тормышын калдырып, икенче дөньяга күчә. Ә аннан соң үз юлын дәвам итә. Һәм бу дөньяда ничек яшәвенә карап, Ахирәт тормышында йә хәерле урынга, йә куркыныч урынга килеп ирешә.

Менә шулар хакында уйлануыбыз, шул рәвешле фикерләп, үлемгә әзерләнүебез тиешле. Ничек кенә яратмасак та, көннәрдән бер көнне үлем киләчәк. Аннан берәүнең дә котылып калганы юк. Үлемне зикер итеп, аңа әзерләнеп яшәсәк, беренчедән әзерлекле кеше булырбыз, икенчедән калеб катылыгыннан котылырбыз, иншәАллаһ.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән йөрәкнең гафләттә булуының сәбәбен сораганнар. Һәм ул әлеге аятьне укыган:

كَلَّاۖ بَلۡۜ رَانَ عَلَىٰ قُلُوبِهِم مَّا كَانُوا۟ يَكۡسِبُونَ ﴿١٤﴾

**“Юк! [Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!] Кылган [начар] нәрсәләре [һәм рәттән эшләгән гөнаһлары] аларның йөрәкләрен [мәгънәви бер] тутык белән каплаган”.**

«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:14

Кешенең калебе катыланганын ул үзе дә сизми, аны гыйбадәт кылуда ялкаулык баса башлый. Мәсәлән, Коръәннең бер генә битен булса да уку ике-өч минут вакытны ала. Әмма без шуңа да вакытыбызны кызганабыз. Шул ук вакытта буш сүз сөйләргә, вакытыбызны әрәмгә үткәрергә мөмкинбез. Бу йөрәкнең каты, гафил булуын белдерә торган галәмәт.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм көненә йөз мәртәбә: “Йәә мүкаллибәл кулүүби ҫәббит кальбии галәә диииникә”, ягъни: “Йә, калебләрне әйләндерүче, минем калебемне Синең динеңдә нык ит”, – дип әйтә торган булган. Ягъни Аллаһыга калебләребезне динебездә ныгытуын сорап дога кылу мөһим.

Галимнәрнең тагын бер киңәше – нәсыйхәтләр бирелә торган мәҗлесләрдә еш булу. Нәкъ менә шундый мәҗлесләрдә ихласлылык турында сөйләнә, биредә без үзебезнең кимчелекләребез хакында уйланабыз, рухи яктан чистарынабыз.

Чыннан да, Аллаһыны искә алу, харамнардан тыелу, ятимнәрнең башын сыйпау, кешеләрне ашату, галимнәр белән аралашу, җеназа намазларында катнашу, зиратларда булу – калебләрне төзекләндерә торган чаралар булып тора. Кайбер калебләргә һәрвакыт искә төшереп тору кирәк. Шуңа да без калебләребезгә битараф булмаска, тәнебезне сәламәтләндереп, кайгыртып торган кебек, калебләребезне дә йомшартып, борчулары булса, аннан арындырып торырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә күңелләрбезгә йомшаклык, миһербан-шәфкать, мәрхәмәт хисләре салып, динебезне башкаларга күркәм яктан күрсәтүдә безгә ярдәм итсә иде. Һәрнәрсәдән гыйбрәт алып, нәсыйхәтләнеп, Раббыбызның ризалыгына ирешергә булышса иде. Калебләребезне гафләттән, битарафлыктан, катыланудан арындырса иде. Аллаһы Раббыбыз динебезне дөрес аңлап, башкаларга да аңлатуда өлеш кертүебездә ярдәм итсә иде. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*“Хозур” редакциясе*

*30 нчы июль вәгазе*

*Зөлхиҗҗә аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# «Бу бит сөннәт кенә...»

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһии әҗмәгыйн.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Үзенең киң Рәхмәтләре белән һәрбер адәм баласын шушы дөньяга халык кыла һәм шушы дөньяда югалмасын, тугры юл белән яшәсен дип һәрбер кешегә, һәрбер милләткә, һәрбер буынга һәм һәрбер җиргә расүлләр аша диннәрен ирештерә.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең өммәтебезгә дә, Кыямәт көнендә бер нур булсын, бу дөньяда рухи бер укытучы булсын дип, Расүли Әкрам Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне пәйгамбәр итеп җибәргән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең калебләребезгә бер нур булып тора. Аңа карата булган ярату чиксез. Аңа карата булган хөрмәт, аның әдәбенә, аның сыйфатларына карата булган хөрмәт бик олыдыр.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Рәхмәте белән бу дөньяга бер рәхмәт итеп җибәрелде. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә дә бу хакта әйтеп үтә:

وَمَآ أَرْسَلْنَٰكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَٰلَمِينَ ﴿١٠٧﴾

**«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِى رَسُولِ ٱللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُوا۟ ٱللَّهَ وَٱلْيَوْمَ ٱلْـَٔاخِرَ وَذَكَرَ ٱللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

**«Сезнең өчен [бигрәк тә] Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан башкарылган һәрбер эш, гамәл безгә бәрәкәтле олы бер үрнәк булып тора.

Ә инде Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә, Үзенең Рәхмәте белән, без адашмасын, туры юлдан барсыннар дип, безгә Коръәни Кәримне иңдергән, ягъни шушы Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә безгә итагать итеп, иман китерергә, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм артыннан иярергә, шулай ук аңа да итагать итәргә, бозык гамәлләрдән, начар эшләрдән сакланып яшәргә һәм изге гамәлләр кылырга әмер итә.

Ә инде Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен үтәгәннән соң, Аллаһы Тәгалә Расүлебезгә итагать итәргә, ягъни ул кушканнарны үтәргә, ул тыйганнардан тыелырга әмер итә, чөнки Аллаһының Расүле – безнең өчен олы үрнәк, дип әйтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күрсәткән һәрбер гамәл безгә сөннәт булып тора. Аллаһы Тәгалә һәм дә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яраткан һәр кеше, һәр мөселман Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагать итеп яшәргә тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә нурлы бер юл күрсәтүче булып килде. Кем дә кем Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм артыннан иярсә, аның сөннәтен үтәп яшәсә, һичшиксез, ул нурлы, матур бер юлдан бара. Кем дә кем аның сөннәтен үтәп яшәргә тырышса, һичшиксез, ул беркайчан да бәхетсез булмаячак.

Әмма пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне никадәр яратсак та, без аның бөтен сөннәтен дә үтәп бетерә алмаска мөмкинбез. Ләкин мөмкин булган кадәрле бөтен сөннәтләрен дә үтәп барырга кирәк. Аллаһы Тәгалә моның өчен олы әҗерләрен бирер, иншәАллаһ.

Әмма, кызганычка, бүгенге көндә күп вакыт мондый сүзләр ишетергә туры килә: «Бу бит бары тик сөннәт кенә, бу фарыз түгел. Бу – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте генә, ул бит аларны мәҗбүри эшләргә кушмаган». Бу бик хаталы, ялгыш фикер, чөнки әгәр без аны үзебезгә үрнәк алганбыз икән, безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бөтен кылган гамәлләрен ихлас күңелдән үтәп барырга тырышырга кирәк. Кешенең нәфеле, сөннәте юкка чыкканнан соң, аның фарыз гамәле дә юкка чыгарга мөмкин, Аллаһы сакласын. Фарыз гамәл ул матур бер асылташ булса, сөннәт гамәл – шушы асылташны уратып алган алтын, ягъни сөннәт гамәл берничек тә артык була алмый. Сөннәт гамәлне калдырганга гөнаһ булмаса да, ләкин, аны кылган өчен, савап бар. Иң мөһиме – сөннәт гамәлне кылган өчен Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатьчелеге була. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ияргән, аның сөннәтен үтәгән барлык кешегә дә Расүлебез Кыямәт көнендә үзенең шәфәгатьчелеген вәгъдә итә. Ә кем инде шушы сөннәтләрне калдырса, сөннәтләргә игътибарсыз, салкын карашта булса, аның мөһимлеген инкяр итеп яшәсә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатьчелегеннән мәхрүм калырга мөмкин, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай

дип әйтә:

يَٰٓأَيُّهَا ٱلَّذِينَ ءَامَنُوٓاْ أَطِيعُواْ ٱللَّهَ وَأَطِيعُواْ ٱلرَّسُولَ وَأُوْلِى ٱلْأَمْرِ مِنكُمْ... ﴿٥٩﴾

**«Ий, иман китерүчеләр! Аллаһыга итагать итегез, Расүлгә һәм үзегездән булган хөкем ияләренә итагать итегез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:59

Аллаһы Тәгаләгә итагать иткән һәр кеше Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә итагать итәргә тиеш, чөнки Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне соңгы пәйгамбәр, соңгы расүл итеп безгә сайлап җибәрде. Ул – Хәбибулла, расүлуллаһ һәм Мостафа булып безнең арабызга килде, безгә динне өйрәтүче олы бер зат булды, ягъни мөселманнарга, өммәтебезгә расүл итеп җибәрелгән Аллаһының яраткан бер колы иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык фарыз гамәлләрне үтәп, өстәмә намазлар, гамәлләр кылып яши иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләре аның кылган гамәлләрен хәтерләрендә калдырып, үзләре дә бу гамәлләрне үти башлыйлар. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәрвакыт ахшам намазыннан соң ике рәкәгать намаз укырга кушкан. Бу ахшам намазының сөннәте булып бара. Иртәнге намаз алдыннан – ике рәкәгать, өйлә намазы алдыннан – дүрт һәм өйлә намазыннан соң ике рәкәгать сөннәт намазлары укыган. Болар барысы да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән калган көчле сөннәтләр булып торалар. Шулай ук намазлардан соң тәсбих тарту да олы бер сөннәт гамәл булып тора. Кызганыч, күпләр: «Бу фарыз түгел, бары тик сөннәт кенә», – дип вакытларын кызганып, шушы дөньяга бирелеп, күпчелек очракта сөннәт гамәлләрне калдыралар һәм ахыр чиктә, әҗерсез, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатьчелегенә

илтә торган бер юлдан мәхрүм калалар. Ә бит Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Онытылган сөннәтләрне торгызыгыз. Аларны торгызган кешегә зур бүләкләр бардыр. Ахирәт тормышында зур нигъмәтләр булыр», – дип әйткән. Димәк, без сөннәтләрне калдырырга тиеш түгелбез. Киресенчә, шушы авыр һәм гыйлем юкка чыгып барган заманда сөннәтләрне вакытында һәм тиешле рәвештә үтәп барырга тиешбез. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә бөтен гамәлләрне ихлас күңелдән кылу мөмкинлеген өйрәтте. Фарыз гамәлләрдән кала, ул тагын күп өстәмә намазлар, мөгамәләт һәм гаиләгә мөнәсәбәт, ашау, йоклау, госел, тәһарәт – боларның бөтенесен дә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өстәмә гамәлләр буларак башкарды. Һичшиксез, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ияреп, аның артыннан барлык гамәлләрне кылучыларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булачак, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әмер итә:

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ ٱللَّهَ فَٱتَّبِعُونِى يُحْبِبْكُمُ ٱللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَٱللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа ияregez, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Аллаһы Тәгаләне яраткан һәр кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең артыннан ияреп, аның кылган бөтен гамәлләрен кылып барырга тиеш. Шушы очракта, һичшиксез, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә һәрбер шушы сөннәтне үтәп баручыга олы бер әҗерләрен бирер, иншәАллаһ.

Сөннәт гамәл – ул фарыз гамәлне саклый торган өстәмә бер гамәл, гыйбадәт. Фарыз гамәлләренең камиллеккә ирешүен теләгән кеше

сөннәт гамәлләрен җиренә җиткереп үтәргә тиеш. Һәрбер гамәлдә, яшәешебезнең һәрбер көнендә, тормышыбызның олы бер адымында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте булуы бик мөһим, чөнки Аллаһының Расүле безгә рухи укытучы, һәм аның сөннәтен үтәгән һәр кеше бәхетле, хәерле сәгадәтле юлдан бара. Кем дә кем фарыз гамәлләрне кылып, сөннәтләрне кимчелек китермичә үтәсә, бу кешегә бәхетсезлек, начарлык, хәерчелек, фәкыйрьлек, ачлык, рухи бушлыктан чыгу юллары бар, чөнки шушы сөннәт юлында гына котылу бардыр. Сөннәт юлы – үзе бер нурдыр. Фарыз гамәлләрне үтәүче шушы сөннәт гамәлләрне дә үтәп яши икән, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә аның бөтен гамәлләренә бәрәкәтен бирәчәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яраткан кеше аның сөннәтенә тотынырга тиеш, чөнки бүген без аяныч хәлләрне күрәбез. Берәүләр җырчыларны, икенчеләре спортчыларны, кино актерларын үзләренә үрнәк итеп алалар, аларга охшарга тырышалар, нәкъ аларныкы кебек тормыш рәвеше алып барырга тырышалар. Ә бит тарихта иң олы кеше булучы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм – иң күркәм әхлак, үрнәк иясе, чөнки Аллаһы Тәгалә: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар. Без аны бөтен галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрдек», – дип әйтә. Аллаһының Расүленә ияргән, шушы сөннәтләргә тотынган һәм аның кебек тормыш рәвешен алып барган, мөгамәләт корган һәр кешегә киң әҗер-саваплар, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәфәгатьчелеге һәм Кыямәт көненнән соң аның белән җәннәтләрдә утыру мөмкинлеге булачак, иншәАллаһ. Шушыңа ышанган, инанган һәр кеше Аллаһы Тәгаләнең Китабын һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен тормышка ашырып, ягъни иң күркәм рәвештә яшәргә тырышырга тиеш. Бары тик шушы очракта гына Аллаһы Тәгаләнең һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәхәббәте бу кешегә төшәчәк, чөнки Аллаһының Расүленә охшарга тырышкан һәр кешене Аллаһы Тәгалә

ярата. Аллаһының Расүле – ул Хәбибулла, ягъни Аллаһының яратканы. Аллаһы Расүленә охшарга тырышкан һәр кеше – ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәхәббәтенә лаеклы кеше, аның дусты, якыны һәм аның артыннан иярүче була. Шушы кешеләрне, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә дә ярата.

Газиз дин кардәшләрем, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен торгызу һәр мөселманның өстендә олы бурыч булып тора. Бу гамәлләрне үтәүдә тырышлык куйган кешегә Аллаһы Тәгаләнең киң рәхмәтләре бардыр. Һәрберебез мөмкин булган кадәрле шушы сөннәтләрне үтәп яшик һәм безгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте вә бәрәкәте булыр, әҗер-саваплары ирешер. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабызга да бәхетле, сәгадәтле тормыш бирсә иде һәм гыйлемсезлек хөкем сөргән шушы авыр заманда Коръәни Кәрим һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте белән яшәргә насыйп вә мияссәр кылса иде. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә бәхет вә сәгадәт бирсә иде. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*

*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе,*

*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*6 нчы август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1442 ел*

# Мөхәррам аен каршылап…

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмин вәссаләтү вәссаләмү вә галәә расүлиһи Мүхәммәд вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Аллаһы Тәгалә бар, Аллаһы Тәгалә бер, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһ юк, Аннан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аның Расүле. Бөтен мактауларыбыз һәм сәналәребез, догаларыбыз, гыйбадәтләребез безне юктан бар иткән, безгә рәхмәтен күрсәткән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Әйтелгән салаватларыбыз бу дөньяга рәхмәт өчен килгән, безне бәхетле булырга өйрәткән, бөтен пәйгамбәрләрнең имамы булган, иң камил кеше – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсә иде.

Мөхәррам ае белән без яңа айны гына түгел, һиҗри буенча яңа елны да каршылыйбыз. Һиҗри дигән сүз нәрсәне аңлата соң? «Һиҗрәт», дин терминологиясеннән караганда, ул бер җирдән икенче җиргә «күченү», «күчү» мәгънәсендә килә. Һәм әдәби яктан, гарәп теле ягыннан караганда да «нәрсәнедер ташлау» дигәнне аңлата. Мәсәлән, ниндидер яхшы яки начар гадәтне ташлау, дип әйтик. Аны да һиҗрәт дип атыйлар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында берничә һиҗрәт кылына, ләкин безнең очракта Расүлебезнең Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылуы турында сүз бара. Бу һиҗрәт милади буенча 622 елда була. Мөхәррам ае, һиҗри елның башы буларак, Гомәр радыяллаһу ганһе хәлифә булганда билгеләнә. Мөхәррам ае яңа һиҗри елның беренче ае буларак кына калмый, әле ул дүрт тыелган айның берсе булып тора. Һәм Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә аның турында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ وَقَاتِلُوا الْمُشْرِكِينَ كَافَّةً كَمَا يُقَاتِلُونَكُمْ كَافَّةً ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ مَعَ الْمُتَّقِينَ ﴿٣٦﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһимуссәлам] калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез. Алар сезгә каршы барчасы ничек сугышкан кебек, сез дә [куркуга төшеп качмыйча һәм бер-берегезгә ярдәм кулы сузып] барчагыз мөшрикләр белән сугышыгыз һәм белегез, һичшиксез, Аллаһы – [ярдәме Аның әмерләрен тотып, харамнардан сакланган] тәкъвалык ияләре белән бергә».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Бу айда Аллаһы Раббыбыз сугышларны тыйган, ләкин безнең «сугыш» дигән мәгънәне чикләвебез, тарайтуыбыз дөрес булмас. Әгәр без бу мәгънәгә җитдирәк итеп карый белсәк, үзебезгә дә хәерле булачак. Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһенең сүзләрен моңа дәлил буларак китерәбез. Бу сүзләрдән чыгып, без бу тыюны сугыш яки төрле корал белән чабып йөрү яки шул төшенчәләргә хас булган нәрсәләр белән генә чикләмибез.

Безгә Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе шундый сүзләр әйткән: «Начарлык, золымлык, фәхешлек гел тыелган. Аллаһы ул әйберләр өчен бернинди вакыт та билгеләмәгән. Алар бу айда гына түгел, бүтән айларда да, бүтән вакытта да тыелган. Мәсәлән, ниндидер гыйбадәт, ниндидер яхшылык өчен Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә кайбер чакта аерым вакыт билгели. Рамазан аендагы ураза өчен, хаҗ өчен, мәсәлән. Ләкин бу начарлыклар өчен бернинди вакыт та билгеләнмәгән. Әмма аларны бу тыелган дүрт айда кылган кеше өчен зыяны күпкә арта, ә кылган изгелекнең дәрәҗәсе Аллаһы алдында күпкә үсә». Шушы сәхабә безгә бу тыюларны шулай ачыклап биргән. Димәк, бу тыю бер-беребез арасында сугыш булдырмауны гына аңлатмый, бу айны начарлык, золымлык, фәхешлек һәм бүтән начарлыклардан да тыелып үткәрү мөһим.

Шуңа күрә, хөрмәтле, газиз дин кардәшләрем, бөтен төр фәхешлектән тыелыйк, талашларга, бәхәсләргә кермәскә тырышыйк, хөсетлектән, начар уйлардан сакланыйк, бер-беребезгә карата хөрмәт, мәхәббәт хисләре тудырыйк. Һәм бер-беребезгә карата яхшы мөгамәләдә, яхшы элемтәдә булыйк. Бу айның бүтән айлардан аермалы булган гыйбадәтләре дә бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең мәшһүр хәдисендә: «Рамазан ае уразасыннан соң иң хәерле ураза – ул Аллаһының ае – мөхәррам аенда тотылган ураза. Ә фарыз намазыннан тыш, укылган иң хәерле намаз – ул төнге намаз», – дип әйткән. Пәйгамбәребез бу хәдистә мөхәррам аен, Аллаһы ае, дип билгеләде һәм аңа дәрәҗә бирде. Бу сүзләр, изгелекләр кылып, гыйбадәтләребезне арттырыр өчен, җитәрлек сәбәп булырга тиеш. Ягъни «Бу – Аллаһының ае», – дип әйтү – безнең өчен мөһим сүзләр. Галимнәр иҗтиһады буенча тыелган айлар – бәрәкәтле айлар, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең бәрәкәт урнаштырган айлары булып санала. Бәрәкәт нәрсә ул? Күбебез аның хакында белсә дә, кабат искә төшереп китик. Мәсәлән, бәрәкәт киемдә булырга мөмкин. Андый кием озак тузмый, килешле була, озакка җитә, формасын югалтмый. Ризыкның

да үз бәрәкәте бар. Мәсәлән, кеше артык ашамаса да, туклана. Ризыкка артык акча сарыф ителми. Вакытның да үз бәрәкәте бар. Мәсәлән, ике кеше бер төрле үк эшне башкара. Аллаһы Тәгаләдән бәрәкәт бирелгән кеше эшен бер сәгатьтә эшләп бетерә ала. Бәрәкәт булмаса, аны ун сәгатьтә дә җиренә җиткереп булмый. Акчада да шулай ук. Мәсәлән, ниндидер бер күләм акчаны алыйк. Бәрәкәт булса, ун мең акча да җитә. Бәрәкәт булмаса, йөз мең дә җитмәскә мөмкин.

Аллаһының рәхмәте, без бүтән вакытта гафиллектә, ваемсызлыкта яшәсәк тә, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә шундый бәрәкәтле айлар бирә. Без, бу айлар сәбәпле, ниндидер отышларга ирешә алабыз. Әгәр без бу айларда фәхешлектән, начарлыктан, золымнан саклансак, күбрәк тырышсак, гыйбадәтебезне арттырсак уңышка ирешербез.

Тиздән без мөселман тәкъвиме буенча яңа елга керәбез. Биредә Нух галәйһиссәламнең мисалын китерәм. Нух галәйһиссәламгә үлем фәрештәсе килгәч, аңа: «Йә, Нух, син тугыз йөз илле ел гомер иттең. Бу – бик күп вакыт. Әйдә, тормышыңа нәтиҗә ясa әле», – дигән. Нух галәйһиссәлам аңа шундый җавап кайтарган: «Әгәр дә менә бу вакытны (яшәгән елларны) исәпкә алсам, нәтиҗә буларак, бу вакытның тиз үтүенә мисал китерәм: бу ишекне ачып, башыңны тыгып карап, ишекне кире ябу сыман. Нәкъ шундый тизлектә бу тугыз йөз илле ел үтеп китте».

Без хәзер ваемсызлык күрсәтмәгән, гафиллектә булмаган, тормышы тулы бәрәкәт булган Нух галәйһиссәлам турында искә алдык. Хәтта аның да тормышы шундый ук тизлек белән үтеп киткән. Безнең бүгенге тормышка килгәндә, без аның узганын сизми дә калабыз. Күзне дә йомарга өлгермибез, ел да үтеп китә. Шуңа күрә дә игътибарлы булыйк, гыйбадәттә булыйк, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең ризалыгына ирешергә тырышыйк.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Вәлиуллин,*

*«Әхтәм» мәчете имам-хатыйбы*

*13 нче август вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Гашурә көне

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә сәйидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар кылып, безләрне халык иткән, тәрбияләгән Аллаһыга барча хәмде-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булсын. Һәм дә Аллаһының хак расүле, тугры пәйгамбәре, шәриф булган колы – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә салават-шәрифләребез ирешсә иде. Гашурә көне – харам булган дүрт айларның берсе – мөхәррам аеның 10 нчы көне. Коръәни Кәримдә Раббыбыз болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ ٱلشُّهُورِ عِندَ ٱللَّهِ ٱثۡنَا عَشَرَ شَهۡرٗا فِي كِتَٰبِ ٱللَّهِ يَوۡمَ خَلَقَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ
وَٱلۡأَرۡضَ مِنۡهَآ أَرۡبَعَةٌ حُرُمٞۚ ذَٰلِكَ ٱلدِّينُ ٱلۡقَيِّمُۚ فَلَا تَظۡلِمُواْ فِيهِنَّ أَنفُسَكُمۡۚ
وَقَٰتِلُواْ ٱلۡمُشۡرِكِينَ كَآفَّةٗ كَمَا يُقَٰتِلُونَكُمۡ كَآفَّةٗۚ وَٱعۡلَمُوٓاْ أَنَّ ٱللَّهَ مَعَ ٱلۡمُتَّقِينَ٣٦

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике. Шуларның дүртесе – харам [айлар]. Бу – [рәвешле елның унике ай булып, шуларның дүртесенең харам кылынуы турындагы хөкем Ибраһим һәм Исмәгыйльдән [галәйһимуссәлам] калган] хак дин. [Моннан соң бернинди айда да, бигрәк тә] Боларда [гөнаһ эшләү һәм гыйбадәтләрне кире кагу белән җаныгызны җәһәннәмгә атып] үз-үзегезгә золым итмәгез».**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Гарәп теленнән «Гашурә» дигән сүз «унынчы» дип тәрҗемә ителә. Бу көннең тарихи үзенчәлеген, аның мөселманнар өчен ни дәрәҗәдә югары көн икәнен барыбыз да аңлыйбыз, беләбез. Бу көн – пәйгамбәрләр тарихында да үз урынын алган көн. Гашурә көнендә күп гасырлар элек бер зур вакыйга, Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы була.

Муса галәйһиссәлам үзенең халкы белән артыннан куа килгән гаскәрдән качкан. Ул гаскәрнең башлыгы фиргавен була. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәлам халкына диңгездә юл яра, диңгез суы икегә бүленеп, коридор барлыкка килә, ә диңгез төбендәге җир коры була. Бу могҗизаны күрсә дә, үзенең имансызлыгы белән сукырайган фиргавен барыбер шушы коридорга керә. Муса үз халкы белән икенче ярга җитүгә, Аллаһы Тәгалә диңгезне кире куша һәм фиргавен үз гаскәре белән су астында кала. Бу бәладән котылу хөрмәтенә, Муса галәйһиссәлам шул көнне ураза тота башлый, аның халкы да аңа иярә.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе мондый хәдис тапшыра: «Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдиләрнең Гашурәдә ураза тотканнарын күрде. Ул алардан: «Нәрсә бу?» – дип сорады. Яһүдиләр: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мусаны фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Муса да бу көнне ураза тоткан», – дип җавап кайтардылар. Пәйгамбәребез аларга: «Муса пәйгамбәргә карата минем хокукым беренчелдер (мин лаеклырак)», – дип җавап бирде һәм үзе дә уразага кереп, калганнарга да бу уразаны тотарга кушты», – дип әйткән. Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үрнәк итеп шушы көнне уразада булган. Ул үзенең өммәтен, мөэмин-мөселманнарны, ягъни безне дә бу көндә ураза тотарга өндәгән.[1]

Бу көндә ураза тотуның фазыйләте турында түбәндәге хәдистә дә әйтелә: «Ул үткән ел гөнаһларына йолым булып тора»[2].

[1] Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан, 3397.

[2] Имам Әл-Мөслимнең хәдисләр җыентыгыннан.

Бу көнне төннең кайсыдыр өлешен намазда үткәрергә, гыйбадәттә булырга кирәк. Пәйгамбәребезнең тагын бер хәдисендә болай дип әйтелә: «Рамазан аеннан соң иң яхшы ай – мөхәррам ае; мәҗбүри (биш вакыт фарыз) намаздан һәм төнге намаздан соң, ягъни тәһәҗҗөд намазыннан соң иң яхшысы – Гашурә көнендә укылган намаз»[1].

Нинди көндә ураза тотасы? Имам Әхмәд рахмәтуллаһи галәйһинең хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Гашурә көнендә ураза тотыгыз. Бу эшегездә яһүдиләргә каршы булып, йә бер көн алдан, йә бер көн арттан уразага өстәгез»[2]. Әлеге хәдисләрдән чыгып, шуны әйтергә була: Гашурә уразасын 3 көн тоту хәерлерәк. Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең күңеленә дә туры юлны – һидаять салып, бу тормышта җәмгыятебез өчен дә, кешеләр өчен дә файдалы булып яшәүләребезне насыйп итсен иде. Аллаһы Тәгалә безне бозык, дөрес булмаган, адашу юлларыннан саклап, дөрес юлга, мәгърифәт юлына ирештерсә иде. Аллаһы барчабыздан да разый булсын. Әәмин.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Гайсә хәзрәт Фәрхетдинов,*

*«Шәрәфетдин» мәчете имам-хатыйбы*

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан, 2154.

*20 нче август вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Күрше хакы

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Коръәни Кәримнең «Ән-Ниса» сүрәсендә болай дип әйтелгән:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ﴿٣٦﴾

**«[Ий коллар!] Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага, [бертуганнар һәм агалар кебек] якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә, [нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән] якын күршегә, [нәселдәшлеге яки өе] ерак күршегә, [ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек] янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә игелек кылыгыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Аллаһы Тәгалә, Коръән һәм хәдисләр аша, күршеләргә хәерле мөнәсәбәттә булыгыз, дип әмер бирә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә ышанган кеше күршесенә яхшы мөнәсәбәттә булсын», – дигән.

Чыннан да, янәшәңдәге күршең белән көн саен күрешәсең, кайгы-шатлыкларыңны уртаклашучы да беренче ул булырга мөмкин, йомыш төшсә дә күрше ярдәм итә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өч төрле күрше була, аларның һәрберсенең төрле хокуклары бар», – дип әйткән. Беренчесе – туган булган күршеләребез. Икенчесе – мөселман булган күршеләребез. Өченчесе – туган да, мөселман да булган күршеләребез. Әгәр безгә туган булган мөселман күршебез бар икән, ул кеше өч хакка да ия була. Күршебез мөселман икән, аның каршында ике хакыбыз бар, ә күршедә башка дин кешесе яшәсә, аның каршында күршелек хакыбыз гына кала. Янәшәбездә кем генә гомер итсә дә, Аллаһы Тәгалә аңа карата хәерле мөнәсәбәттә булырга әмер итте. Динебез буенча, әгәр кеше башка диндәге күршесе керткән ризыкның хәләл булуына шикләнми икән, ул керткән күчтәнәчне дә кабул итә. Әлбәттә, үзе дә аны кунак итә, сыйлый ала. Бу күршеләр арасындагы дуслыкны, элемтәләрне ныгытачак кына. Шулай ук бер-береңә бүләкләр бирү дә – күркәм гамәл.

Мәдинә шәһәрендә Пәйгамбәребезнең күршесе яһүди карчыгы булган. Ул гомер буе Расүлебезнең бакчасына чүп-чар ташлаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, күрше хакын хаклап, аның бу начар гадәтенә игътибар итмәскә тырышкан. Бакчадагы чүп-чарны җыештырып, бер чокырга күмә торган булган. Бу хәл озак вакытлар кабатланган. Көннәрдән бер көнне Пәйгамбәребез бакчасының чип-чиста булуын, анда чүп-чарның юклыгын күргән. Шуннан соң ул күршесе өчен эче пошып, аның хәлен белергә кергән. Һәм: «Бүген күренмәдегез, бакчамда чүп-чар юк, борчылып кердем, әллә авырып киттегезме?» – дип йомшак кына эндәшкән. Яһүди карчыгы, үзенең гаебен һәм хатасын танып, Пәйгамбәребезнең искиткеч күркәм холкына сокланып, ислам динен кабул иткән.

Расүлебезнең күршесендә мөселман булмаган кешеләр, мәсәлән, яһүдиләр, насаралар да яшәгән. Ул барысына да яхшы мөнәсәбәттә бул-

ган. Без дә, әйләнә-тирәбездә нинди генә дин кешеләре булмасын, нинди генә телдә сөйләшмәсеннәр, аларга хөрмәт белән карыйк, күрше булганнары алдында хакларыбызны үтик.

Әйе, кешеләр төрле, шуңа да кайвакытларда күршеләрдән гаделсезлек, золым күрергә туры килә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм күршеләреннән авырлыклар, явызлыклар күрсә дә сабыр булды, аларга карата хөрмәтен югалтмады. Үзенә начарлык кылган кешеләргә дә яхшылык белән җавап бирә иде. Мәсәлән, берәү күршесенең бакчасындагы җиләкләрне сорамыйча җыеп чыгып китә икән, бу каралык була. Бу очракта үз бакчаңдагы җиләкне җыеп күршеңә кертеп бирергә мөмкин һәм: «Син башка алай эшләмә, мин сине үзем дә сыйлыйм», – дип, яхшылык белән җавап кайтарсак, Расүлебез сыман, явызлыкка яхшылык белән җавап биргән кеше булырбыз. Безнең яхшылыгыбызны күреп, күршебез үзенең гамәле өчен оялыр, башка сорамыйча бакчабыздан җиләк-җимеш алырга кыймас.

Шулай ук без күршеләребез өчен тәүфыйк, Аллаһының аларны туры юлга күндерүен сорап дога кыла алабыз. Әгәр күрше ялгышлык һәм наданлык белән хаталанган икән, аңа карата игелек күрсәтү, аны гыйлемгә, дингә өндәү, начар гамәлләрнең гөнаһ икәнен аңлату дөрес һәм хәерле булыр. Халыкта: «Кырык йортка кадәр – күрше», – дигән әйтем бар. Шәһәр җирендә күршеләр уң һәм сул якта гына түгел, ә өстә дә, аста да. Әйе, хәдисләрдә уң якта яшәгән күршеләрдән башларга дип әйтелә. Әмма, шәһәр җирендә күп катлы йортларда яшәүчеләр бөтенесе дә күрше булып санала. Кызганыч, еш кына шәһәрдә яшәүче күршеләр бер-берсен танымый да... Хәтта бер-берсе белән бик аралашмый да. Бу – сагайта. Ләкин нишләтәсең? Күршеңә, иң кимендә, елмаеп сәлам булса да бирергә кирәк. Шулчакта Аллаһы каршында аз булса да күрше хакын үтәгән булабыз.

Хәтта: «Өйдә ризык пешергәч, исе таралса, аны күршеләргә дә кертергә кирәк», – дигән хәдис тә бар бит. Пәйгамбәребез: «Күршесе ач

булган хәлдә, үзе тук булып йокларга яткан кеше миңа инанмаган» , – дип әйткән.

Чынлыкта, күршеңнән уңу, аның игелеген күреп, яхшы мөгамәләсен тоеп яшәү – бәхет. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу дөньяның бәхете  дүрт нәрсәдән гыйбарәт: хәерле киң йорт, итагатьле хатын,  яхшы ат (бүгенге заманда бу яхшы машина) һәм хәерле күрше». Әйе, яхшы күрше – ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте вә бүләге!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җәбраил фәрештә миңа күршеләргә карата яхшы мөгамәләдә булу хакында шулхәтле күп сөйләде ки, хәтта мин, мирасымны да күршегә калдырырга тиешмен, дип уйладым»[1]. Күз алдына китерегез, Җәбраил галәйһиссәлам күршесе белән мөнәсәбәтләрнең кирәклеге турында ничә тапкыр хәбәр иткән булган, Пәйгамбәр Исламда күршесенең ни дәрәҗәдә югары икәнен бәяләп, аңа хәтта васыять калдырырга уйлаган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм күршенең берничә хакы бар дип әйткән: «Аңа карата сүз вә гамәл белән игелекле булырга тырыш, хәлен кайгырт; һәрчак ярдәмче бул, серен вә гаурәтен һәрвакытта да сакла. Әгәр дә шатлыгы булса,  аның өчен ихластан сөен,  кайгысы булса, хәсрәтен уртаклаш; кунакка чакырса, аңа җавап бир. Көндәлек тормышта хәлен белеп тор. Авырса, хәлен белергә кер. Бурычка акча сорап тора икән, булдыра алган кадәр биреп торырга, аның ихтыяҗларын үтәргә тырыш. Күршеңә хәерле гыйлем өйрәтүдә ярдәмче бул. Әгәр ул мөселман икән, аның белән мәчеткә барырга, гыйлем алырга тырыш. Бер-береӊ турында һәрчак яхшы уйларга, күршең явызлык кылса, сабыр булырга кирәк. Явызлык белән җавап кайтарма».

Күршеләребез хакында берәрсе гайбәт сөйләсә, аны тыңламаска, башкаларга кушылып сөйләмәскә тиешбез. Күршеләребезгә сәлам бирергә тырышырга кирәк. Вафат булсалар, соңгы юлга озатырга тиеш булабыз.

[1] Имам Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ۚ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ ﴿٣٤﴾

**«Яхшылык белән явызлык тиң түгел. Син [кайбер дошманнарыңнан күргән явыз мөгамәләне күрмәмешкә салышып, яхшылык белән җавап кайтару белән түгел, явызлык кылганга игелек кылу кебек] иң яхшы мөгамәлә белән кайтар, шулвакыт сиңа дошман булган кеше гүяки шәфкатьле бер дус [булыр]»,** – дип әйткән.

«Фуссыйләт / Аңлатылды», 41:34

Раббыбыз динебезнең күркәмлеген, хаклыгын әйләнә-тирәдәгеләребезгә, күршеләребезгә күрсәтеп, күркәм әхлаклы булып яшәүләребезне насыйп итсә иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*

*«Саләх» мәчете имамы*

*27 нче август вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Гыйлем алуда дәвамчылык

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле мөселманнар кардәшләребез! Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәннең иң беренче аяте белән безне гыйлем алырга чакыра:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

**“[Расүлем! Һәрнәрсәне юктан бар итеп] Яратучы Раббың исеме белән [башлап, Коръәнне] укы!”**

«Әл-Галәк / Оешкан кан», 96:1

Тәфсир галимнәре аңлатуынча, бу аятьтәге “укы!” дигән сүз – җирдәге һәм күктәге гаҗәеп матурлыкка, төрле мәхлүкъларга карап фикерлә, уйлан, белем ал дигәнне аңлата. Чыннан да, динебез безне гыйлем алырга, шул гыйлемнәребез белән гамәл кылырга, нәсыйхәтләнергә, фикерләргә, Аллаһыны танырга, аның Рәхмәтен күрә белергә өйрәтә. Уйлап карыйк әле, боларны белгән, ике дөнья турында да фикерли алган кеше белән гафләттә яшәүче бер була аламы?! Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**“Белгән [һәм белгәне белән яшәгән] кешеләр белән [хакны] белмәгән кешеләр тиң була аламы?»**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:9

“Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп”, – дип әйткәннәр. Димәк, нәрсәнедер белмәвебез гаеп булмаска мөмкин, әмма белергә теләмәвебез, гыйлем алуга салкын каравыбыз гаеп эш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Гыйлем алу һәр мөселман өчен фарыз”, – дип әйткән. Күз алдыбызга китерик, без динебез буенча яшәргә телибез дип ниятләдек, ди. Сүз дә юк бу бик зур адым, Аллаһының рәхмәте булып тора. Әмма кылырга тиешле булган гамәлләребезнең рәтен, тәртибен белмәсәк, савап эшлисе урынга, хаталы көе гамәл кылган булмабызмы?! Әлбәттә, ялгышудан куркып кына дин юлына басмау дөрес түгел, билгеле. Әгәр Раббыбызның ризалыгына ирешергә теләп, гамәл-гыйбадәт кылып яшәргә омтылабыз икән, шул гамәлләребез төзек, камил булсын өчен, гыйлем алырга тиеш булабыз. Иң мөһиме ниятебез дөрес булырга тиеш. Гыйлемне без, иң беренче чиратта, кешеләр: “Бу шундый гыйлемле кеше”, – дип әйтсен өчен түгел, гамәлләребезне камил дәрәҗәдә башкарыр өчен алабыз.

Шунысын да белик, әгәр без алган гыйлемнәребез белән башкаларга да файда китерә алсак, монысы тагын да хәерле була. Өйрәтеп калдырган гыйлем өчен бирелгән савап, кеше үлгәч тә, гамәл дәфтәренә язылып барачак. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Кеше вафат булганнан соң, барлык гамәләреннән өзелә, ләкин аның өч төрле гамәле файда китерәчәк. Беренчесе, садакатүль-җәрия, ягъни кеше үлгәннән соң да, файда китерә торган садака. Икенчесе, башкаларга биреп калдырылган белем. Өченчесе, балаларның догалары”.

Бер хәдистә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге сүзләрне әйткәнлеге билгеле: «Кем гыйлем алу юлына басса, Аллаһы аңа җәннәткә алып бара торган юлны җиңеләйтә. Фәрештәләр гыйлем алучы

кешегә кылган гамәленә ризалык белдереп, канатларын җәяләр. Күктәге һәм җирдәге җан ияләре, хәтта балыклар да, гыйлем иясенең гөнаһысын гафу итүне сорыйлар. Галимнең гыйбадәт кылучы (белемсез) кешедән өстенлеге – айның бөтен йолдызлардан да өстен булуы кебек. Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр динарны да һәм дирһәмне дә мирас итеп калдырмадылар, алар бары тик гыйлемне генә калдырдылар. Кем дә кем аны алса, үзенә җитәрлек дәрәҗәдә алган булыр” .

Бу хәдистә гыйлем алучы кешенең фазыйләтләре дә, галимнәрнең Пәйгамбәрләрнең варислары булуы хакында да әйтелгән. Күз алдыбызга китерик әле, нинди зур дәрәҗә икән ул гыйлемгә омтылу, гыйлемле кеше булу! Моннан тыш гыйлем алучы кеше өчен барлык мәхлүкълар Аллаһыдан аны гафу итүен сорап тора, Раббыбыз бу кешегә җәннәткә илтә торган юлны җиңеләйтә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

شَهِدَ ٱللَّهُ أَنَّهُۥ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ وَٱلۡمَلَٰٓئِكَةُ وَأُوْلُواْ ٱلۡعِلۡمِ قَآئِمَۢا بِٱلۡقِسۡطِۚ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ ٱلۡعَزِيزُ ٱلۡحَكِيمُ ﴿١٨﴾

**“Аллаһы, фәрештәләр һәм гыйлем ияләре Аннан башка гаделлек урнаштыручы һичбер илаһ булмаганына шаһитлык итәләр. Ул – [җиңелмәс] Бөек һәм Хикмәт иясе. Аннан башка һичбер илаһ юк”.**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:18

Әлеге аятьтә дә Аллаһы Тәгалә гыйлемнең, гыйлемле кешеләрнең фазыйләте турында әйтә. Бередә Аллаһы Тәгаләгә иман китергәннән соң, бу дөньялыкта ия булган иң кадерле әйберебез – Аллаһы хакында, динебез турында алган гыйлем булуы ассызыклана. Гыйлем – Аллаһының бөек нигъмәте. Ул аны теләгән кешесенә генә бирә. Дөреслектә, пәйгамбәрләрдән соң иң зур дәрәҗәле кешеләр булып, гыйлемгә ия булучылар гына тора. Бу аятьтә фәрештәләрдән соң гыйлем ияләре хакында

искә алынган. Дөреслектә, бу бик зур дәрәҗә.

Габдулла бине Габбас радыяллаһу ганһе: “Галим белән Аллаһыга ышанучы гади кеше арасындагы аерма җиде йөз баскыч. Һәрбер баскыч арасында ат чабып үткән йөз еллык ара”, – дигән.

Гыйлемнең фазыйләте зур. Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә өч төркем кешеләргә шәфәгатьче булыр. Пәйгамбәрләрдән соң галимнәр, ә аннары шәһитләр килер. Шуңа күрә һәрбер мөселман, ничә яшьтә булуына карамастан, бу бөек нигъмәткә ирешүгә омтылырга тиеш. Аңа ирешергә теләгән һәркем өчен Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмен бирә, юлын, гыйлем ишеген ача. Кеше тырышлык куярга гына тиеш.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Шәйтан өчен бер факиһ (шәригать белгече) гыйбадәт кылучы мең кешегә караганда авыррак”. Ягъни үз динен белеп, аны үтәп яшәгән гыйлемле кешене юлдан яздыру, гыйлемгә ия булмыйча гыйбадәт кылып яшәүче мең кешене юлдан яздыруга караганда авыррак. Шуңа күрә Шәригать кешене һәрвакытта да, дини мәсьәләләрдә генә түгел, ә дөньяви сорауларда да гыйлемле булуга  чакыра.

Әмма кеше Раббыбыз күрсәткән дөрес юлны, гыйлем дигән байлыкны алуга караганда, дөнья тормышын күбрәк якын итә. Моның сәбәбе – кешеләрнең Ахирәт тормышына караганда, үтә торган, вакытлыча әйберләрне өстенрәк күрүендә. Бу динебезне, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләне белмәгәнгә күрә. Әгәр адәм баласы үзен Яратучыны бар күңеле белән таныса, Ул җибәргән хакыйкый юлның ике дөнья бәхетенә ирештерүен аңласа башка төрле фикер йөртер иде. Аның өчен гыйлем, Ислам дине сулар һава кебек кадерле булыр иде.

Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә динебезне дөрес аңлап, аны үтәп, гыйлем дигән байлыкның кадерен белеп, ике дөнья бәхетенә ирешүебезне насыйп итсә иде.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*МДНнең Дәгъват бүлеге белгече,*

*“Саләх” мәчете имам-хатыйбы*

*3 сентябрь вәгазе,*
*Мөхәррам аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Сафәр – уңыш ае

Барлык галәмнәрнең Хуҗасы булган, киң рәхмәте илә безне тәрбияләп торган, хата вә кимчелекләребезне гафу итеп безне туры һидаять юлыннан алып барган Аллаһы Раббуль Гыйззәгә ихлас күңелләребездән чыккан хәмед сәналәребез, мактауларыбыз, олуглауларыбыз ирешә күрсә иде. Бөек Илаһыбыз ике җомга арасында кылынган гамәл-гыйбадәтләребезне кабуллардан кылса иде! Барча галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, галәмнәрнең нуры булган, бөек шәфәгатьчебез, сөеклебез, хәбибебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез вә салават шәрифләребез ирешә күрсә иде!

Дөньяда ел исәбен алып бара торган берничә календарьлар бар. Әмма без куллана торганнары икәү: милади һәм һиҗри. Миладины барыбыз да беләбез: гыйнвардан алып декабрьгә кадәр булганнары, икенче төрле кояш айлары дип тә әйтеп булыр иде. Һиҗри айлар турында Аллаһы Тәгалә түбәндәгеләрне әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ ... ﴿٣٦﴾

**“Һичшиксез, Аллаһы хозурында айларның саны Аллаһының күкләрне һәм җирне яраткан көндәге [катгый карарын белдергән] язуында [Ләүхүл-Мәхфүздә] – унике.**

«Әт-Тәүбә», 9:36

Бу барыбызга да мәгълүм: мөхәррам, сафәр, рабигыль-әүвәл, рабигыль-ахыр, җөмәдәл-әүвәл, җөмәдәл-ахыр, раҗәб, шәгъбан, Рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә һәм хаҗ ае – зөлхиҗҗә.

Бу айлар арасында аерылып тора торган харам айлар, ниндидер вакыйгага бәйле айлар һәм, әлбәттә, айларның солтаны – Рамазан ае бар. Без һәр айны көтеп алабыз, чөнки берсендә – Гашурә көне, икенчесендә – Бәраәт кичәсе. Андый кичәләрне гыйбадәттә үткәрергә тырышып, мөселман үзенә күбрәк савап җыеп калырга тырыша.

Шушы айлар арасында сафәр аен да әйтеп үттек. Исламга кадәрге чорда бу айны төрле бәла-казалар ае дип атап йөрткәннәр. “Сафәр” сүзенең мәгънәләренең берсе “сары төскә керү” дип тәрҗемә кылына. Икенче бер фикер буенча сафәр сүзе “исфар” ягъни бушлык сүзеннән чыккан. Исламгача чорда сафәр көз ае булган, бу айларда, гадәттә, гарәпләр өйләрен калдырып, сәфәргә чыгып китә торган булганнар.

Әмма бу айның башка исемнәре дә бар: сафәр әл-мозаффар, сафәр әл-хайр, ягъни уңыш, уңышка ирешү. Бу исемнәр ислам дине килгәч, кешеләрне шушы ай белән бәйле булган уйдырмалардан саклар өчен кушыла.

Чыннан да, исламга кадәр бу айны бәла-казалар ае дип санаганнар. Мөселман кешесе бәла-казаларны ниндидер вакыт, урын белән бәйләмәсә дә, кайбер кешеләрнең аңында андый хорафатлар әле дә урын алган. Кара мәченең юлны кисеп чыгуы әле дә күп кешегә тынгы бирми, буш чиләкле кеше очратсалар, начарны көт тә тор, ә өйдән чыгып кире кайткан кеше, йә көзгегә карый, йә су эчә... Алай эшләмәсәң, “начарны көт тә тор”.

Менә мондый төр хорафатлар динебездә юк, әмма тормышыбыз алар белән әйләндереп алынган. Шул хорафатларның берсе – сафәр аен уңышсыз ай дип уйлау. Аллаһы Тәгалә безне мондый уйдырмалардан ерак кылса иде.

Сезнең кайчан да булса берәр кешегә акча биргәнегез бармы? Ул нәрсә эшли? “Җиргә, идәнгә куй, шуннан алам” – дип әйтә. Әлбәттә, бу кайбер якларда, ниндидер вакыйга белән кереп калган хорафат. Әмма, күп кеше аңа әле дә ышана. Шуның кебек, сафәр ае турында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган кайбер хорафатлары бар. Әйдәгез иң башта аларны карап үтик:

– сафәр ае – бәла-казалар ае;

– сафәр аенда никах укытырга ярамый;

– сафәр аенда килешүләр төзәргә, ниндидер зур эшкә тотынырга ярамый;

– сафәр аенда сәфәр кылырга, ерак юлга чыгарга ярамый.

Танышмы бу хорафатлар, ишеткәнегез бармы? Ә бит аның ише сүзләрне, безгә, имамнарга, еш ишетергә туры килә. “Ике гает арасында никах укырга ярамый, сишәмбе эш башларга, җомга көнне эш эшләргә ярамый” кебек сүзләрне әледән әле ишетеп торабыз.

Кадерле җәмәгать, динебездә боларның берсенә дә урын юк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Авыру кошлар белән, ябалакның кычкыруы белән һәм сафәр ае белән бәйле хорафатларга урын юк”, – дип әйтә. Икенче бер хәдистә ул: “Исламда тәшәүмгә (начар уйлануларга, хорафатларга) урын юк, иң яхшысы булып тәфәүл (яхшыга юрау) тора”, – дип әйткән.

Кадерле җәмәгать, бер айда ниндидер көндә берәр төрле эшнең уңышлы булмавы, ул бу көн белән берничек тә бәйле була алмый. Стакан белән мисалны ишеткәнегез бардыр: стакан үзе начар түгел, аңа нәрсә салуыгыз сездән тора. Кеше су салса, бу яхшы, кеше харам берәр нәрсә салса, бу начар. Әмма стакан үзе гаепле түгел. Шуның кебек, көннәр дә безнең гамәлләребездән генә тора. Начар көн була аламы? Ала! Бу – кешенең Аллаһы Тәгалә турында оныткан көне, гөнаһ кылып үткәргән көне. Шулай ук кешенең яхшы көне дә була ала – бу Аллаһы Тәгаләне гел

искә алып, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып үткәргән көне. Аллаһы Тәгалә «Әш-Шура» сүрәсенең 30 нчы аятендә болай дип әйтә:

وَمَا أَصَابَكُم مِّن مُّصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُو عَن كَثِيرٍ ﴿٣٠﴾

**“Сезгә килгән һәр бәла – кулларыгыз казанган [начар] нәрсәләр сәбәпле. Ул бик күбен гафу итә [һәм аларга җәза бирми, шулай булмаса, җир йөзендә һичбер җан иясен калдырмаган булыр иде]”.**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:30

Димәк, күп кенә бәла-каза ниндидер хорафатларга бәйле булмыйча, безнең кулларыбыз аркасында, ягъни кылган гөнаһларыбыз аркасында да килә. Шуның турында онытмыйча, Аллаһыдан туры юлдан алып баруын, шушы юлда ныклык бирүен һәм төрле имеш-мимешләргә “бирешмичә” яшәргә насыйп булуын сорыйк. Аллаһы Тәгалә барчаларыбызны Үзенең яраткан колларыннан кылса иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы имам-хатыйбы*

*10 нчы сентябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Садакалы һәр көн…

Барлык галәмнәрнең Хуҗасы булган, Үзенең киң рәхмәте белән безне тәрбияләп торган, хата вә кимчелекләребезне гафу итеп безне туры һидаять юлыннан алып барган Аллаһы Раббуль Гыйззәгә ихлас күңелләребездән чыккан хәмед-сәналәребез, мактауларыбыз, олуглауларыбыз ирешә күрсә иде. Бөек Илаһыбыз ике җомга арасында кылынган гамәл-гыйбадәтләребезне кабуллардан кылса иде! Барча галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, галәмнәрнең нуры булган, бөек шәфәгатьчебез, сөеклебез, хәбибебез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез вә салаватшәрифләребез ирешсә иде!

Газиз мөэмин мөселман кардәшләрем, бүгенге җомга вәгазебез, иншәАллаһ, садаканың фазыйләтенә вә аның файдаларына багышланачак. Һичшиксез, ул хәерлегә вә бәхеткә ирештерә торган капка булып тора. Садака – Аллаһы Раббыбызның ризалыгына, бу дөнья вә Ахирәт хәсәнәтенә (яхшылыгына) ирештерә торган туп-туры юл ул. Чынбарлыкта, садака ул кешенең иманлы булуына дәлил (борхан) булып тора. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака бирү – иманның дәлиле», – дип әйткән. Ягъни садака бирүче кеше, ошбу гамәле белән үзенең Аллаһыны вә Аның динен яратуын исбатлап тора.

Садака – ул малның, байлыкның артуына сәбәпче, төрле чирләрдән, афәтләрдән, кешеләрнең мәкерлекләреннән калкан була торган бөек гыйбадәт. Аллаһы юлында хәләл малын биргән бәндә, Кыямәт көнендә җәннәткә «Садака» капкасыннан керәчәк, иншәАллаһ.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә болай дип әйткән: «Җиде төркем кеше Гареш күләгәсе астында булыр. Шуларның берсе – ихлас күңелдән яшерен садака бирүче».

Садака хаталардан вә гөнаһлардан пакьләнү ысулы булып тора, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Су утны юк иткән кебек, садака хаталарны юк итә», – дип әйткән.

Садака – авыруларның дәвасы. Сөекле Расүли Әкрам болай дип әйткән: «Байлыгыгызны зәкят белән пакьләгез, авыруларны садака белән дәвалагыз».

Садака җәһәннәм утыннан пәрдә, саклану булып тора. Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәгә Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтеп калдырган: «Йә Гайшә! Җәһәннәм утыннан хөрмәнең яртысы белән булса да сакланыгыз».

Шулай ук, садака бирүче кабер газабыннан имин булыр, иншәАллаһ. Расүлебезнең хәдисендә «Садака бирүче кабер газабыннан имин булыр», – дип әйтелә.

Расүлебез, Аллаһының изге юлында малларын бирүчеләр Кыямәт көнендә ошбу садаканың күләгәсе астында булырлар, дип хәбәр итә. Һичшиксез, садакага юмарт кеше үзенең малында, байлыгында бәрәкәт күрәчәк, чөнки садака малны киметми, ә, киресенчә, арттыра гына. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Садака малны киметмәс, кол, Аллаһыдан гафу үтенгән саен, гыйззәткә генә ирешер, түбәнчелек күрсәткән саен мәртәбәсе артыр».

Садаканың төрле төрләре бар, иң әүвәл садака якыннарыңа: гаиләңә, туганнарыңа, якыннарыңа, күршеләреңә бирелә, аннары мохтаҗ мөэминнәргә тапшырала.

Садака дигәндә, акча, матди ярдәм итү генә күз алдында тотылмый. Акчасы, мөмкинлеге булмаган мөселманнар да садака бирү әҗеренә ирешәләр: хәтта үз кардәшеңне күргәч, аңа ихлас күңелдән елмаю да

садаканың төрләреннән булып тора. Пәйгамбәребез: «Һәрбер изгелек – садака, кардәшеңә елмаю да садака булып тора», – дип әйткән.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә алдында белгән вә белмәгән мөэмин-мөселманнарга сәлам бирү, кешеләргә зарар китергән әйберләрне юлдан алып кую, авыру кешеләрнең хәлен белү, аларның хәлләрен җиңеләйтү, алар өчен дога кылу, хәтта адашкан кешегә дөрес юл күрсәтү дә садака булып тора.

Хөрмәтле җәмәгать, кадерле дин кардәшләрем! Үзебезне дә, бездән соң килгән бала-оныкларыбызны да садака бирүчеләрдән булсыннар дип тәрбиялик.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

لَنْ تَنَالُوا الْبِرَّ حَتَّىٰ تُنْفِقُوا مِمَّا تُحِبُّونَ ۚ وَمَا تُنْفِقُوا مِنْ شَيْءٍ فَإِنَّ اللَّهَ بِهِ عَلِيمٌ ﴿٩٢﴾

**«Үзегез ярата торган [мал һәм җан кебек] нәрсәләрдән [Аллаһы юлында] сарыф итми торып, сез изгелеккә [ягъни игелекнең иң камил ноктасына һәм Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына] ирешә алмаячаксыз. [Күңелегезгә хуш килгән яки килмәгән] Нәрсәне [генә] сарыф итсәгез дә, һичшиксез, Аллаһы – аны Белүче».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:92

Аллаһы Раббыбыз ил-көннәребезне тыныч кылсын, барчабызга да бәхет-шатлык, ике дөнья хәсәнәтенә ирешүләрне насыйп итсен!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Сәүбәнов,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы*

*17 нче сентябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Ислам – тынычлык дине

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әмма бәгъде: барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде. Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, аның сөекле Расүле Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез.

Аллаһы Тәгалә Үзенең сөекле пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә болай дип әйтте:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ ﴿١٠٧﴾

> **«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Бу аять – Исламның тынычлык дине булуына меңләгән дәлилләрнең берсе: динебезне пычратырга, аны үзенең мәкерле максатларында кулланырга теләүчеләргә Аллаһы Сүзләре белән җавап. Адәм баласы әллә нинди бормалы җөмләләр төзи, шигырьләр уйлап чыгара ала, әмма аларның берсе дә Раббыбыз әйткәннән өстен булмас. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәренә

нинди бурыч билгеләгәнен Үзе аңлатып бирә. Әлеге аятьтә: «Рәхмәт итеп җибәрдек», – дип әйтә. Ләгънәт, михнәт, җәза итеп түгел. Рәхмәт итеп! Пәйгамбәр Җир шарына рәхмәт итеп, ягъни рәхим-шәфкать таратучы итеп җибәрелгән икән, димәк, аның аркылы иңдерелгән дин дә игелек дине булып чыга. Игътибар итегез: искә алынган шушы аятьтә «Мөселманнар өчен рәхмәт итеп», – диелми, ә, «Бөтен галәмнәр өчен рәхмәт итеп», – дип әйтелә. Ислам динен үзләренең пычрак эшләрендә куллана торган агымнар йогынтысына бирелгән бәндәләр шушы бер аятьне генә булса да искә алсын иде. Үзләренең хак дингә түгел, шәйтанга хезмәт итүләрен аңласын иде. Ничек инде: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне яратабыз», – диясең дә бер гаепсезләрнең каннарын коярга чыгып китәсең?! Шул буламы рәхмәт итеп яратылган Пәйгамбәр сөннәтен саклау?! Шул буламы тынычлык сагында тору?!

Асылда, динебезне канга батырырга теләүчеләр Коръәнне дә белми, Сөннәтне дә танымый. Аларның максаты бер – Ислам дине хакыйкате артына яшеренеп, үзләренең явыз максатларына ирешү. Меңләгән, миллионлаган кешеләрне юк итәсе булса да, алар туктап калмас. Аларга карап, мөселманнарга яла ягылыр, дин турында яман фикер формалашыр. Шуларга ияреп, үзләрен мөселман дип санаучылар диннән дә чыгып китәр, җәһәннәмгә дә килеп керер. Үзләре шуны аңламый да калыр.

Коръәни Кәримнең «Әл-Каләм» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә Расүлен янәдән күркәм рәвештә сыйфатлый:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе. [Олуг пәйгамбәрләр кебек, син дә чыдый алмаслык михнәтләрне кичерәсең]».**

«Әл-Каләм», 68:4

Уйлап карыйк әле. Кемдер безне бергә уртак эш башларга чакыра. Йә ерак сәфәрдә юлдаш булырга тәкъдим итә. Әлбәттә, без ул кеше турында аны

белгәннәрдән сорашачакбыз. Аның элекке эшләре турында белешәчәкбез. Шунда берәрсе безгә: «Ул – ышанычлы кеше, холкы да бик күркәм, югары әхлаклы», – дисә, ахыргы нәтиҗә ясар өчен безгә бу мөһим бер сәбәп булачак. Әхлаклы булгач, димәк, бергә эш башласак – алдамас. Юлга чыгып китсәк – ташлап калдырмас. Ә бу очракта бит Аллаһы Тәгалә пәйгамбәр турында Үзе әйтә. Шулай булгач, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша килгән дин дә югары әхлак дине булып чыга бит. Югары әхлак белән вәхшилек берничек тә янәшә була алмый. Кемдер яманлык кыла да: «Дин шулай куша», – дип әйтә икән, белегез: сезнең каршыгызда сезне хак юлдан тайпылдырырга тырышучы тора, чөнки Ислам дине һәрчак тынычлык яклы. Ислам дине һәрвакыт иминлек сагында. Мөселман кешесе беркайчан да үзенең явызлыгын, кара йөрәклелеген дингә сылтап калдырмый. Мөселман өчен иң зур үрнәк – Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Ул – югары әхлак иясе. Ул бөтен галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән. Һәм аны үрнәк итеп алучы мөселманнар да һәр мизгелдә шундый булырга омтыла. Үтерергә, юк итәргә, җимерергә түгел, ә коткарырга, ярдәм итәргә, төзергә, төзекләндерергә, матурлатырга.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә: «Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем»[1], – дип әйткән. Аның вафатыннан соң: «Расүлебезнең холкы нинди иде?» – дигән сорауга Гайшә анабыз радыяллаһу ганһә: «Аның холкы – Коръән иде», – дип җавап биргән. Ягъни ул Коръән кушканны үтәгән, Коръән тыйганнан читләшкән. Хәзер уйлап карыйк әле: бүген үзен мөселман дип атап, үзе яманлык кылучының холкы – Коръәнме? Дин кушканча яшиме ул, әллә шәйтан боерганчамы? Һәм динне байрак итеп алып, вәхшәт кылучы шәригатьчә эш итәме? Җаваплар аңлашыладыр.

Сәхабәләрнең берсе, Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Мин Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ун ел

[1] Имам Әхмәд бине Хәнбәл, Мөснәд.

хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: «Бу эшне ник болай эшләдең?» – дип ачуланганын күрмәдем»[1].

Асылда, хөрмәтле дин кардәшләрем, мөселманны адаштырырга, ялгыш юлдан алып китәргә, «хак дин шушы, син иярергә тиеш» дип бутарга тырышучылар һәрвакыт булган һәм ахырзамангача булачак. Дәҗҗал фетнәсен күрү насыйп булмасын. Әмма вак фетнәләр безне һәр көнне сагалап тора. «Намазны дөрес укымыйсың», «Динне дөрес тотмыйсың», «Садаканы дин юлына тапшырмыйсың», «Дин өчен иҗтиһад кылмыйсың» кебек шигарьләр белән мөрәҗәгать итәләр икән – сак булыгыз! Әнәс бине Мәлик искә алганча, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да: «Бу эшне ник болай эшләдең?» – дип ачуланмаган. Ә үзләрен аеруча тәкъва булып күрсәтергә теләгән, шул рәвешле динне пычраткан, мөселманнарны адаштырган бәндәләр гел тәнкыйтьләргә генә торалар. Һәм күңелебездән беркайчан да шуны чыгармыйк: Аллаһы Расүле рәхмәт итеп җибәрелгән. Һәм һәрбер мөселман – аның бу изге эшен дәвам иттерүче, рәхим-шәфкать сагында торучы.

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

*24 нче сентябрь вәгазе*

*Сафәр аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# Теленнән дә, кулыннан да зарар килмәгән зат…

Барча галәмнәрнең Раббысы, тәрбиячесе, яратучысы булган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез ирешсен. Шулай ук йөрәкләребезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез, юлбашчыбыз, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешсен. Хөрмәтле мөселманнар, шушы изге җомга көне белән сезне тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә барчагызга да күңелләрегездәге изге ният, морад-максатларыгызга ирешергә насыйп әйләсен. Күңелләребездә булган барча начар сыйфатларыбыздан арынырга насыйп итсен. Безләрнең бүгенге көнебезне кичәгеләреннән, иртәгесе көннәребезне бүгенгесеннән хәерлерәк кылса иде.

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Бүгенге вәгазебез «Теленнән дә, кулыннан да зарар килмәгән зат…» дип атала.

Белгәнебезчә, әлеге сүзләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә китерелә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман кешесе – башкаларга кулы белән дә, теле белән дә зарарлык итмәгән заттыр», – дип әйткән.

Әйе, чыннан да, бик уйландыра торган сүзләр. Без барыбыз да үзебезне мөселман дибез. Намаз укыйбыз, рузасын да тотабыз. Әмма еш кына кемнедер йә кулыбыз, йә телебез белән үпкәләтергә, кимсетергә мөмкинбез, шул рәвешле, кемнеңдер хакына керүебезне сизмичә дә калган чакларыбыз бар. Җан ияләре күп бит, монда сүз кешеләр хакында гына бармый. Без барлык җан ияләре өчен дә җавап тотачагыбызны

онытмыйк. Мөселман кешесе – Аллаһыга буйсынган дигәнне аңлатадыр. Әгәр Аллаһы Тәгалә тыйганны эшләп, Аны ачуландыра торган гамәл кылабыз икән, димәк, без гамәлебез белән ул кысалардан чыгабыз. Ә начар гамәлнең эзе каладыр, кардәшләрем. Бер галим болай дип әйткән: «Гөнаһыбызны Аллаһы кичерер, ләкин ояты калыр, оятын кая куярбыз?»

Хөрмәтле дин кардәшләрем, динебездә гыйлем бик мөһим, ә наданлык бик начар. Ләкин аннан да яхшырагы, мөһимрәге – ул әдәп. Тәрбия – кечкенәдән сеңәргә тиешле нәрсә. «Әдәпле надан тәрбиясез галимнән хәерлерәк», – диләр, кардәшләрем. Әдәп һәр нәрсәдә дә кирәкле. Кая гына барма, әдәпле булу хуштыр. Мөселман кешесе, ягъни Аллаһыга буйсынган, башкаларга зарар китермәүче кеше – әдәпле кешедер. Әдәп иң элек Аллаһыдан оялуга өйрәтә. Шулай ук башка мәзһәбтәге кардәшләрне дә, галимнәрне, хәтта гади фәкыйрьләрне дә хөрмәт итәргә, олыларны олы, ә кечеләрне кече итәргә өйрәтә. Шуңа да, Ислам динебезнең тамырында әдәп ята.

Көннәрдән бер көнне Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләргә болай дип әйткән: «Кем дә кем Аллаһыга вә Кыяմәткә иман китергән булса, сүз сөйли икән, хәерлесен генә сөйләсен йә тик торсын; кем дә кем Аллаһыга вә Кыямәткә иман китергән булса, күршесенә зарар салмасын; кем дә кем Аллаһыга вә Кыямәткә иман китергән булса, кунагын икърам кылсын, кадерләсен». Күрәсезме, хөрмәтле кардәшләрем, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иманны күркәм холык белән бәйли.

Хәдиснең икенче өлешендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иманың булса, күршегә зарар салучы булма», – дип әйткән. Димәк, Ислам дине – ул, иң беренче чиратта, күршене дә рәнҗетмәү. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бик мәшһүр сорауга җавабын хәтеребезгә төшерик әле. Берәү аннан болай дип сораган: «Бер хатын бар, ул нәфел намазлар укый, нәфел уразалар тота, тик күршеләре аннан имин

түгел, ул аларга зарар сала». Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Ул хатында һичбер хәерлелек юктыр, ул – җәһәннәмдә». «Ә берсе фарыз булган гыйбадәтләрен генә кыла, тик күршеләре аңардан сәламәт, имин булдылар», – дигәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул – җәннәттә», – дип җавап биргән. Раббыбыз кодси хәдистә болай дип әйтә: «Әгәр бәндәм миңа карата гөнаһ кылса, соңра үкенеп тәүбә итсә, мин аны кичерәм, әгәр икенче бер колымны рәнҗетсә, рәнҗетелгән бәндәмнән гафу сорамыйча, мин аны кичермәм».

Кардәшләрем, золымлык кылу – бик зур югалту. Шуңа, гаепләргә, уйламыйча артык сүз әйтергә ашыкмагыз.

Теленнән дә, кулыннан да зарар килмәгән зат – кем соң ул? Әлеге гыйбарәнең мәгънәсе тирәнрәк, кардәшләрем, чөнки башкаларга золымлык итсәң, үзеңне өстенрәк куйдың дигән сүз. Бу гамәл безнең намазыбызны да шик астына куядыр. Кодси хәдистә Аллаһы Раббыбыз болай дип әйтә: «Дөреслектә, тәкәббер булмаган, гөнаһ кылуда дәвамчылык кылмаган, рәхимле булган кешенең генә намазын кабул кылырмын». Ә залим кеше рәхимлеме? Үзен өстенрәк куеп, ул тәкәббер булмыймы? Залимлыгында дәвамлы булырга мөмкинме? Юкка гына, намаз безне начар эшләрдән саклый, дип әйтелмәгән. Намазларыбыз кабул булсын өчен, намаз араларында булган вакытыбызда да нинди гамәлләр кылуыбызга игътибар итик. Мөселман – бөек исем, үзеңне мөселман дип таныйсың икән, ул исемне таплама, ваклама.

Аллаһы Раббыбыз ошбу вәгазебездән разый булып, алган гыйлемнәребезне файдаланырга, күңелләребездәге барча начар сыйфатлардан арынырга насыйп әйләсен. Чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып яшәргә вә чын мәгънәсендә мөселман кешесе булып, Аллаһы Раббыбыз хозурына күчәргә насыйп итсен. Әәмин.

***

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Динар Зыятдинов,*

*«Азан» радиосы редакторы*

*1 нче октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1443 ел*

# «Олыларны хөрмәт итмәгән бездән түгел»

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхаабиһи әҗмәгыйн. Әлхәмдү лилләәһи раббил гааләмиин. Галәмнәрнең бердәнбер Раббысы булган, аннан башка илаһ булмаган Затка, барлык мәхлүкъларның Яратучысына, җирләрнең һәм күкләрнең Хуҗасына хәмед-сәналәребез булсын.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: «Кече яшьтәгеләргә карата рәхимле булмаган һәм бездән олырак булганнарны хөрмәт итмәгән кешеләр бездән түгел». «Бездән түгел», ягъни мөселман булган кеше алай эшләмәс, андый гамәл кылмас, дигән сүз. Бу хәдис өлкәннәргә карата ихтирамы булмаган кешенең никадәр түбән булуын күрсәтә. Ошбу хәдистән аңлашылганча, бүгенге вәгазебез бик хикмәтле кешеләр – өлкәннәребез турында булыр.

«Үткәнне белмәгәннең – киләчәге юк», – дип юкка гына әйтмәгәндер халык. Ә үткәнне иң яхшы белгән кешеләр – ул безнең өлкән буын кешеләребез. Нибары 10-20 ел эчендә без фәнни яктан бик алга киттек, яшәү дәрәҗәбез дә үсте. Өстәлләребездә нинди генә ризыклар юк. Бер ун ел элек туган бала өчен бу гадәти хәл булып күренәдер дә. Аякларына кәттә матур кроссовкилар кигәндә, кайчандыр бу киемнәрнең булмаганын күз алдына да китереп карамыйдыр. 1932 елгы әби белән сөйләшеп тордык: «Ий, балам, башта үргән чабатадан йөрдек, бераз яхшылана төшкәч, күрше

абый шул чабатаның астына киез салып бирде: асты озаккарак җитә башлады, озаграк киелә торганга әйләнде. Аннан соң эчсез галошлар чыкты, аннан соң эчлеләре чыга башлады...», – дип сөйләде. Шушы сөйләшүдән соң, нинди тарихи чор артта калып бара икән, дип уйлап куйдым.

Өлкәннәрне хөрмәт итү динебезнең гомум бер кагыйдәләреннәндер. Без олы кешеләрне, аларның кем булуына карамастан, хөрмәт итәргә, аларга карата яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә кешене көчсез итеп яратып, урта яшьләргә аңа күп көч бирә. Әмма, яше арта барган саен, ул көч кире китә. Кеше сабый чагындагы кебек күп нәрсәне аңламый башлый, йөри алмый, куллары тотмый һ.б.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

ثُمَّ يُخْرِجُكُمْ طِفْلًا ثُمَّ لِتَبْلُغُوٓا۟ أَشُدَّكُمْ ثُمَّ لِتَكُونُوا۟ شُيُوخًا ۚ وَمِنكُم مَّن يُتَوَفَّىٰ مِن قَبْلُ ۖ وَلِتَبْلُغُوٓا۟ أَجَلًا مُّسَمًّى وَلَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ ﴿٦٧﴾

**«Шуннан соң сезне [аналарыгызның карыныннан] бала хәлендә чыгара. Шуннан соң [куәт, акыл һәм танып белү мәсьәләсендә] көчле чагыгызга [унсигез-утыз яшь арасына] ирешүегез өчен, шуннан соң картлар булуыгыз өчен [сезне яшәтә]. Арагыздан [картлыгына җитәр-җитмәс яки] моннан алда [куәтле чагына ирешкәннән соң яки әле бала чагында ук] вафат булганнар да бар. Сез билгеләнгән бервакытка ирешүегез өчен, һәм дә [туфрак, су тамчысы, оешкан кан кебек төрле хикмәтләрне] аңлавыгыз өчен».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:67

Бу – Аллаһы Тәгалә куйган тәртип, һәм моңа каршы барып булмый. Юкка гына Пәйгамбәребез: «Картлыктан һәм үлемнән дәва юк», – дип әйтмәгәндер. Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән кешеләр урта яшьләрне узып, картлыкка ирешәләр. Ә алар турында кайгыртуны Пәйгамбәребез безгә –

яшьләргә, урта буын кешеләренә йөкләде.

Бервакыт имам булып баскан Мөгаз исемле сәхабә намазны озаграк укыта. Намаз тәмамланганнан соң, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Дөреслектә, синең артыңда өлкәннәр дә, көчсез-хәлсезләр дә, ихтыяҗлары булган кешеләр дә намаз укый», – дип әйтә. Ягъни өлкән кешеләрнең озак басып торырга хәлләре булмаска, аяклары авыртырга мөмкин, шуңа күрә имам кеше моның турында беркайчан да онытмаска тиеш. Юкка гына безне кечкенәдән олыларга урын бирергә өйрәтмиләрдер. Метро-автобусларга кергәч тә, өч телдә олыларга, авыру кешеләргә урын бирергә тәкъдим иткән аудиоязмаларны ишетеп була. Әмма безнең тәрбиябез бу аудиоязмалар булмаса да, бу эшләрне үтәргә этәрергә тиеш.

Расүлебез олыларга хөрмәтен күрсәтеп: «Намаз вакыты кергәч, берәрегез азан әйтсен, ә иң олыгыз имам булсын», – дип әйткән. Хәтта сәлам бирүнең дә үз әдәбе бар икәнен беләбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кече яшьтәгеләр – өлкәннәрне, бара торган кеше – утырып торучыны, кече төркем зуррак төркемне сәламли», – дип әйткән.

Юкка гына кешенең нәселен агач белән чагыштырмыйлар. Безнең халыкта «нәсел шәҗәрәсе» дигән гыйбарә дә йөри. Агачның тамырлары, кәүсәләрендә бабаларыбыз тора. Ә балалар, гадәттә, агачның яфракларына языла. Уйланып алыйк әле: әгәр дә агачның тамырына зыян килсә, корыса, ул очракта нәрсә булыр иде? Ул агач корый, яшәүдән туктый! Без, яшь буын дөрес, матур, тыныч яшәсен өчен, үзебезнең тамырыбызны белергә, аны саклап тотарга тиешле түгелме соң? Пәйгамбәребез, диненә, фикер юнәлешенә карамастан, олы кешене хөрмәтләргә куша. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Картлыкка ирешкән кешене хөрмәтләгән яшь кешегә Аллаһы Тәгалә аның картлыгында да хөрмәт итүчене билгеләр», – дип әйтә. Хәдистә, олы мөселман кешесен, дип тәгаенләп әйтмәгәч, без бу хәдисне гомум кагыйдә була-

рак куллана алабыз, ягъни һәрбер олы кешене хөрмәт итәргә, дип кабул итәбез.

Олы кешеләргә Аллаһы Тәгалә Үзе дә кайбер җиңеллекләрне биргән. Аллаһы Тәгалә: «Шуннан соң картлар булуыгыз өчен [сезне яшәтә]», – дип әйтә. Әмма шул ук вакытта көче, хәле булмаган кешегә ураза тотмаса ярый. Олы кешенең хәле булмаса, ул хаҗга да үзе урынына башка бер кешене җибәрә ала. Аллаһы Тәгалә һәр кешегә Рәхимле, Шәфкатьле.

Әмма кешенең картлыгына карап, аның дәрәҗәсе һич кимеми. Яшь балалар шәригать хөкемнәрен балигълыкка ирешкәч кенә кылырга тиеш булса да, картлыкта шәригать хөкемнәрен үтәмәскә ярый торган андый яшь юк.

وَٱعْبُدْ رَبَّكَ حَتَّىٰ يَأْتِيَكَ ٱلْيَقِينُ ﴿٩٩﴾

**«Киләчәгенә һич шик булмаган [үлем дигән] нәрсә сиңа ирешкәнче, [бер мизгелне дә бушка уздырмыйча] Раббыңа [һәрдаим] гыйбадәт кыл».**

«Әл-Хиҗр», 15:99

Безнең өчен әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз иң якын өлкән кешеләр булып тора. Әти-әнинең балаларын яратулары, аларга карата җылы мөнәсәбәтләре Аллаһы Тәгалә тарафыннан салынган инде. Әмма бала һәрвакытта да әти-әнисенә карата җылы булмый. Коръәндә болай дип әйтелгән:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِنْدَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُلْ لَهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُلْ لَهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا﴿٢٣﴾ وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُلْ رَبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا﴿٢٤﴾

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек [кылырга] әмер итте. [Ий кеше!] Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсә, аларга [канәгатьсезлек белдереп]: «Уф!» – дип тә әйтмә. [Сүзгамәлләре сиңа ошамаса да] Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт. Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]: «Ий Раббым! [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] Алар кечкенә чагымда мине [зур бер шәфкать белән] үстергәннәре кебек, Син дә аларга [бакый рәхмәтең белән] мәрхәмәт ит», – дип әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23-24

Аллаһы Тәгаләгә табыну әмере янында әти-әниләргә игелек кылу әмере дә бар. Аллаһы Тәгалә бу вазифаны югары күтәрә. Әти-әниләребезгә карата йомшак булу, аларны ярату – ул үзе бер гыйбадәт. Безнең әти-әниләребез үзләре начаррак тормышта яшәсә дә, «Безгә булмады инде, балаларыма булсын», – дип күпме тырышалар. Үзләре ямаулы кием киеп булса да, безгә яңадан-яңа кием алырга тырышкан кешеләр бит алар. Югарыда искә алган әбинең сүзләре искә төшә дә, өлкән кешеләргә карата хөрмәт тагын да арта гына.

Ата-бабаларыбыз шундый авыр заманаларда да кешелек сыйфатларын югалтмаганнар, динебезне саклап калып, безнең буынга алып килеп җиткергәннәр. Үзләренең өсләрендә булган югары әманәтне үтәп, безгә тапшырганнар. Бар әйбер дә булган заманда хакыйкый кыйммәтләрне саклап калу авыррак булса да, динебезгә ныклап ябышсак, кемнәрне хөрмәт итәргә, ни рәвешле яшәргә кирәклеген күрә алырбыз. Олылар турында кайгырту безнең өчен бәхет булырга, рухи яктан үсеш булырга тиеш. Без олылар өчен тагын бер пансионат ачтык дип түгел, ә аларның ябылуына шатланырга тиешбез. Әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның урын-

нары өйләребезнең түрләрендә булырга тиеш бит. Кеше яше арткан саен йомшак күңеллерәк була, авыр сүзләрне йөрәкләренә тагын да якынрак кабул итә торганга әйләнә. Без һәрвакыт аларның фатихасын алырга омтылырга, алар белән киңәшләшеп эш йөртергә тырышырга тиешбез. Өлкән буын кешеләре бәрәкәтнең югалмавына бер сәбәп икәнен онытмасак иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә карт кешеләр, сабый балалар һәм болыннарда көтелгән маллар булмаса, сезгә иге-чиге күренмәгән бәлаләр килер иде», – дип әйтеп калдырган.

Һәм онытмагыз: без өлкәннәргә нинди мөнәсәбәт күрсәтсәк, картаймыш көннәребездә безне дә шундый ук мөгамәлә көтә. Аллаһы Тәгалә барчаларбызга да рәхмәтен, шәфкатен бирсә иде. Әәмин!

* * *

Фузаил бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

# Әңгәмә

# «Татар теле хакында бервакытта да шигем булмады»



*Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан, без татар теленең бүгенге хәле һәм аның киләчәге хакында сөйләшеп алырга булдык. Бүгенге әңгәмәдәшебез – Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, диктор Фоат Галимуллин.*

## «Үзебезнең Эльс Гаделев»

**– Фоат абый, Сезнең хакта сүз чыгуга, беренче чиратта, укытучы, профессор түгел, «Татарстанның алтын тавышы» булып күзалланасыз. Дикторлык хезмәтегез нидән башланды?**

– Ул үзеннән-үзе, көтелмәгәндә булды. Әле армиягә кадәр Кукмарада театр коллективын җитәкләдем. Көннәрдән бер көнне мәдәният йортына өстәл кадәр магнитофон кайтардылар. Гадәти магнитофон юк вакыт, ә монда зур, профессиональ аппаратура. Коллектив шул магнитофонга җырлар, аудиоспектакльләр яздыра башлады. Берсендә Галимҗан Сәгыйдуллинның «Тамырлар» әсәре буенча куелган спектакль, уңышның нәрсәгә бәйле булуы, режиссёр буларак, нинди максатлар куелуы турында сөйләргә тәкъдим иттеләр. Сөйләдем. Соңыннан язманы тыңлаучылар: «Казанда «Татарстан» радиосында Эльс Гаделев дигән диктор бар. Синең тавыш тембрың анықы кебек икән. Сиңа да диктор булырга кирәк», – диделәр. Җырлап йөреп танылу алып өлгергән идем инде. Ә менә сөйләм мәсьәләсендә тавышымның нинди дер сәнгатьчә әһәмияте

турында бернинди дә хәбәрем юк иде. Җырлаганда тенорга тыртымрак җырлыйм, ә сөйләгәндә, үзеннән-үзе баритон тавыш белән сөйли башлыйм. Әле баритонның да түбәнрәк рәвеше. Менә шул магнитофон язмасы ярдәмендә аңладым да инде тавышымның аермасын һәм үзенчәлеген.

Соңрак Кукмара радиоузелы аша җирле тапшырулар оештыра башладылар. Мәдәният йортында эшләгән кеше булганга, тапшыруларның берсен алып барырга сорадылар. Беренче тапшыру чыккач та, «Үзебездә дә «Татарстан» радиосында кебек дикторларыбыз бар икән», – дип шалтырата, яза башладылар. Шул рәвешле, ике ел Кукмара радиоузелы аша атнага 1-2 тапкыр эфирга чыгып килдем.

## «Без бит сине ничә елдан бирле эзлибез!»

– 1967 елда армиядән кайткач, Рәсәй күләмендә Совет хакимиятенең 50 еллыгына багышланган фестиваль уздырылды. Кукмара вәкиле итеп Казанга җибәрделәр. Ә Казаннан 3 кешене Рәсәй фестивalенә сайлап алдылар: сопрано тавышлы консерватория тәмамлаган профессиональ җырчы – Әлфия Борнашева, Минзәлә ягыннан Кәбир Нигъмәтҗанов һәм мин. Җырлау культурасын яхшырту өчен, Кукмарадагы эштән аерып, Казанга Консерваториягә вокал буенча дәресләргә чакыртып алдылар. Тавыш кую буенча укытучы, профессор Зөһрә Бәйрәшева кул астында 4 ай укыдым: тавыш куярга, җырлаганда тавышны, сулышны дөрес файдаланырга өйрәттеләр. Әлеге курсның файдасы бик зур булды. Куйбышев (хәзерге Самара – ред.) шәһәрендә узган Рәсәйкүләм фестивальдән югары дәрәҗәле диплом белән кайттым.

Фестивальдән соң 1-2 җырны яздырырга, фестиваль, хис-кичерешләр турында сөйләргә дип радиога чакырдылар. Студиягә кердем дә сөйли башладым. Фәүзия Бурнашева «Туктагыз!» дип мине туктатты да, студиядән чыгып йөгерде. Бераздан унбишләп кеше җыеп керде. Барысы да оператор янына утырып, тәрәзә аша гына безне күзәтә башла-

ды. Фәүзия апа белән әңгәмә тәмамлангач, карап утыручыларның берсе – мәһабәт гәүдәле, күзлекле ир-ат, студиягә кереп мине кочаклап алды да: «Кайда йөрисең син? Без бит сине ничә елдан бирле эзлибез!» – диде. Менә шуннан профессиональ диктор итеп эшкә чакырдылар. 5 ай эчендә фатир да бирделәр, хәтта.

**– Телгә карата мәхәббәт дикторлык эше белән бәйлеме?**

– Ул мәхәббәт бар иде инде. Татар теле һәм әдәбиятына карата минем беркайчан да шигем булмады, чөнки татар мохитендә үстем. Ләкин татар теленең мөһимлеген, халык өчен ни дәрәҗәдә кирәк булуын дикторлык хезмәте башлангач кына аңладым. Ул вакытларда татар телендә сөйли торган радио иң көчлеләрдән булды. Төпле телевидение дә юк бит әле. Бары тик безне генә тыңлыйлар. Башкортстан, Пермь, Ульяновск, Киров өлкәләреннән хатлар килде радиога.

## «Имамнар да диктор кебек бит инде»

**–Фоат абый, имамнарга дикторлык серләрен белү ни дәрәҗәдә мөһим?**

– Диктормы, лектормы, укытучымы – без бит тел белән эш итәбез, тел ярдәмендә фикерләребезне белдерәбез. Имамнар да диктор кебек бит инде. Темалар гына төрле. Мәчетләрдә вәгазь сөйләгәндә дә, Коръән мәҗлесләрендә дин әһеле төп сөйләүче, шушы мәҗлесне алып баручы, аңа юнәлеш бирүче. Вәгазь сөйләргә бик нык әзерлек кирәк дип уйлыйм мин, чөнки алар берүк теманы гына күтәрмиләр. Һәр көнне нинди дә булса яңа темага әзерләнеп киләләр. Коръәнне белергә, сүрәләр, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрен аңларга һәм аңлата белергә кирәк. Имамнар шулкадәр күп материалны карап, бер ноктага тезеп, аерым бер теманы ачарлык итеп әзерләнәләр.

Имам чыгышка гыйлем ягыннан никадәр генә әзерлекле булса да, халык алдына чыгып басар алдыннан, тел ягыннан әзерлек кирәк. Аларның

үз сөйләм алымнары да бар. Мәсәлән, үткән заманны белдерүнең ике төре: билгеле үткән заман һәм билгесез үткән заман бар. Имамнар билгеле үткән заман белән сөйләшәләр. Анысы да миңа кызык тоела. Без алай сөйләшмибез. Әгәр игътибар иткән булсагыз, имамнар «Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте», – диләр. Әйткән димиләр, чөнки «әйткән» дип сөйләү билгесезлекне белдерә. Әйтерсең лә имам кемнәндер ишеткәнне генә сөйли. Нәтиҗәдә, дин әһеленә карата ышаныч тумас иде. Билгеле формада сөйләгәндә, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм яки аның якын кешеләре әйткәнне имамнар үзләре ишетеп торган кебек була. Мин моны имамнарга гына хас үзенчәлекле бер сөйләм дип кабул итәм. Үзенә күрә бер матур сөйләм ул.

## Телләр ник үлә?

**– Фоат абый, телләрнең үлүенә кем сәбәпче?**

– Дөньяда 6000нән артык тел бар, дип әйтелә. Дөрес, соңгы вакытларда 5000 дип тә әйтә башладылар, ягъни кими бара. Әле соңгы көннәрдә генә мине бер вакыйга тетрәтте. Ерак Көнчыгышта – Камчатка ягында бер әби вафат булган. Әлеге әби милләте буенча алеут һәм шул телне белгән бердәнбер кеше булган. Телнең бетүе менә шулай да була икән! Без телнең бетүен күз алдына да китермибез. 5000 дигән вакытта, әле азмы-күпме яши торган телләр күз алдында тотыла торгандыр. Әлбәттә, аның зурлары да бар. Мәсәлән, кытай теле. Бу телдә миллиард ярым, ике миллиард кеше сөйләшә. Яки Һинд илендәге телләр, шулкадәр күп миллионлы кешеләр сөйләшә бит. Аннан өченче урында – инглиз теле. Ул дөньяны иңләп алды һәм төп телләрнең берсенә әйләнеп бара.

Телләрнең бетүенә нәрсәләр тәэсир итә соң? Әлбәттә, иң элек глобальләштерүне атап китәргә кирәк, чөнки теге яки бу телдә сөйләшүче халыкның күплегенә бәйле, кайбер телләр ничектер өстенлек алырга тырышалар. Башка телләрне кысу хисабына үзләренең яшәү даирәләрен

киңәйтергә омтылалар. Инглиз теле моңа ачык мисалдыр инде. Рәсәйдә, мәсәлән, рус телен мисал итеп китерергә була.

Икенче сәбәп – урбанизация, шәһәрләшә бару. Авыллардан шәһәргә күчәләр һәм монда әнә шул шәһәрләрдәге глобальлек авыллардан килгән кешеләрне тел җәһәтеннән йота, төп телдә сөйләшүгә күчерә һәм бу туган телләргә бик зур зыян китерә. Безнең бурыч – шәһәр шартларында да туган телләрне саклау, үстерү өчен мөмкинлекләр табу.

Өченчесе беренче һәм икенчесеннән килеп чыга. Ул да булса – ассимиляция. Татар теленә, шөкер, бүгенге көндә әле андый юкка чыгу куркынычы янамый.

## Татар теленең үзенчәлеге нидә?

– Безнең халкыбыз күп миллионлы һәм аның холкының һәм яшәү рәвешенең бик әһәмиятле үзенчәлеге бар: кая гына барса да, кайда гына яшәсә дә, үз теленнән ваз кичмәү. Өй шартларында гына булса да, балаларга, яшь буыннарга телне өйрәтү һәм мөмкинлек булганда, мәктәпләр оештырып уку, укуны җайга салу.

Мәсәлән, патша Рәсәендә дәүләт татар мәгарифен үстерүгә бер тиен дә бирмәгән. Ә татар халкы Рәсәй Федерациясендә иң укымышлы халык булып яшәгән, чөнки халык үзе, үз хисабына мәктәп-мәдрәсәләр булдырып, балаларын укыткан һәм язарга өйрәткән. Шуңа күрә әдәбиятыбыз да мең елдан артык үсеш кичергән. Кайсы халык шулай әйтә ала?!

Борын-борынгыдан дәүләтле халык булгач, киң даирәләрдә дәүләт төзеп яшәгән халык буларак, татар халкында укуга, телне үстерүгә, саклауга, әдәбиятыбызга булган мәхәббәт һәм омтылыш бервакытта да сүнмәгән. Менә шул безгә татар теленең дә дөнья күләмендә танылуын тәэмин итте. Дөньядагы 5000 телдән ЮНЕСКО 14 телне сайлап ала. Әлеге исемлек телләрнең дөнья халыкларына аңлаешлы булу ягыннан, катлаулы фикерләрне белдерә алу мөмкинлегенә карап төзелгән. Шулар ара-

сында татар теле бар! Рәсәй Федерациясендә ике генә тел кергән: рус һәм татар теле генә. Ә безнең үзебездә генә дә 200дән артык тел бар бит. Төрки телләрдән бары тик татар теле генә кергән. Төрки телләрдән мөстәкыйль дәүләт булган Төркия бар. Анда 60 миллионнан артык кеше яши, ләкин төрек теле шушы 14 тел арасына кермәгән. Димәк, татар теле үзенең системасы, яңгырашы, сүзлек составының бай булуы белән башка телләрдән аерылып, өстен булып тора. Әлбәттә, без моның белән горурланабыз һәм безгә шул казанышны сакларга кирәк.

## Татар теле интернет теле була аламы?

**– Теләсә кайсы тел, тел буларак яшәсен өчен, авылда, өйдә генә түгел, ә фәнни, һөнәри өлкәләрдә дә кулланылуы кирәк. Бүгенге көндә татар теленең, гомумкатламда куллану өчен, мөмкинлекләре бармы?**

– Телләр үссен өчен, берничә шарт бар. Иң кирәклесе – җәмгыятьтә телгә ихтыяҗ булу. Телнең башкара торган вазифалары күптөрле, киң булырга тиеш.

Беренче вазифа – көндәлек тормышта кулланылуы. Бездә әле, шөкер, татар теле көндәлек тормышта киң кулланыла. Дөрес, борчыган нәрсәләр дә бар. Мәсәлән, вата-җимерә булса да башка телдә сөйләшү күренешләре күзәтелә. Бигрәк тә өлкән буын кешеләренең дә балалары киң кулланыла торган телдә сөйләшкәч, аларга яраклашырга теләп, аларча сөйләшергә омтылу күренешләре бар. Ләкин моңа бирешмәскә кирәк.

Икенчесе – аның матур әдәбиятта кулланылуы, чөнки әдәби теле, матур әдәбияты булмаган халыкның көндәлек сөйләм теле дә ярлы була. Телнең үсеше һәм сакланышы бары тик матур әдәбият әсәрләрендә генә булырга мөмкин. Мәсәлән, без бүген дә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен укыйбыз һәм татар теленең нигезен тәшкил итә, дип саныйбыз икән, андагы бөтен сүз запасы – бүгенге көндә дә кулланылышта. Әгәр дә

шушы әсәр булмаса без моны ничек саклар идек икән?!

Ә үсеше мәсьәләсенә килгәндә, ел саен, гасыр саен телебез камилләшә һәм үсә бара. Әнә шул Кол Гали әсәре, Алтын Урда ядкярләре, Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел фәрадис», Сәиф Сараи әсәрләреме… Гасырдан-гасырга телдә үзгәрешләрне күзәтеп килергә мөмкин. Казан ханлыгына җитсәк, Өмми Камал, Мөхәммәдъяр әсәрләре. XIX гасырда без бөтенләй башка күренешкә тап булабыз, әдәби телнең төрекләшә баруы. Ул инде XX гасыр башына шактый гади халык аңламаслык хәлгә җиткән, ягъни әдәби тел белән халыкның гади сөйләм теле арасында бик нык аерма бар. Күрәсез, телдә нинди үзгәрешләр бара, ә инде Г.Кандалый, Г.Тукай, Г.Камалдан башлап чын халыкчан телгә әйләнеп кайту һәм XX гасырда аның искиткеч зур югарылыкка күтәрелә, ягъни әдәбият ярдәмендә без тел торышының үсешен (эволюциясен) күзәтә алабыз. Телне саклау һәм үстерүдә әдәбиятның мөһимлеген күрәбез. Әлбәттә, телнең дәрәҗәсе һәм аның үсеше – тормыш-көнкүрештә бер, ә уку-укыту, тәрбия барышында, сәнгатьтә кулланылуы башкача һәм шул кулланылыш вакытында алар заманга туры китерелеп байый баралар. Ә инде татар теленең бүгенге техник өлкәләрдә кулланылышына килгәндә, безнең зыялыларыбыз XX гасыр ахырында бик зур үрләргә җитеште. Татар телен техник яктан куллануга мөмкинлекләр бик күп. Менә инде ничә елдан бирле дөнья мәйданын әйләндереп алган интернет системада татар теленең кулланылышын күзәтәбез. Интернет программаларны татарчалаштыру, тәрҗемә итү – болар барысы да татар телен техник өлкәгә кулланылышка кертү күрсәткече. Бу, әлбәттә, башлангыч хәлдә генә әле, безгә әле аны үстерергә, камилләштерергә кирәк. Ләкин шунысы әһәмиятле – димәк, шундый даирәләрдә дә татар телен иркенләп кулланып була. Моңа бары тик мөмкинлекләр генә кирәк.

## Телнең киләчәге нинди?

**– Фоат абый, телебезнең киләчәген ничек күзаллыйсыз? Телне саклап калу өчен, без нинди чаралар күрергә тиеш?**

– Телебезне көнкүрештә генә түгел, ә әдәби әсәрләр, техник кулланылыш дәрәҗәсендә, фәнни даирәләрдә мөмкин кадәр күбрәк куллану. Кулланылышны тарайтмау, киметмәү. Киресенчә, көннән-көн арттыру һәм кулланылыш даирәсен киңәйтү. Менә шунда инде аның бөтен яшәү яки яшәмәү мәсьәләсе.

Тагын бер мөһим мәсьәлә бар. Ул да булса – мәктәпләрдә татар телен укытуны тиешле дәрәҗәгә кую. Хәзер мәктәпләрдә татар телен укыту ата-аналарның гариза язуларына бәйле. Күпчелек ата-аналар үз балаларына татар телен укытуны сорап, таләп итеп гаризалар язалар. Аннары яңа уку елында ачылган «Адымнар» мәктәбе һәм шул мәктәпкә тәңгәл килерлек уку йортларының ачыла башлавы күңелдә канәгатьлек хисе тудыра. Димәк, телебезнең киләчәге халыкның үзеннән генә түгел, ә бәлки дәүләтнең татар телен әнә шундый юнәлешләрдә үстерүенә һәм шуңа юл тотуына да бәйле.

*Әңгәмәне Ленар Хамматов оештырды*

# Үрнәк затлар

# Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе

## Тууы

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе якынча 593 елда Мәккә шәһәрендә, хәниф Зәед бине Гамр бине Нөфәйл һәм Фатыйма бинте Нәҗәт гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

## Нәселе

Сәгыйд бине Зәеднең әтисе – Зәед бине Гамр бине Нөфәйл күпаллалыкны – акылга каршы килү, ә потларга табынуны – мәгънәсезлек дип санаган. Ул бераллаһка ышанып, Ибраһим галәйһиссәлам динендә булган. Үз тарафдарларын эзләп, Шам җиренә барып җиткән һәм бер рухани (раһиб) аңа болай дип әйткән:

– Мәккә җиренә кайт. Синең халкың арасында Ибраһим галәйһиссәлам динен яңартучы булыр.

Шулвакытта Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне хак юлны күрсәтүче расүл итеп җибәрә.

Зәед бине Гамр Мәккәгә кайтканда бәдәви гарәпләр (кайбер чыганакларда насаралар дип әйтелә) тарафыннан үтерелә. Үлгәндә болай дип дога кылган: «Йә, Раббым, мине шул нигъмәттән мәхрүм кылсаң, минем улым Сәгыйдне мәхрүм кылма!»

Аллаһы Тәгалә Зәед бине Гамрның догасын кабул кылган.

## Ислам динен кабул итүе

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе, иң беренчеләрдән булып, ислам динен кабул иткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнар белән Әркамә йортында очраша башлаганчы ук

инде диндә булган, ул чагында аңа 20 яшь тирәсе булган.

## Гаилә хәле

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһенең Фатыйма исемле апасына өйләнгән һәм Гомәр радыяллаһу ганһенең иман китерүенә сәбәпче булган.

Белүебезчә, Гомәр радыяллаһу ганһе җәһилият вакытында ислам диненең дошманы булган. Ислам динен кабул итүчеләрне газаплап, мөселманнарга аңардан бик зур зарар ирешкән.

Бервакыт ул хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне, гарәпләрне ата-бабалар диненнән читләштереп, ислам диненә чакырганы өчен, үтерергә теләгән. Барыр юлында апасы Фатыйма һәм аның ире Сәгыйд бине Зәеднең ислам динен кабул иткәннәрен белгән.

Гомәр радыяллаһу ганһе иң элек апасы Фатыйма йортына керергә карар кылган. Бу вакытта Фатыйма ире Сәгыйд белән Хәббән бине Мунзирдән Коръән аятьләре өйрәнеп утыра торган булганнар. Ачулы Гомәрнең килеп ишек кагуыннан алар куркып калганнар. Ишекне ачмауларын күргәч, Гомәр радыяллаһу ганһе өйгә бәреп үк кергән. Кергән чакта: «Мин сезнең ислам динен кабул иткәнегезне ишеттем», – дип Сәгыйд бине Зәедне сугып еккан. Ирен якларга теләгән апасына да өлеш чыгарган.

Гомәр радыяллаһу ганһе дине өчен шулай нык торган Фатыйманы һәм Сәгыйдне күреп: «Бу кешеләрне күрче, диннәре өчен ничек нык торалар. Безнең арабызда потлар өчен бер тамчы кан түккән кеше дә юк», – дип уйга калган. Ул кылган гамәлләре өчен бик нык үкенгән һәм апасыннан: «Сез нәрсә укыдыгыз? Бир әле, мин дә укып карыйм», – дип сораган. Фатыйма аңа: «Юк, бу – Коръән. Аңа чиста килеш кенә тотыналар», – дип әйткәч, Гомәр радыяллаһу ганһе госел алып кергән.

Шуннан соң апасы кулындагы төргәкне аңа биргән һәм ул андагы «Та Һа» сүрәсен укыган. Шулчак ул: «Бу нинди гаҗәеп, матур сүзләр.

Кешеләр бу сүзләрне әйткән кешедән кала беркемгә дә гыйбадәт кылырга тиеш түгелләр! Мине Мөхәммәд янына алып барыгыз!» – дип әйткән.

Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йортына барып, аның каршысына килеп шәһадәт кәлимәсен әйткән. Шул рәвешле Ислам динен кабул иткән. Күргәнебезчә, Гомәр радыяллаһу ганһенең ислам динен кабул итүендә Сәгыйд бине Зәеднең дә өлеше булган.

## Сыйфатлары

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе ачык йөрәкле, пакь җанлы, йомшак күңелле, тәкъва һәм дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичкән, халык арасында хөрмәт ителә торган зат булган.

Сәхабә буларак, Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе күп вакытын пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында үткәрергә тырышкан. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәм итүчеләрдән булып, һәрбер сугышта катнашкан. Ул бары тик Бәдер сугышында гына катнаша алмаган, чөнки ул вакытта Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вазифаларын башкарырга дип, Мәдинәгә киткән булган.

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе киң күңелле булуы белән аерылып торган. Ярдәм сорап аңа мөрәҗәгать итсәләр, ул беркайчан да каршы килмәгән. Ганимәт малыннан үзенә тиешле булган өлешне дә фәкыйрь мөселманнарга тарата торган булган, күп очракта үзе ач калган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң да Сәгыйд бине Зәед мөселманнар өчен зур тырышлыклар куйган. Ярмук сугышында мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә ышанып, иманнарында нык торып, дошманнарны җиңгәннәр. Шул вакыттан соң Шам җирләре бер-бер артлы мөселманнар идарәсенә күчеп барган.

Бу вакыйгалардан соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһене Димәшкъ җитәкчесе итеп билгеләп куйган. Ләкин Сәгыйд бине Зәед бу хакта белгәч, әлеге вазифадан баш тарткан, чөнки аңа дөнья өстенлекләре түгел, ә Ахирәт әҗерләре якынрак булган.

Сәхабәләр төрле авырлыкларга очраган кебек, Сәгыйд бине Зәедкә дә төрле сынаулар аша үтәргә туры килгән.

Риваятьләрдә аның белән булган бер вакыйга килә. Мәдинә җирендә Әрва бинте Убәйсә исемле хатын үзенең җир өлешен алган дип Сәгыйд бине Зәедне гаепләгән һәм хәлифә Мәрван бине Хәкәмгә шикаять кылган. Мәрван бине Хәкәм бу хәлгә ачыклык кертер өчен, Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе янына үз кешеләрен юллаган. Сәгыйд бине Зәед аларга болай дип җавап биргән: «Әллә сез мине гаделсезлектә гаеплисезме? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү хаксыз кеше җиреннән бер карыш өлеш алса, Кыямәт көнендә ул җир аның муенына уралыр», – дип әйтте».

Риваятьләрдә Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһенең хаклыгы расланганы хакында хәбәр ителә.

## Вафаты

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе 51 нче һиҗри елда Мәдинә шәһәре янындагы Акыйк җирлегендә вафат булган. Аның җәсәден Мәдинәгә алып килеп дәфен кылганнар. Аны озатучылар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күренекле сәхабәләре Сәгыйд бине Әби Вәккас, Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр булган.

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# Апрель

## “Ислам. Беренче адымнар”ның җиденче сезонында 80 кеше намаз укырга һәм Ислам нигезләренә өйрәнде

Шәгъбан аеның 22 нче көнендә (4 нче апрельдә) нәзарәтнең халык арасында танылган “Ислам. Беренче адымнар” мәктәбе үз эшен тәмамлады. Җиденче тапкыр уздырылган мәктәптә 80 кеше Ислам нигезләрен үзләштереп, намаз укырга өйрәнде. «Ислам. Беренче адымнар» проекты – бу гыйлемнәрне кыска вакыт эчендә өйрәтүне максат иткән чара. Укучылар 7 дәрестә тәһарәт, намаз серләренә төшенә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлын, гакыйдә, хәләл-харам мәсьәләләрен үзләштерә.

## Мөселман уку йортлары шәкертләре татар теле, әдәбият һәм тарих буенча олимпиадада көч сынашты

Шәгъбан аеның 26 нчы көнендә (8 нче апрельдә), Рәсәй ислам институтында Татарстан мәдрәсәләре һәм ислам югары уку йортлары шәкертләре арасында татар теле, әдәбияты һәм татар халкы тарихы буенча республикакүләм олимпиада узды. Әлеге бәйге Татарстан мөфтияте һәм Рәсәй ислам институты башлангычы һәм ярдәме белән «2021 нче ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» кысаларында уздырылды. Олимпиадада РИИ, КИУ, “Мөхәммәдия”, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге, Урыссуның “Фәнис”, Буа мәдрәсәсе шәкертләре катнашты.

## Казанда Диния нәзарәтенең VIII Корылтае узды. Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан мөфтие итеп сайланды

Шәгъбан аеның 30 нчы көнендә (12 нче апрельдә) Казанда Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең чираттагы VIII Корылтае узды. Аның эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, РФ һәм ТР Президентлары Аппаратлары вәкилләре, министрлар, зур оешма җитәкчеләре, район һәм шәһәрләр башлыклары, республиканың 1500 имамы, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты. Корылтай беренче тапкыр “Казан Экспо”га җыелды. Корылтайның көн тәртибендәге мәсьәләләр булып Татарстан Мөфтиен һәм Баш казыен, шулай ук Мөфтинең беренче урынбасарын сайлау, Нәзарәтнең үткән 4 елда башкарылган эшчәнлегенә йомгак ясау һ.б. торды. Шулай ук делегатлар игътибарына Нәзарәтнең Казыйлар шурасы һәм Үзәк ревизия комиссиясе хисабы да тәкъдим ителде.

## Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны үтте

Изге Рамазан аеның беренче көнендә Татарстан Республикасында Диния нәзарәте башлангычы белән традицион «Рамазан – игелекле эшләр ае» хәйрия марафоны старт алган иде. Нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды 30 көн эчендә, битараф булмаган татарстанлылар ярдәме белән, 19 авыру балага дәвалану курсларын түләү өчен акча җәлеп итте. Бу акчалар аларга баш миенең арахноидаль кистасы, ВВС, ДЦП, спастик тетрепарез, Веста синдромы һ. б. диагнозларга каршы көрәштә ярдәм итә. Шулай ук фондның махсус картасына 1 миллион сум күләмендә фитыр

садакасы кергән. Фитыр садакасы мохтаҗ гаиләләргә акча рәвешендә тапшырылды. Моннан тыш, күп балалы, авыру балалар тәрбияләүче һәм тулы булмаган 790 гаиләгә 5,1 тонна күләмендә азык-төлек җыелмалары, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләренә 3 тонна азык-төлек тапшырылды, 110 хөрмәтле ветеран азык-төлек күчтәнәчләре алды. Марафон кысаларында тагын бер зур социаль чара – Республикакүләм ифтары матәм форматында узды. Ифтарда 3,5 меңнән артык кеше катнашты. Рамазан аенда мөселман тоткыннары да игътибарсыз калмады: изге көннәрдә нәзарәт колонияләрдәге 500 тоткынга ифтарлар уздыру өчен 5 тонна күләмендә ярымфабрикатлар, яшелчә һәм җиләк-җимеш тапшырды. Тоткыннар өчен махсус туклану һәм гыйбадәт кылу режимы кертелде, шулай ук гает намазлары үтте.

Казанның «Ярдәм» мәчете 50 сукыр һәм начар күрүче мөселманнар өчен «Йөрәк белән күрәбез һәм ишетәбез» дигән бушлай тернәкләндерү курслары уздырды, ай дәвамында 40 мең мохтаҗ кешене ифтар җыелмалары белән тәэмин итте.

## Нәзарәтнең “Хозур” нәшрият йорты балалар өчен энциклопедия нәшер итте

Гакыйдә фәненә караган сорауларга кыска һәм төгәл, ачык һәм аңлаешлы итеп җавап бирү максатыннан, “Хозур” нәшрият йорты балалар өчен Мәликә Өмме Яхъяның «Клад для маленьких мусульман» (“Нәни мөселманнар өчен хәзинә”) исемле китабын нәшер итте. Биредә гакыйдә фәненең иң авыр төшенчәләре һәм мөселманның вазифалары балалар аңларлык телдә язылган. Материал аңлаешлы булып, хәтердә калсын өчен, автор заманча сторителлинг (хикәяләү) техникасын куллана.

### “Хозур” нәшрияты электрон форматтагы китаплар сата башлады

“Хозур” нәшрият йортының рәсми интернет-кибетендә хәзер китапларны электрон форматта сатып алу мөмкинлеге барлыкка килде. Шул рәвешле, басма китапларга заказ бирүдән тыш, аларның электрон нөсхәсен компьютерга яисә телефонга йөкләп алу мөмкинлеге дә тудырылды. Иң беренчеләрдән булып pdf форматында сайтка урнаштырылган китаплар арасында нәзарәтнең “Калям Шариф. Перевод смыслов” басмасы сатуга чыгарылды. Бу исемлек киләчәктә тагын да киңәйтеләчәк. PDF-басма сатып алучының электрон почтасына акча түләүгә үк җибәреләчәк. Электрон форматтагы китапларны табуы бик җиңел: моның өчен huzurshop.ru кибете сайтына керергә һәм төп биттә “Электрон китаплар” баннерына басарга кирәк.

## Май

### Яңа татар зиратында мөфти катнашында остазларны искә алу көне узды

Рамазан аеның 20 нче көнендә (2 нче майда), мөселман дин эшлеклеләре, имамнар, мөгаллимнәр, зыялылар, киң татар җәмәгатьчелеге Казан шәһәренең Яңа бистә зиратына Остазларны искә алу чарасына җыелды. Алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде. Дога кылу мәрасименә килүчеләрне әлеге чараны 1998 елдан бирле оештырып килүче, искә алу көненең программасын һәм каберлекләр картасын төзүче Ильяс хәзрәт Җиһаншин каршы алды. Остазларны искә алу чарасына аның белән бергә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре дә килде – алар ел дәвамында каберләрне, чардуганнарны карап, чистартып, буяп, төзекләндереп тора. Моннан тыш, чарада иҗат әһелләре – язучылар, мөхәррирләр, фән эшлеклеләре, автор-

башкаручылар, җырчылар бар иде – зыялылар, аллеялар буйлап узганда, фидакарь шәхесләрнең исемнәрен хәтердә яңартырга ярдәм итте, матур истәлекләрне барлады.

## Татарстан мәчетләрендә Казан мәктәбендә килеп чыккан фаҗигадә һәлак булганнар рухына дога кылдылар

Рамазан аеның 29 нчы көнендә (11 нче майда), Татарстан мәчетләрендә Казан мәктәбендә килеп чыккан фаҗигадә вафат булучыларның рухына дога кылдылар. Аерым алганда, башкаланың Галиев мәчетендә мөселманнар, өйлә намазын укыганнан соң, бергәләп, Коръән аятьләре укып, фаҗигадә тән җәрәхәтләре алучыларның тизрәк савыгуын, вафат булган дин кардәшләребезнең рухлары шат булуын сорап дога кылды. Мөселманнар һәлак булучыларның җаннарын Раббыбызның мәңгелек җәннәт белән бүләкләвен, яраланучыларга Үзенең хәерле шифаларын бирүен, Аллаһы Тәгаләнең илебезне, дөньяны мондый коточкыч хәлләрдән Үзе саклавын сорады. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әлеге фаҗига сәбәпле кайгы уртаклашты.

## Казанда матәм шартларында 9 Республикакүләм ифтар узды

Рамазан аеның 29 нчы көнендә (11 нче майда), «Казан ЭКСПО» халыкара күргәзмәләр үзәгендә 9 Республикакүләм ифтары узды. Республикакүләм ифтар ТР мөселманнары Диния нәзарәте, «Ак Барс Арена» стадионы дирекциясе һәм «Туган авылым» милли-туристлык комплексы көче белән үткәрелде. Быел ифтар мәҗлесе 5 мең татарстанлы өчен оештырылган иде. Әмма Казанның 175 нче мәктәбендәге фаҗигале вакыйгалардан соң ифтар матәм шартларында узды. Ифтарга 3,5 меңләп

кеше килде. Алар арасында гади мөселманнар да, азкеремлеләр дә, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр дә, эшмәкәрләр дә, төбәкләрдән килгән кунаклар, мөфтиләр дә бар иде. Татарстандагы милләттәшләренә теләктәшлек күрсәтеп, ифтарга Рәсәйнең Дини Җыены рәисе, Мәскәү һәм Чувашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов һәм Рәсәйнең Азия өлеше Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нәфигулла хәзрәт Аширов килде. Мөфтиләр, республика мөселманнарын сәламләп, кайгы уртаклашты.

## “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең төзекләндерелгән тарихи бинасында уку-укыту башланды

“Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең төзәкләндерелгән тарихи корпусында тулы көчкә уку-укыту процессы башланды. Шул рәвешле бина үзенең тарихи вазифасына кайтты һәм заман таләпләренә җавап бирердәй уку корпусы булып хезмәт итә башлады. Исегезгә төшерәбез: 2020 елда “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең уку корпусында төзекләндерү-реставрация эшләре башланган иде. Быел Ураза бәйрәменә алар төгәлләнде. Гает көнендә бинаны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карап китте һәм башкарган эшләргә уңай бәя бирде.

## ТР МДНе Аксакаллар Шурасы Казан шәһәре яулап алынганда һәлак булганнарны искә алу өчен Хәтер көне датасын билгеләде

ТР МДНе Аксакаллар Шурасы Казан шәһәре яулап алынганда һәлак булганнарны искә алу өчен Хәтер көне датасын билгеләде. Аны шәүвәл аеның 13 нче көнендә уздырырга карар кылынды, чөнки һиҗри исәп буенча бу көнне 959 елда Явыз Иван (Иван IV) гаскәрләре, озак чолганышта торганнан соң, Казанны яулап ала. Башкаланың төшүе Казан ханлыгының бетүенә китерә. Әлеге чарада, аксакаллардан тыш, танылган дин, фән

һәм җәмәгать эшлеклеләре, шул исәптән, Дамир Исхаков, Рәүф Хәсәнов, Фәндәс Сафиуллин һәм башкалар катнашты. Утырышта катнашучылар татар халкы тарихындагы бу мөһим көнне Казан Кремлендә «Кол Шәриф» мәчетендә, шулай ук Казан ханнары мавзолее мәйданында Казан алынганда һәлак булучылар рухына Коръән укып һәм дога багышлап билгеләп үтү турында карар кабул итте.

## Казанда туган телләрне саклау һәм үстерүгә багышланган студентлар конференциясе узды

Шәүвәл аеның 15 нче көнендә (27 нче майда), Рәсәй ислам институтында туган телләрне саклауга һәм үстерүгә багышланган «Хәзерге заман яшьләре һәм Рәсәй халыкларының рухи кыйммәтләре» VI Республикакүләм студентлар фәнни-гамәли конференциясе узды. Әлеге чараны Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Рәсәй ислам институты һәм Казан ислам университеты оештырды. Конференциядә Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Саратовның югары һәм урта һөнәри уку йортлары студентлары катнашты. «Хәзерге заман яшьләре һәм Рәсәй халыкларының рухи кыйммәтләре» VI Республикакүләм студентлар фәнни-гамәли конференциясе кысаларында “Рәсәйдә ислам дин гыйлеме: тарих һәм хәзерге заман”, “Теологик белем бирү – яшь галимнәр күзлегеннән”, “Туган тел һәм әдәбият”, “Мультиконфессиональ киңлектә чит тм иң яхшы фәнни эшләр сайлап алынды.

## Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100-еллыгы бренды идеясен эшләүгә Бөтенрәсәй бәйгесе нәтиҗәләре билгеле булды

Нәзарәттә Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100-еллыгы бренды идеясен эшләүгә Бөтенрәсәй бәйгесенә йомгак ясал-

ды. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте бәйгесендә теләге булган һәркем катнаша алды. Бәйгедә катнашырга теләп 40 тан артык кеше гариза бирде. Алар бәйгегә 70 ләп логотип тәкъдим итте. Бренд идеяләрен сайлап алганда теманы ачу тирәнлеге; иҗади якын килү; идеяләрнең һәм сәнгать чишелешенең чагылышы; конкурс тематикасына туры килү; юбилей чараларының эчтәлеген чагылдыру; идеянең һәм сәнгати бирелешенең оригинальлеге һәм уникальлеге; осталык; эскизның эчтәлеге; техник үтәлеш кебек критерийлар кулланылды. Оештыручылар җиңүчеләр дип Казаннан Илшат Хәйретдиновны һәм Шамил Кормановны тапты. Әмма өченче җиңүче булырдай лаеклы эшләр ачыкланмады. Бәйге шартлары буенча, җиңүченең һәркайсына 100 мең сум күләмендә акчалата бүләк тапшырылды. Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100-еллыгы бренды логотибы әлеге авторлар логотиплары нигезендә эшләнәчәк.

## Ютазыда II Рәсәйкүләм Коръән укучылар бәйгесе үтте

Шәүвәл аеның 17 нче көнендә (29 нчы майда), Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында II Рәсәйкүләм “Халисә” Коръән укучылар бәйгесе үтте. Бәйге Татарстан мөфтияте, Көньяк-Көнчыгыш казыяте, Ютазы мөхтәсибәте тарафыннан район хакимияте катнашында Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүгә 1100-еллык кысаларында үткәрелде. Бәйгегә Татарстан районнарыннан, Казаннан, Башкортстан Республикасыннан, Волгоград, Пенза өлкәләреннән һ.б. төбәкләрдән 46 мөслимә үз көчен сынарга теләк белдереп гариза биргән иде. Төп турга 24 гүзәл зат узды. Сайлап алу туры Урыссуның “Фәнис” мәдрәсәсе базасында үткәрелде. Бәйгедә иң яшь катнашучыга – 5, иң өлкәненә 48 яшь иде.

Биш җөзне белү номинациясендә җиңү яулаучыга Мәрданшиннар гаиләсеннән махсус бүләк – 50 мең сум күләмендә акчалата бүләк, ә 3

җөзне яттан белү номинациясендә беренче урын алучыга Ютазы районы башлыгының махсус бүләге тапшырылды. Калган призерлар һәм катнашучылар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтеннән кыйммәтле һәм истәлекле бүләкләр алды.

Конкурсның җиңүчеләре: «3 җөзне яттан белү» номинациясендә I урын – Зыерова Мөхшәриф (Уфа, 10 яшь), II урын – Хәйретдинова Әминә (Түбән Кама, 12 яшь), III урын – Низамова Ләйлә (Мөслим, 17 яшь). «5 җөзне яттан белү» номинациясендә I урын – Мәфлүхенова Хәбибә (Казан, 17 яшь), II урын – Вәлиева Альбина (Казан, 38 яшь), III урын – Хәнәфиева Сәлсәбил (Казан, 13 яшь).

## Азнакайда Коръән уку һәм татар мәкаме буенча бәйгеләр узды

Шәүвәл аеның 18 нче көнендә (30 майда), Татарстан мөфтияте, Азнакай мөхтәсибәте һәм хакимияте, КИУның Коръән-хафизлар әзерләү үзәге тарафыннан Коръән уку буенча ике зур бәйге уздырылды. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын каршылап һәм Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан үткәрелгән әлеге чаралар Азнакай шәһәре мәдәният сараенда үтте. IV “Әсләм” Коръән укучыларның төбәкара бәйгесе Коръәннең соңгы ике һәм соңгы алты җөзен белү буенча үткәрелде. Быел дүртенче тапкыр Азнакайда уза торган төбәкара бәйге кысаларында беренче тапкыр татар мәкаме белән иң яхшы Коръән укучы да ачыкланды. Татар мәкаме белән Коръәнне иң яхшы укучы Нурислам Әбсәләмов Казанда яши, 38 яшь. Акчалата бүләктән тыш, ул Татарстан мөфтиенең махсус бүләге – гомрәгә юллама белән бүләкләнде.

# Июнь

## Нәзарәттә «Казан басмасы» иске типография шрифты компьютерга кертелде һәм Коръәннең яңа Казан басмасы әзерләнә башлады

Шәүвәл аеның 20 нче көнендә (1 нче июньдә), нәзарәттә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә «Казан басмасы» заманча компьютер шрифты нигезендә беренче Коръән басмасын әзерләү турында киңәшмә узды. «Казан басмасы» компьютер шрифты шул ук исемдәге аутентик типографик эзеннән (оттискысыннан) ясалды һәм цифрлаштырылган рәвештә Коръәнне бастыруда тарихта тәүге тапкыр кулланылачак.

Киңәшмә эшендә ТР МДНе Голәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев, мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, “Хозур” нәшрияты директоры Ришат Хәмидуллин, нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе, Казан казые, Голәмәләр шурасы әгъзасы Булат хәзрәт Мөбарәков, Казан ислам университетының Коръән-хафизлар әзерләү үзәге мөгаллиме, Коръәннең ун кыйраәте белгече Рушан хәзрәт Йосыпов, нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек белгечләре Идрис хәзрәт Кыёмов һәм Әхмәт хәзрәт Әбү Яхъя катнашты.

Утырышта хәзрәтләр чит илдән җәлеп ителгән белгечләрнең «Казан басмасы» шрифтын цифрлаштыру эше нәтиҗәләре турында фикер алышты. Моннан тыш, алар шушы шрифт белән төшерелгән текстларны тикшереп чыкты. Яңа «иске» «Казан басмасы» Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100-еллыгы уңаеннан бастырылып чыгарылачак, дип планлаштырыла. Басма дөньякүләм кабул ителгән халыкара “Әр-Рәсем Әл-Госмани” стандартларына туры киләчәк.

## «Ак Барс» Банк»ының торак сатып алу өчен ислам кануннары буенча эшләнгән продукты Нәзарәт тарафыннан хупланды

Диния нәзарәте резиденциясендә «Ак Барс» Банкы» вәкилләре белән эшлекле очрашу узды. Очрашу Шәригать нормалары буенча өлешләп түләү аша күчемсез милекне сатып алу юлы белән «Ак Барс» Банкы»ның яңа продуктын гамәлгә ашыру мәсьәләләренә багышланды. Әлеге продукт 2019 елда “Мурабаха” ислам контракты формасында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән килештерелеп, сертификацияләнгән шәригать эксперты катнашында AAOIFI (Ислам финанс учреждениеләрендә исәп-хисап һәм аудит оешмалары) стандартлары нигезендә эшләнде һәм ТР МДН тарафыннан хупланды. Ислам финанс продуктын тулысынча гамәлгә ашыру максатыннан, ТР мөселманнары Диния нәзарәте белгече Идрис Кыёмов даими шәригать күзәтчелеге алып барачак.

## Мөфти Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү буенча оештыру комитеты составына кертелде

Шәүвәл аеның 23 нче көнендә (4 нче июньдә), Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү буенча республика оештыру комитеты составын раслады. Документта оештыру комитеты составына Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәтнең дә кертелүе әйтелә. Комиссия 2022 елда әлеге күркәм вакыйгага бәйле булган чараларны әзерләү һәм үткәрү белән шөгыльләнәчәк.

## БИАда Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча утырыш узды

Шәүвәл аеның 24 нче көнендә (5 нче июньдә), Болгар ислам академиясендә Изге Болгар җыены кысаларында Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү мәсьәләләре буенча утырыш узды. Киңәшмә Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Шакирҗан улы Хөснуллин җитәкчелегендә үтте. Очрашуда РФ Президентының дини оешмалар белән багланышлар буенча Департаменты җитәкчесе Евгений Еремин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстанның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразиев, ТР ДС рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, министрлар, ведомстволар җитәкчеләре катнашты. Дини оешмаларны Рәсәйнең баш мөфтие Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Рәсәй мөселманнары Дини җыены башлыгы Әлбир Крганов, Рәсәйнең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Нәфигулла хәзрәт Аширов, Кырым мөселманнары мөфтие Әмирали Аблаев, Рәсәй мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов һ.б. бар иде.

Татарстан мөфтияте юбилейга, җиң сызганып, беренчеләрдән керешүче дини оешма булды. Бу хакта конкрет мисаллар һәм тирән эчтәлекле дәлилләр китереп, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сөйләде һәм нәзарәтнең бәйрәмне уздыру буенча тәкъдимнәрен җиткерде. Камил хәзрәт билгеләп үткәнчә, нәзарәт 1100-еллык уңаеннан төзелгән барлык эш планын 5 төп юнәлеш нигезендә алып барырга ниятли. Болар – Коръәнне өйрәнү өлкәсендәге башлангычлар; мультимедиалы чаралар; фәнни-дини проектлар; күргәзмәләр; яшьләр өчен проектлар.

## Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1099 еллыгы уңаеннан Изге Болгар җыены узды

Шәүвәл аеның 24 нче көнендә (5 июньдә), Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1099 еллыгына багышланган «Изге Болгар җыены» узды. Бәйрәмдә Мәскәүдән күпсанлы рәсми кунаклар, Татарстан Республикасы җитәкчелеге, дини лидерлар, муниципаль берәмлек башлыклары, Рәсәй Федерациясе төбәкләреннән килгән министрлык һәм ведомство җитәкчеләре, XI Бөтенрәсәй татар дин әһелләре форумы эшендә катнашкан мөселман дин әһелләре катнашты.

## Татарстан мөфтиятенең «Хәләл» стандарты комитеты һәм Рәсәй мөфтиләр шурасы каршындагы «Хәләл» Халыкара стандартлаштыру һәм сертификацияләү үзәге арасында Меморандумга кул куелды

Зөлкагъдә аеның 1 нче көнендә (11 нче июньдә), Татарстан мөфтияте бинасында «Хәләл» стандарты комитеты белән Рәсәй мөфтиләр шурасы каршындагы «Хәләл» Халыкара стандартлаштыру һәм сертификацияләү үзәге арасында үзара аңлашу турында яңартылган Меморандумга кул куелды. Документны оешмаларның башлыклары Габбас хәзрәт Кадыйров һәм Айдар Газизов имзалады. Документка рәсми рәвештә кул кую чарасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рәфикъ Фәттәхетдинов катнашты. Үзара аңлашу турындагы Меморандумга озак вакытлы конструктив партнерлык элемтәләрен ныгыта торган шартлар булдыру өчен ике яклы тырышлыкны туплау максатыннан һәм Рәсәйдә хәләл-индустрияне үстерү

нияте белән кул куелды. Үзара бәйләнешне тигезлек, ике яклы ышаныч, шулай ук Рәсәйдә һәм БДБ илләрендә хәләл базарны үстерү эшендә максатчанлык нигезендә гамәлгә ашыру күздә тотыла. Моннан тыш, Меморандумда ике сертификацияли торган оешманың Татарстан Республикасы җирлегендә эшләү тәртибе дә билгеләнгән.

## Нәзарәт халык арасында наркоманиягә каршы дәгъват алып бара

Зөлкагъдә аеның 6 нчы көнендә (16 июньдә), Диния нәзарәте ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасы вәкилләре белән бергәлектә яшьләр арасында психикага начар йогынты ясый торган матдәләрне куллануны кисәтү темасына видеоконференция рәвешендә түгәрәк өстәл уздырды. Түгәрәк өстәл материаллары Татарстан Республикасы районнары имамнарына киләчәктә һөнәри эшчәнлекләрендә профилактик эш күнекмәләрен булдыру өчен хезмәт итәчәк. Шунысы игътибарга лаек, Татарстан сәламәтлек саклау министрлыгы ТР Диния нәзарәте белгечләрен Татарстанда яшәүчеләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча ТР Хөкүмәт комиссиясенең эшче төркеменә кертте.

## Татарстан дини уку йортларында кабул итү кампаниясе башланды

Татарстан мөселман уку йортларында кабул итү кампаниясе башланып китте. Бүгенге көндә республикада күп баскычлы дини мәгариф системасы гамәлдә. Башлангыч белемне мәчетләр каршындагы курсларда алып булса, урта белемне мәдрәсәләр, югары белемне Рәсәй ислам институты / Казан ислам университеты (бакалавриат, магистратура) һәм Болгар ислам академиясе (магистратура, докторантура) бирә.

## Казанда Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган «ALGA TRAIL» массакүләм йөгереше узды

Зөлкагъдә аеның 10 нчы көнендә (20 нче июньдә), Казанның Аккош күле янәшәсендә «ALGA TRAIL» дип аталган массакүләм йөгереш узды. Чара Идел буе Болгар дәүләтендә исламны рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланды һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан үткәрелде. Йөгерештә катнашу өчен Аккош күле буеча 200-гә якын кеше җыелды. 5 яшьтән алып һәм аннан өлкәнрәк спортчылар Казаннан гына түгел, Яр Чаллы, Түбән Кама, шулай ук Ульяновск, Әстерхан, Мурманск төбәкләреннән дә килде. Күмәк йөгерешкә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да кушылды һәм конкурстан тыш 5 км аралыкны уңышлы йөгереп чыкты. Аның белән бергә мөселман яшьләренә уңай үрнәкне Түбән Кама районы имам-мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов һәм Рәсәй ислам институты мөгаллимнәре дә күрсәтте.

# Тарих

# Хабибрахман Шакир: меңләгән күлләр иленә сикәлтәле юл

(Дәвамы. Башы алдагы санда)

## Пешавардагы тормыш битләреннән…




**Хабибрахман Шакир Әл-Болгари (үзәктә). Пешавар**


1930 елда Хабибрахман Шакир Әфганстаннан Пешавар (ул вакытта Британия колониясе составындагы Һиндстанга кергән) шәһәренә күчә. Ә хәзер ул, Пакыстан-Әфганстан чикләрендә урнашкан, Пакыстанның чик буендагы шәһәре булып тора.

Көнчыгыш Төркистаннан булган Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин (Мөхәммәд Гали Рахмәтулла улы) ярдәме белән, безгә Хабибрахман Шакирның Пешавардагы тормышыннан кызыклы фактлар билгеле булды. Шунысы ук кызыклы: алар әлеге зур шәрыкъ шәһәрендә очрашып,

шәхсән таныша алганнар. Ул вакытларда Пешаварда элеккеге Рәсәй империясенең совет хакимияте тарафыннан җәберләүләргә дучар ителгән бик күп мөселман качкыннары яшәгән. Күчеп килүчеләрнең күпчелеге Урта Азиядән, шул исәптән, Көнчыгыш Төркистаннан булган.

Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин сәүдә эшләре белән Кашгар (Көнчыгыш Төркистан) шәһәреннән Пешаварга килә һәм җирле халык тарафыннан бер мәҗлескә чакырыла. Монда ул очраклы рәвештә «Яңа Милли Юл» («Новый национальный путь») журналына тап була.

Бу журнал 1920-30 елларда Гаяз Исхакый тарафыннан, Берлинда нәшер ителә һәм татар иммиграциясенең периодик рәвештә чыгып килә торган төп басмасы була. Аның: «Бу басманы кем яздыртып ала?» – дигән соравына: «Мәүләви Хабибрахман Әл-Болгари», – дип җавап биргәннәр. «Мәүләви» сүзе, гарәпчәдән «хаким», «тәрбия кылучы», «хуҗа» дип тәрҗемә кылына. Урта Азия, Иран, Әфганстан, Пакыстан һәм Һиндстан мөселманнары арасында бу сүз хөрмәтле дин галименә, шәригать хөкемнәре белгеченә эндәшкәндә кулланыла. Мөхәммәд Гали Рахмәтуллинның Хабибрахман Шакир белән танышуы шул рәвешле булган. Хабибрахман Шакир, Пешаварда качкыннарны туплау буенча, актив эшчәнлек алып барган. Аның тырышлыгы белән, «Мәдрәсәт әл-мөһаҗирин»




**«Яңа Милли Юл» журналы, Берлин, № 7, 1933 ел, июнь**

(«Мөһаҗирләр мәдрәсәсе») дип исемләнгән, күченеп килүчеләрнең балалары укый торган мәдрәсә барлыкка китерелә. Аннары ул әлеге мәдрәсәдә укыткан, аның имамы булган, мәдрәсәне җиһазландыру һәм финанс яктан тәэмин итү мәсьәләсен кайгырткан.




**Финляндия татарлары. Балалар укытучы белән милли курсларда. 1932-1933 еллар, Куопио, Финляндия**

Мөхәммәд Гали Рахмәтуллин сүзләре буенча, Хабибрахман Шакирның хәлләре мөшкел була. Аңа, мәдрәсәне тәэмин итәр өчен, чыгымнар табу кыен була, чөнки күченеп килүчеләр, балаларын укытыр өчен, үзләренең акчаларын корбан итәргә бик омтылмый. Моннан тыш, Хабибрахман Шакир китаплар язарга да вакыт таба. Ул башка илләргә дә таралган мөселман мөһаҗирләре белән хатлар алышып, тыгыз элемтәдә торган. Шулай ук, Ерак Көнчыгыштагы «Милли Байрак» («Национальное

знамя») исемле татар газетасында да басыла торган булган. Ул Пешавардагы һәм Көнчыгыш Төркистандагы мөселманнарның тормышы хакында хәбәр биреп торган һәм төрле юллар белән аларның проблемаларын хәл итәргә тырышкан.

## Пакыстанның булачак президентының меңләгән күлләр иленә эләгүе

Хабибрахман Шакирның авыр тормыш юлы турындагы хикәяләүне дәвам итеп, без аның ул вакытта Британия империясе составына кергән Пешавардагы тормышына тукталдык. Пешаварда Хабибрахман Шакир танылган татар дин белгече Муса Бигиев белән таныша. Аларның аңа хәтле үк тә таныш булулары ихтимал. Муса Бигиев сәфәрдән Япониягә кайткан-да Һиндстан аша Әфганстанга эләгергә тели, әмма 1939 елда Англиянең колониаль хөкүмәте аны кулга ала. Ул 1945 елга кадәр Пешаварда кулга алынган хәлдә кала.

1942 елда меңләгән күлләр иленең булачак имамы гаиләсе белән Бомбейга (хәзер Мумбаи дип билгеле) күченергә карар кыла. Монда ул үзенең дини һәм укытучылык эшчәнлеген дәвам итә. Бомбейда Хабибрахман Шакирның укучылары арасында Пакыстанның булачак президенты һәм премьер-министры Зөлфикәр Али Бхутто (1928–1979) да була. Финляндиядә булганда ук Хабибрахман Шакир гомер буе кызыксынып, үзенең элеккеге укучысының уңышларын күзәтеп бара.

1946 елда Бомбейга Муса Бигиев килә. Күп еллар Пешавар төрмәсендә булганнан соң аның сәламәтлеге какшаган була. Монда ул ике ай чамасы хастаханәдә дәвалана, берничә операция кичерә. Нәкъ менә шул вакытта Каһирәгә китәр алдыннан Муса Бигиев, үзенең якташы, татарлар арасындагы белемле галимгә, ихтыярсыз иммигрант булган Хабибрахман Шакирга, Тампере шәһәрендә финлы татарларның имамы буларга тәкъдим итә.

Муса Бигиев һәрвакытта да Финляндия татар җәмәгатьчелеге белән тыгыз элемтәдә яши. Тампере шәһәре татарлары бай һәм көчле җәмәгатьчелек була һәм шул вакытта ук күпсанлы җәмәгатьчелектән аерым мөстәкыйль рәвештә эшчәнлек алып баралар. Бу җәмәгатьчелек күптәннән белемле имамга һәм укытучыга мохтаҗ була. Шуңа да Муса Бигиев аларга Хабибрахман Шакирны тәкъдим итә.

Шул рәвешле, алдагы санда билгеләп үткәнчә, 1933 елда «Яңа милли юл» журналының җиденче саны Х.Шакир өчен зур роль уйный, чөнки анда әлеге шәхеснең Пешавардагы авыр тормышы турында мәкалә басыла, ә журналның икенче битенә Финляндиядән булган балаларның укытучылары белән төшкән фотосурәтләре һәм милли курслар турындагы мәгълүмат куела.  Әле беркем дә 14 елдан соң Хабибрахман Шакир һәм аның гаиләсе өчен Финляндия аларның икенче ватанына әйләнәчәген күз алдына да китерә алмаган.

Һәм 1947 елда Муса Бигиев киңәше белән ул Тампере шәһәренең фин татарлары җәмәгатьчелегенә имам сыйфатында чакырыла. Бу вакытка Х. Шакир Ислам дөньясында танылган һәм авторитетлы галим була. Татар теленнән тыш, ул төрек, гарәп, урду һәм фарсы телләрен дә белгән. Аның төп вазифалары: җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрү, вәгазьләр сөйләү һәм балалар укыту эшләре булган.

Әмма, кызганычка, аның бик күп гыйлемнәре, мөселман җәмәгатьчелегенең көнкүреш тормышында кулланылмаган. Тампереда ул бөтендөнья ислам галимнәре белән аралашуын һәм язышуын дәвам иткән. Әгәр дини мәсьәләләрдә авыр сораулар килеп туса, барысы да аңа мөрәҗәгать итә торган булган. Хабибрахман Шакирның кыйммәтле азсанлы китаплардан торган зур китапханәсе булган. Һәм ул кызыксынучы кешеләргә китапларны алып торырга рөхсәт биргән.


1949 елда Хабибрахман Шакир «Финляндия Ислам Мәҗәлләсе» (Финляндиянең Ислам җыентыгы) дип исемләнгән җыентыкны чыгару

эшенә тотына. Алга таба ул «Ислам Мәҗәлләсе» дигән исем белән чыга. Хабибрахман Шакир бу җыентыкның татар эмиграциясе яшәгән бөтен почмакларга (Төркия һәм Япониягә) кадәр таралу өчен тырыша.

Сәмигулла Вафин (Samiulla Wafin) белән берлектә алар «Дин дәреслеге вә Ислам тарихчәсе» дип аталган китап бастыралар. Х.Шакир шулай ук шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган китап та нәшер итә. Ул үзе дә шигърияттә сәләтле була һәм татар халык көйләрен ярата.

Кызганычка, китап белән килеп туган техник проблемалар иҗатта үзләренең идеяләрен тулысынча тормышка ашырырга бирми. 1966 елда ул Советлар Союзында була ала һәм Зыяэтдин Бабахан, Габдулла Исаев кебек танылган мөселман эшлеклеләре белән очраша.

Аның хатыны Бибирайханә шулай ук гыйлемле хатын-кыз булган һәм камил рәвештә гарәп телен белгән. Ул Тампере татар җәмәгатьчелеге өчен бик күп эшләгән. Замандашлары аның бик әйбәт, ачык кеше булуын ассызыклый. 1972 елда корольнең шәхси чакыруы белән, Хабибрахман Шакир хәләл җефете белән бергәлектә, Согуд Гарәбстанына бара һәм Мәккәдә хаҗ кыла.



**1966 елда Хабибрахман Шакир Советлар Союзына килгәч. Ташкентта үзенең элеккеге дусты Зыяэтдин Бабахан белән.**

Сәфәр вакытында Х. Шакир король Фейсал бине Габделгазиз Әл-Согуд (идарә итү еллары 1964-1975) белән шәхсән таныша.

1974 елда галимнең хәләл җефете Бибирайханә үлә, ә бер

елдан соң 1975 елда Хабибрахман Шакир үзе дә бакыйлыкка күчә. Аларны Хельсинкиның мөселман татар зиратында җирлиләр.




**Хабибрахман Шакир һәм хатыны Бибирайханәнең каберләре (шәхси архивтан).**

Күрүебезчә, Хабибрахман Шакирның тормышы бик авыр һәм үзенчәлекле булган. Меңләгән күлләр иленә эләгер өчен, аңа күп авырлыклар һәм югалтулар кичерергә туры килгән. Бу татар халкының дини һәм милли эшлеклесе булган шәхес тормышының бер өлешен генә сурәтләү иде һәм ул бүгенге заман тикшерүчеләренең дә аерым игътибарын таләп итә.

*Мөхсин НУРУЛЛА язмасы,*

*islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә*

# Корбан

# Корбан ни дигән сүз?

**«Корбан» сүзенең мәгънәсе һәм шәригатьтәге хөкеме**

Корбан – мөэмин-мөселман кешесе тарафыннан билгеле бер вакытта, Аллаһы ризалыгына ирешү нияте белән кылынган гыйбадәтнең бер төредер. Корбанлыкка дөяләр, эре һәм кече мөгезле терлекләрнең һәркайсы яраклыдыр. Корбан дип, чалынган хайванга әйтеләдер.

Корбан гыйбадәте зәкят һәм гает намазлары белән бер вакыттарак, һиҗрәтнең икенче елында вәҗиб кылынган. Бу хакта катгый Коръән аятләре, сахих хәдисләр һәм иҗмагъ (галимнәрнең бердәм карары) бар.

Коръәндәге дәлилләр ошбулардыр:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

**«[Шулай булгач] Раббың өчен намаз укы һәм [Аның исеме белән] корбан чал».**

«Кәүсәр», 108:2

وَالْبُدْنَ جَعَلْنَاهَا لَكُم مِّن شَعَائِرِ اللَّهِ لَكُمْ فِيهَا خَيْرٌ فَاذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَيْهَا صَوَافَّ فَإِذَا وَجَبَتْ جُنُوبُهَا فَكُلُوا مِنْهَا وَأَطْعِمُوا الْقَانِعَ وَالْمُعْتَرَّ كَذَٰلِكَ سَخَّرْنَاهَا لَكُمْ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Зур башлы хайваннарны [дөяләрне] Без сезнең өчен Аллаһының билгеләреннән иттек, аларда сезнең өчен файда бар. Инде [дөяләрне ятып торганда түгел, аякларын] сузган хәлендә чакта [корбан итегез һәм чалган вакытта] алар өстендә Аллаһының исемен искә алыгыз. [Җаннары чыгып] Яннарына аугач, [теләсәгез] алардан ашагыз, канәгатьле булганга да, [сораныр өчен юлыгызга аркылы төшкән] теләнчегә дә ашатыгыз.**

**Без шулай итеп аларны сезгә итагать иттердек [шуңа аларны бәйләп бугазлый аласыз]. Бәлки, сез шөкер итәрсез».**

«Хаҗ», 22:36

Сөннәттә дә дәлилләр бихисап. Шундыйлардан – Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәдән риваять кылынган бер хәдистә: «Корбан гаетенең беренче көнендә Аллаһы Раббүл Гыйззә хозурында корбанлык каны агызудан да сөеклерәк эш юктыр. Хисап көнендә бу хайван мөгезләре, тояклары һәм тиресе белән килеп басар. Корбанлыкның каны әле җиргә коелганчы ук, Аллаһы тарафыннан кабул ителер. Бәс, рәхәтләнеп, кинәнеп чалыгыз корбанлыкларыгызны!»

Икенче бер хәдисне исә Әнәс радыяллаһу ганһе риваять кыла: «Мин Расүлебезнең мөгезләре сау булган аксылрак төстәге ике бәрәнне корбан итеп чалганын күрдем. Ул бер аягы белән хайванны кысып, «Бисмилләһи, Аллаһү әкбәр!» сүзләрен әйтте дә кулындагы пычагы белән бәрәннең бугазын ышкып җибәрде» .

Барлык Ислам галимнәре корбанның диндә хупланган, изге гамәл булып, бәндәне Аллаһыга якынайта торган гыйбадәт булуы хакында уртак фикердә.

## Корбанның шәригатьтәге хөкеме

Хәнәфи мәзһәбендә бер төбәктә даими гомер кичергән (ягъни сәфәрдә булмаган), гает көненә тиешле нисапка тулган байлыкка ия булган хәлдә килеп ирешкән, ирекле (тоткынлыкта булмаган) мөэмин-мөселман бәндәгә елга бер мәртәбә корбанлык хайван бугазлау – вәҗиб хөкемендә. Имам Әбү Хәнифә, имам Мөхәммәд, имам Зөфәр, Хәсән һәм бер чыганакка күрә Әбү Йосыф кебек олы мөҗтәһид галимнәр корбан чалуны вәҗиб гамәл дип бәяләгәннәр.

Корбанның вәҗиб булуын раслап килгән дәлилләрнең берсе – Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән килгән ошбу хәдистер: «Корбан чалырга мөмкинлеге була торып, чалмаган кеше безнең намаз кылу урыныбызга (мәчетебезгә) якын килмәсен!»

Әгәр дә корбан вәҗиб, ягъни мәҗбүри гамәл булмаса, аны калдыручыга бу тикле авыр кисәтү ясалмаган булыр иде. Вәҗиб булган корбан гыйбадәте – билгеләнгән, махсус бер вакытта гына кылына торган гамәл.

Корбанның вәҗиб булуын куәтләгән тагын бер хәдистә: «Әй кешеләр! Һәрбер йорттан елга бер мәртәбә корбан чалу вәҗибтер!» – диелә.

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе хәзрәтләренең: «Расүлебез Мәдинәдә яшәгән ун ел дәверендә, ел саен, бер дә калдырмыйча, корбан чалып килде», – дигән сүзе дә бу карашны ныгытып килә.

Әгәр дә корбан чалырга ниятләгән мөэмин кеше корбанлык хайванны садака итеп кенә биреп җибәрсә (ягъни аны үзе чалмаса яки башка берәүгә кушып чалдырмаса), аның бу гамәле корбан булып саналмас. Корбан чалу хайванның канын агызуны күздә тота. Чалынган малның итен тарату бик хуп күрелсә дә, мәҗбүри түгел.

## Корбанның төрләре

Корбанның ике төре бар: вәҗиб һәм нәфел.

Вәҗиб корбанга түбәндәгеләр керә:

• Нәзер корбаны. Әгәр дә кеше үз-үзенә: «Ошбу дөяне яки сарыкны корбан итеп чалу – минем Аллаһы алдындагы бурычым» яки «Мин бу сарыкны, Аллаһы ризалыгы өчен, корбан итеп чалачакмын», – дисә, аңа, бай яки ярлы булуына карамастан, бу корбанны чалу вәҗиб (мәҗбүри) була.

• Ярлы кеше тарафыннан корбан итеп чалу нияте белән сатып алынган хайван. Әгәр дә нисаб микъдарындагы байлыгы булмаган ярлы кеше корбанлыкка дип сарык сатып алса, аңа бу сарыгын корбан итеп чалу вәҗиб була, чөнки өстендә корбан чалу мөкәлләфияте (бурычы) булмаган

ярлы адәмнең корбанлык хайван сатып алуы аның үз ихтыяры белән корбан чалырга ниятләвен аңлата. Ә бу исә нәзер буларак бәяләнә.

• Хәленнән килгән кешеләрнең Корбан гаете көннәрендә, Аллаһы Тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен, шөкер итү йөзеннән, Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәламнең сөннәтен торгызу һәм гөнаһлардан арыну нияте белән чалынган корбаннар.

• Шөкер корбаны. Корбанның бу төре кыйран һәм тәмәттугъ хаҗы кылучыларга вәҗибтер.

• Кәффарәт корбаны. Бу төр корбан хаҗ вакытында кылынган кайбер хата-кимчелекләргә кәффарәт буларак чалына.

Нәфел корбаннарга:

• Гакыйка корбаны. Бу корбан бала туу сөенеченнән Аллаһы Тәгаләгә биргән олы нигъмәте өчен рәхмәт буларак чалына. «Гакыйка» дип яңа туган нарасыйның башындагы чәчен атыйлар. Гакыйка корбаны – Пәйгамбәребезнең сөннәте. Риваятьләргә караганда, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм оныгы Хөсәен дөньяга килү куанычыннан бер сарык чалган. Бу корбанны бала туган көннән алып, балигъ булганчыга кадәр чалырга була. Шулай да, бу эшне бала туганның 7 нче, 14 нче яки 25 нче көннәрендә эшләү хәерлерәк. Ә инде иң фазыйләтлесе – 7 нче көндә. Шул ук көнне баланың чәче кыркылып, шуның авырлыгы бәрабәрендә алтыннан, көмештән яки акчалата садака бирү бик күркәм булыр.

• Ифрад хаҗы кылган хаҗиларның корбан чалуы. Аларга корбан чалу вәҗиб булмас, үз теләкләре белән нәфел итеп чалсалар, нур өстенә нур булыр.

• Корбан гаете көннәрендә чалынмаган корбан. Мондый корбаннар вәҗиб категориясенә кермәс, бәлки кешенең үзе теләгән вакытта Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү йөзеннән кылынган саваплы гамәл булып язылыр, иншәАллаһ.

# Корбанның шартлары

## Корбанның вәҗиблек шартлары

Хәнәфи мәзһәбендә, корбан гыйбадәте кешегә вәҗиб булсын өчен, аның билгеле күләмдә байлыкка ия булуы шарт. Җитәрлек матди мөмкинлекләре булмаганнарга Корбан гаете көннәрендә мал сую вәҗиб булмас. «Матди мөмкинлекләр» дигәндә, фитыр садакасы бирүне вәҗиб кылган байлык булу күздә тотыла. Бу байлыкны корбанның нисабы дип атыйлар. Корбан нисабы дигәндә, без кешенең зарури (асыл) ихтыяҗларыннан (торак, йорт кирәк-ярагы, транспорт, иң кирәкле кием-салым, үзеңне һәм карамагыңда булганнарны бер ел дәвамында тәэмин итеп торырлык акча) һәм бурычларыннан тыш, 80 грамм алтын яки шул күләмдәге акчага ия булуын аңлыйбыз. Шулай итеп, корбан нисабына ия булган кеше хәлле дип санала һәм аңа корбан чалу вәҗиб була. Бу күләмдәге байлыгы булганнарга ел саен Корбан гаете көннәрендә мал чалу мәҗбүридер.

**Корбанның дөрес булуы өчен кирәкле шартлар:**

а) корбанлык хайван сау-сәламәт, таза булырга тиеш. Малда итенең кимүенә яки саулыгын югалтуга китерерлек җитешсезлекләр булмау шарт. Шәригать галимнәре фикеренчә, дүрт төрле кимчелек, хайванны корбанга чалу өчен, яраксыз хәлгә китерә: сукыр булуы, аксаклык, артык арыклык һәм берәр төрле авыру. Моңа дәлил итеп, Бәраэ бине Газиб хәзрәтләре җиткергән бер хәдис китерелә. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Корбанга чалынасы хайван дүрт төрле кимчелектән ару булырга тиеш: дөм сукырлык, аермачык беленеп торган авырулар, җелекләре корыр дәрәҗәдә арык, хәлсез булу».

Шушыларга таянып, галимнәр кыяс (чагыштыру) юлы белән башка төрле кимчелекләрне дә билгеләгәннәр. Шул җөмләдән, хайванның бер

яки ике күзенең дөм сукыр булуы, корбан чалынасы урынга мөстәкыйль рәвештә барып җитә алмас дәрәҗәдә аксак-чатан булуы, җелеге кору, күпчелек тешләренең коелган булуы, тумыштан ук колаксыз булу, җилеме киселгән булу, борыны киселгән булу, колак һәм койрыкның өчтән бер өлешеннән артыгы киселгән булу, күзләре тонык, томанлы булу һ.б. Гермафродит (ике җенесле) булган яки бары тик нәҗес, шакшы нәрсәләр белән тукланган хайваннарны корбанга чалу тыела. Шакшы нәрсәләр белән тукланган хайванны, итенең исе яхшырсын өчен, аерым урынга бикләп тоткан очракта, корбан итеп чалу рөхсәт ителә. Моның өчен, дөяләрне – 40, сыер малын – 20, ә кәҗә һәм сарыкларны 10 көн бикләп тоту таләп ителә.

Мөгезләре булмаган яки сынган хайваннарны корбанга чалу ярый, чөнки бу корбан гыйбадәтенең хикмәтенә хилафлык китерерлек олы кимчелек булып саналмый. Шулай ук, печелгән хайваннарны чалу да ярый, чөнки аларның итләре тәмлерәк була. Әбү Һөрайра хәзрәтләре радыяллаһу ганһе риваять кылган бер хәдистә: «Аллаһы Расүле корбанга дип чалу нияте белән ике зур, симез печелгән тәкә сатып алды. Аларның берсен ул үзе һәм гаиләсе исеменнән, ә икенчесен өммәте, ягъни Аллаһыдан гайре хак илаһ булмавын һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның колы вә расүле икәнлеген таныган бәндәләр исеменнән чалды», – диелә. Симез, ләкин тире авыруларыннан интеккән малны чалу да рөхсәт ителә, чөнки тире авырулары итнең күләм һәм сыйфатына артык йогынты ясамый. Артык арык, хәлсез хайван исә корбанга бармый, чөнки ябыклык ит күләме белән турыдан-туры бәйле.

Әгәр хайван сатып алынганда таза-сау булып та, соңыннан хасталанса яки анда тора-бара корбанлык итеп чалуга комачаулык кылган кимчелекләрнең берәрсе беленсә, ике төрле юл бар: сатып алган кеше хәлле булса, яңасын алырга тиеш, инде ярлы булып, моңа көче җитмәсә, шул булган хайванын, кимчелекле булса да, корбан итеп чалыр.

б) Корбан гыйбадәте махсус билгеләнгән вакытта үтәлергә тиеш. Бу вакыт – Корбан гаетенең 1 нче, 2 нче һәм 3 нче көннәрен үз эченә ала. Шушы вакыт узганнан соң корбан чалу дөрес булмас. Әлбәттә, бу эш өчен иң хәерлесе – гаетнең 1 нче көне (10 нчы зөлхиҗҗә). Гает намазы укылган шәһәрләрдә һәм авылларда корбанлыклар намаздан соң чалынып, ә гает укылмаган төбәкләрдә – кояш чыкканнан соң. Бу – корбан чалуның башлангыч вакыты. Бу вакыт гаетнең 3 нче көнендә кояш баеганчы дәвам итә. Бәраэ бине Газиб радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән түбәндәгеләрне риваять кыла: «Бу көнне (гает көнне) без иң башта бәйрәм намазын кылырга, аннан соң кайтып, корбаннарыбызны чалырга тиеш. Шулай иткән кеше сөннәтебезне тоткан булыр. Кем дә кем корбанлык хайванын бу вакыттан иртәрәк чалса, аныкы – гаиләсенә иткә дип суелган гадәти сугым гына булып калыр».

Әнәс бине Мәликтән китерелгән икенче бер хәдистә исә Аллаһы Расүле болай дип әйтә: «Кем корбанын гает намазына кадәр чалса, үзе өчен генә чалган булыр. Ә кем дә кем намаздан соң чалса, корбан йоласын үтәгән һәм мөселманнар сөннәтен тоткан булыр» .

Корбан гыйбадәтенең өч көн белән чикләнгән булуы турында Гомәр, Гали һәм Ибнн Габбас радыяллаһу ганһүмәләр кебек сәхабәләр риваять кылган хәдистән укып беләбез: «Корбан чалу көннәре – өчтер, шуларның иң хәерлесе беренче көндер».

Төнге караңгылык төшкәч, корбан чалу мәкруһ санала, чөнки караңгылык аркасында хаталар китәргә мөмкин.

Корбан чалуның вәҗиблеге билгеләнгән шушы вакыт узганчы дәвам итә. Шуңа да, әгәр кеше бәйрәм көннәре башлануга кинәт баеп китсә, Ислам динен кабул итсә яки коллыктан азат булса яки берәр урынга озак вакытка килеп урнашса, аңа гаетнең соңгы көне беткәнче корбан чалу вәҗиб була. Моның нәкъ киресе дә булырга мөмкин. Әгәр дә кеше гает көннәре тәмамланганчы иманыннан язса (мөртәд булса), мохтаҗлыкка

төшсә (малы нисаб микъдарыннан кимесә) яки сәфәргә кузгалса, аның өстеннән корбан чалу бурычы төшә. Ә инде кеше Корбан гаете көннәре узгач мохтаҗлык хәленә төшсә, корбанга яраклы сарык бәясе аның өстенә бурыч булып языла. Байлыгы булган хәлле кеше Корбан гаетенең өч көненең берсендә корбанын чалырга өлгермичә үлеп китсә, бу бурыч аның өстеннән төшкән булып санала. Әгәр фәкыйрь кеше инде корбан чалган булып, соңыннан гает көннәре дәвамында кинәт баеп китсә, иң ышанычлы хөкем буенча, аңа яңадан корбан чалу вәҗиб була, чөнки аның фәкыйрьлек хәлендә чалган беренче корбаны нәфел хөкемендә булып санала.

Корбан чалу эшенә гает намазы бетеп, әле хөтбә тәмамланганчы ук керешү рөхсәт ителсә дә, хөрмәт йөзеннән хөтбәнең бетүен көтү хәерлерәк.

Хаҗиларга гает көнне бәйрәм намазы уку вәҗиб түгел, чөнки алар бу вакытта хаҗ йолаларын үтәү белән мәшгуль булалар. Аларга кояш чыгу белән үк корбан чала башларга ярый.

Корбан чалу гамәле дөрес үтәлсен өчен, аны башкарган урынга да игътибар юнәлтү зарур. Әйтик, гает намазы укылмаган төбәктә шәһәр кешесе исеменнән корбан чалынганда, әлеге зат үзе әле бәйрәм намазын укымаган булса да, корбаны кабул була.

## Кемнәргә корбан чалу вәҗиб?

Түбәндәге сыйфатларга ия булган кешегә генә корбан чалу вәҗиб буладыр:

– Ислам, ягъни мөселман булу;

— гакыл, ягъни кешенең акылга сәламәт булуы;

— балигъ булу;

— хөр, ягъни ирекле булу;

— мокыйм булу, ягъни сәфәрдә булмау;

— фитыр садакасы түләү өчен, тиеш булган күләмдә байлыкка ия булу.

Сәфәрдәге кешегә корбан чалу вәҗиб булмаса да, ул үз теләге белән чала калса, корбаны дөрес булыр. Ләкин бу хөкем кеше корбанлык хайван сатып алганчы сәфәргә чыккан булса гына урынлы. Инде корбанлыкны сатып алганнан соң, сәфәргә кузгалган кешегә килсәк, аңа корбан чалмыйча, алган корбанлыгын кире сатып җибәрү тиешле.

Хатын-кыз иреннән тиешле мәһәрен алгач, хәтта ул кичектерелгән булса да, байлыкка ия булып санала һәм корбан чалырга тиеш була. Шулай ук, үз йорты булып, шунда ире белән бергә гомер кичергән хатын-кызга да, гәрчә иренең аны торак белән тәэмин итү кодрәтеннән килсә дә, корбан чалу кирәк.

Нисаб микъдарына тигез яки аннан артык малга ия булган сабый бала исеменнән дә корбан чалынырга тиеш. Җитәрлек малы булган акылы зәгыйфьрәк кешеләр бала хөкемендә карала, чөнки Әбү Хәнифә хәзрәтләре белән имам Әбү Йосыф карашынча, балигъләек яшенә ирешү һәм камил акыл корбанның вәҗиблек шартларыннан түгел. Имам Мөхәммәд исә балигъльлык һәм акылга бөтен булуны, корбан чалу өчен, кирәкле шартлар рәтенә кертеп карый. Шулай итеп, балигъльккка ирешмәгән сабыйлар һәм акылга зәгыйфь кешеләргә, җитәрлек байлыкка ия булсалар, корбан чалу тиеш булып чыга.

Вакытлыча зиһенен җуеп торганнан соң, кабат үз акылына кайткан кешенең исә хәлен исәпкә алырга кирәк. Бу кеше Корбан бәйрәме көннәрендә үз акылында булмаса, югарыда искә алынган галимнәрнең иҗтиһадларына нигезләнеп фәтва чыгарыла. Инде ул бәйрәм көннәрендә үз акылында булса, корбан чалырга тиеш була.

## Корбан чалу өчен яраклы хайваннар һәм аларның яше

Ислам галимнәре бердәм рәвештә корбанлыкка кече һәм эре мөгезле терлекләр, дөяләр яраклы дигән карарга килгәннәр.

Корбанлыкка дигән сарык малының яше кимендә бер яшь булырга тиеш. Әгәр алты айлык бәрән таза-көр булып, авырлыгы бер яшьлекләрдән ким булмаса, аны да корбанга чалу рөхсәт ителә.

Бер хәдисендә Аллаһы Расүле бу хакта: «Көчегездән килсә, бер яшен тутырып, икенче яше киткән малны гына чалырга тырышыгыз. Бер дә булмаса, алты айлык бәрән суегыз», – дип әйтеп калдырган.

Корбанлык дөяләр, кимендә биш яшьлек, ә сыер малы (монда үгезләр, буйволлар да керә) ике яшен тутырган булырга тиеш. Яше тулып җитмәгән малны чалган очракта, ул корбаннан китми. Иң хәерлесе – ким дигән яшь чигеннән азрак өлкәнрәк булган хайванны чалу.

Сарык малы белән кәҗәләр бер генә кеше исеменнән чалына ала. Дөя, сыер яки буйвол, корбан чалу нияте белән, җиде кешегә кадәр уртак булырга мөмкин. Җәбир радыяллаһу ганһе риваять кылган бер хәдистә бу хакта: «Аллаһы Расүле корбанга дөя яки сыер чалган вакытта, бездән җиде кешегә шул малга уртак булырга боера иде», – дип әйтелә.

Икенче бер хәдистә исә, Җәбир хәзрәтләре: «Хаҗ һәм гомрә вакытларында без Аллаһы Расүле белән корбанга дигән эре малга уртак була идек», – дип хәбәр итә. Җәбир радыяллаһу ганһедән: «Эре малны чалгандагы кебек, кече мөгезле терлеккә дә уртак булырга ярыймы?» – дип сорагач, ул: «Бу бары тик эре терлеккә генә кагыла», – дип җавап кайтарган.

Әгәр уртаклардан берәрсенең генә булса да өлеше $^{1}/_{7}$ дән кимрәк икән, бу малга уртак булганнарның берсенең дә корбаны кабул булмый. Корбан җиде кешедән кабул кылынсын өчен, һәрберсенең тиешле нияте булу шарт. Гәрчә алар хаҗилар булып, бер-берсеннән аермалы хаҗ төрен (кыйран, тәмәттугъ) үтәсәләр дә. Җидедән азрак санда кеше дә бер малга

уртак булырга мөмкин. Әгәр җиде кеше биш яки аннан да артыграк сыерга уртак булсалар, корбаннары дөрес булыр, чөнки һәрберсенә сыерларның $^1/_7$ өлеше тия. Ләкин сигез кеше җиде яки артыграк сандагы сыерга уртак булса, корбаннары дөрес булмас, чөнки бу очракта һәр сыер сигез өлешкә бүленеп, уртакларның һәркайсының өлеше $^1/_7$ ким булып калыр.

Чалынган малның ите уртаклар арасында бүленгәндә, үлчәүгә салып, авырлыкка карап бүленер, гәрчә кайберәүләр үз өлешләреннән баш тарткан булса да. Корбанның ите диндә табыш китерә торган мал (товар) категориясенә кергәнгә, аны сату-алу, алмашу яки башка берәүгә тапшыру кебек мәсьәләләр шәригать кануннары нигезендә хәл ителергә тиеш.

## Корбанның итенә кагылышлы шәригать хөкемнәре

Сәләмә бине Әкъвагъдан риваять кылынган бер хәдисендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Корбан чалган кешенең өендә өч көн узганнан соң корбан итеннән бер кисәк тә калмасын», – дигән. Киләсе елга Аллаһы Расүленнән шул ук мәсьәлә соралгач, ул: «Үзегез ашагыз, башкаларны сыйлагыз һәм теләгән кадәрен үзегезгә калдырыгыз. Былтыр еллар авыр килеп, кешеләр мохтаҗ булганга, аларга ярдәм итүегезне теләгән идем», – дип җавап кайтарган.

Корбан чалган кешегә итнең бер өлешен үзенә һәм гаиләсенең ихтыяҗларына калдырып, калганын садака яки бүләк рәвешендә тарату мөстәхәбтер. Садакага дигән өлеш итнең $^1/_3$ нән дә ким булмаса яхшы. Ә иң хәерлесе – $^1/_3$ ен фәкыйрь вә мохтаҗларга таратып, $^1/_3$ ен дус-иш, күрше-күлән һәм туган-тумачаны сыйлауга тотканнан калган $^1/_3$ ен кешенең үзенә калдыруыдыр. Корбанның итен тулаем үзеңдә калдыру да тыелмый, чөнки корбанның асылы – Аллаһы ризалыгы өчен, хайванның канын коюдыр, ә итне садака итеп өләшү исә мөстәхәб гамәл.

Кемне дә булса карап-тәрбияләп торган фәкыйрь кешегә итне тулаем үзендә калдыру дөресрәк булыр.

Кергән акчасын садака итеп өләшү нияте белән корбан итен сату тыела. Шулай ук, бу ит белән зәкят түләү дә дөрес эш түгел.

*«Корбан» китабыннан*

# Зөлхиҗҗә аеның ункөнлегендә ураза тоту

Зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә ураза тоту мөстәхәб гамәл булып тора. Бу хакта фәнни хезмәтләрдә язылган. Әлеге айның унынчы көне – ул Корбан Гаете һәм бу көннәрдә ураза тоту тыелган. Шуңа күрә, ничек инде бу көнне ураза тоту мөстәхәб гамәл булып санала, дип сорарга мөмкиннәр. Моңа болай дип җавап бирәбез: ураза тотарга тиешле булган өч көн турында сүз барганда, зөлкагъдә аеның соңгы көне һәм зөлхиҗҗә аеның тугыз көне исәпкә алына. Ә сөйләмдә зөлхиҗҗә ае хакында гына әйтелә, чөнки күпчелек көннәр әлеге айга туры килә. Ункөнлек дигәндә, зөлхиҗҗә аеның тугыз көне һәм тәшрикъ көннәреннән соң булган бер көнне дә әйтергә була, әмма беренче фикер дөресрәк булып санала.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһыга гыйбадәт кылырга тиешле булган көннәр арасында зөлхиҗҗә аеның беренче ун көненнән дә сөеклерәк көннәр юк. Бу көннәрдә тоткан һәрбер көн ел дәвамында ураза тотуга тиң. Гыйбадәттә үткәргән һәрбер төн – Кадер киченә тиң». Икенче бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Бу көннәрдә кылган изге гамәлләр өчен җиде йөз савап языла». Әбү Дәрда радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә ураза тотарга, садака бирергә һәм, гөнаһлар гафу ителсен өчен, күбрәк дога кылырга кирәк. Мин Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне бәрәкәтен кулланмаган кешегә бәла килер», – дип әйткәнен ишеттем. Бу айның тугызынчы көнендә (Гарәфә көнендә) ураза тотарга тырышыгыз. Ул көндә шулхәтле саваплар бар, хәтта аны берәү дә санап бетерә алмый». Димәк, тугызынчы көндә ураза тоту кирәк. Анда күп бәрәкәт бар.

Берәү зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә ураза тотса, аңа Аллаһы Тәгалә ун кәрамәт бирер. «Аның тормышы бәрәкәтле булыр, яхшылыгы

арттырылыр, балалалары бәла-казалардан имин булыр, гөнаһлары ярлыканыр, изге гамәлләре өчен әҗер ун тапкыр арттырылыр, үлем сәгате килгәндә, җаны җиңеллек белән чыгар, кабере нурлы булыр, гамәлләр Мизанында саваплары авыр килер һәм җәннәтләрдә югары дәрәҗәдә булыр».

Мөхәррам аеның беренче ун көнендә ураза тоту мөстәхәб гамәл булып тора. Бу – бәрәкәтле көннәр. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Берәү зөлхиҗҗә аеның соңгы көнендә һәм мөхәррам аеның беренче көнендә ураза тотса, үткән елны ураза токан хәлдә озатыр, яңа елны ураза тоткан хәлдә каршы алыр…».

## Гашурә көнендә ураза тоту

Гашурә көнендә ураза тоту шулай ук ел дәвамында кылган гөнаһларның гафу ителүенә сәбәп булып тора. Габдулла бине Гамре радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Гашурә көнендә ураза тоткан кеше ел дәвамында тота алмаган уразалары санынча ураза тоткандай була. Берәү бу көнне садака бирсә, ел дәвамында бирә алмаган садакалары санынча садака биргән була». Әбү Катәдә радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен риваять иткән: «Гашурә көнендә ураза тоту – ел дәвамында кылган гөнаһлар өчен кәффарәт». Ибне Габбас радыяллаһу ганһе: «Рамазан аеннан соң, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тоткан иң изге ураза – ул Гашурә көне уразасы», – дип әйткән.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аеннан соң, күбрәк шәгъбан аенда ураза тота торган иде. Бу хакта Гайшә радыяллаһу ганһә дә искә алган. Ул: «Расүлебез Рамазан аеннан кала бер айны да тулысынча ураза тотып үткәрмәде», – дип хәбәр иткән. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аена бер яки ике көн кала ураза тотмаган. Әмма бу көннәр аның, гадәттә, ураза тота торган көннәренә туры килсә, искәрмә ясаган. Берәү атна саен ураза тотса, ул ураза көннәрен алыштырырга тиеш.

Кешеләр: «Рамазан килде, Рамазан китте», – дип әйтергә тиеш түгел, чөнки бу тупас яңгырый. Кайберәүләр, Рамазан – ул Аллаһының бер исеме, шуңа күрә аңа хөрмәт белән мөрәҗәгать итәргә кирәк, дип әйткән. «Рамазан килде», – дип әйткәнче, «Рамазан ае җитте», – дип әйтү яхшырак. Кайбер галимнәр, Рамазан аен «Рамазан» дип кенә әйтү катгый рәвештә шелтәләнә, дип белдергән. Әгәр инде без: «Рамазанда ураза тоттык», – дип әйтәбез икән, бу рөхсәт ителә, чөнки сүз Рамазан ае турында барганы аңлашыла. Имам Мәлик рахимәһуллаһи һәм аның тарафдарлары хәтта бу очракта да «Рамазан ае» дигән сүз урынына «Рамазан» дип әйтү берсүзсез мәкруһ була дип санаган.

Уразаны берөзлексез ике көн рәттән тотарга ярамый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу рәвешле ураза гыйбадәтен башкаруны тыйган, чөнки ул хәлсезләнүгә китерә. Моннан соң кеше даими кыла торган гыйбадәтләрен үти алмаячак. Әгәр кеше төнлә бераз гына ашаса, бу гамәл тыелмый.

Бәйрәм һәм тәшрикъ көннәреннән кала, елның һәр көнен уразада үткәрү – шелтәле гамәл. Хөрмәтле Гомәр радыяллаһу ганһе Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән:

– Ел буе ураза токан кеше хакында нәрсә әйтерсез? – дип сораган.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Ул ураза да тотмады һәм ифтар да кылмады, – дип җавап биргән .

Ягъни, ул ураза тотмаган кебек, чөнки моны Аллаһының ризалыгыннан башка эшләде һәм шуңа күрә савапка ия булмаячак .

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Сауми висаләдән сакланыгыз (ягъни ел буе ураза тотарга тырышмагыз)», – дигән сүзләренә таянып, кайбер галимнәребез, бәйрәм көннәреннән тыш, елның һәр көнен уразада үткәрүне шелтәләнә торган гамәл, дип санаган. Имам Әгъзам рахимәһуллаһи, Имам Мәлик рахимәһуллаһи һәм Имам Шәфигый рахимәһуллаһи, бәйрәм көннәре булган биш көннән

тыш, елның һәр көнен уразада үткәрүне мәкруһ дип санамаган .

## Мөселман бәйрәмнәре көннәрендә ураза тоту

Рамазан ае бәйрәме, Корбан бәйрәме һәм тәшрикъ көннәрендә (ягъни Корбан бәйрәменең икенче, өченче, дүртенче көннәре) ураза тоту тыелган. Тәшрикъ «итне кисеп алып, киптерү» дигәнне аңлата. Бу көннәрнең болай аталуының сәбәбе бар, чөнки фәкыйрьләр бу көннәрдә үзләренә бирелгән итне кисеп алып, озакка җитсен өчен, киптерә торган булган. Галимнәрнең гомуми фикере буенча, әлеге бәйрәмнәрнең биш көнен уразада үткәрү тыела. Бу көннәрдә мөселманнар Аллаһының кунагы. Аллаһы Тәгалә бу көннәрдә кешеләрнең корбан ите белән сыйлануын һәм фитр садакасы буларак бирелгән акчаларны куллануларын теләгән. Фәкыйрьләр бу көннәрдә байлар кебек яши. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә бу көннәрдә фәкыйрьләрнең дә, байларның да ураза тотуын теләмәгән. Бу көннәрдә ураза ярамый.

*«Ислам юлы» китабыннан*

*н*

# Хәдис

# Җомга намазы китабы

## كِتَابُ الجُمُعَةِ

٢٧٨

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: نَحْنُ الآخِرُونَ السَّابِقُونَ يَوْمَ القِيَامَةِ، بَيْدَ أَنَّهُمْ أُوتُوا الكِتَابَ مِنْ قَبْلِنَا، ثُمَّ هَذَا يَوْمُهُمُ الَّذِي فُرِضَ عَلَيْهِمْ، فَاخْتَلَفُوا فِيهِ، فَهَدَانَا اللَّهُ، فَالنَّاسُ لَنَا فِيهِ تَبَعٌ اليَهُودُ غَدًا، وَالنَّصَارَى بَعْدَ غَدٍ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Без бу дөньяда иң соңгылар, ләкин Кыямәт көнендә, башкаларга Язу безгә караганда иртәрәк бирелгән булса да, без беренчеләр булачакбыз. Аларга да бу көнне хөрмәт итү боерылган иде, ләкин аларның фикерләре бүленде. Безне Аллаһы Үзе моңа китерде, башкалар безгә иярде: яһүдиләр – икенче көнгә (ягъни шимбәгә), насаралар аннан соң килә торган көнгә (якшәмбегә) хөрмәт күрсәтә башладылар» .

٢٧٩

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ: الغُسْلُ يَوْمَ الجُمُعَةِ وَاجِبٌ عَلَى كُلِّ مُحْتَلِمٍ، وَأَنْ يَسْتَنَّ، وَأَنْ يَمَسَّ طِيبًا إِنْ وَجَدَ

Әбү Сәгыйд Әл-Хөдри радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Балигълыкка ирешкән һәрбер кешегә җомга көнне госел коену мәҗбүри. Шулай ук мисвәк белән тешләрен чистарту һәм таба алганда хушбуй куллану да кирәк».

٢٨٠

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: مَنِ اغْتَسَلَ يَوْمَ الجُمُعَةِ غُسْلَ الجَنَابَةِ ثُمَّ رَاحَ، فَكَأَنَّمَا قَرَّبَ بَدَنَةً، وَمَنْ رَاحَ فِي السَّاعَةِ الثَّانِيَةِ، فَكَأَنَّمَا قَرَّبَ بَقَرَةً، وَمَنْ رَاحَ فِي السَّاعَةِ الثَّالِثَةِ، فَكَأَنَّمَا قَرَّبَ كَبْشًا أَقْرَنَ، وَمَنْ رَاحَ فِي السَّاعَةِ الرَّابِعَةِ، فَكَأَنَّمَا قَرَّبَ دَجَاجَةً، وَمَنْ رَاحَ فِي السَّاعَةِ الخَامِسَةِ، فَكَأَنَّمَا قَرَّبَ بَيْضَةً، فَإِذَا خَرَجَ الإِمَامُ حَضَرَتِ المَلَائِكَةُ يَسْتَمِعُونَ الذِّكْرَ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Җомга намазы алдыннан җөнеб вакыттагы кебек госел коенып мәчеткә (алданрак) килгән кеше дөяне корбан чалган кебек булачак. Соңрак барган кеше сыерны корбан итеп чалган кебек, тагын да соңрак барганы – мөгезле сарыкны, тагын да соңрак барганы – тавыкны, моннан да соңрак барганы йомырканы корбан итеп китергән кебек булыр. Минбәрдән вәгазь сөйләр өчен, имам чыккач, аның Аллаһыны зикер итүен тыңларга фәрештәләр җыелыр».

٢٨١

عَنْ سَلْمَانَ الفَارِسِيِّ: لَا يَغْتَسِلُ رَجُلٌ يَوْمَ الجُمُعَةِ، وَيَتَطَهَّرُ مَا اسْتَطَاعَ مِنْ طُهْرٍ، وَيَدَّهِنُ مِنْ دُهْنِهِ، أَوْ يَمَسُّ مِنْ طِيبِ بَيْتِهِ، ثُمَّ يَخْرُجُ فَلَا يُفَرِّقُ بَيْنَ اثْنَيْنِ، ثُمَّ يُصَلِّي مَا كُتِبَ لَهُ، ثُمَّ يُنْصِتُ إِذَا تَكَلَّمَ الإِمَامُ، إِلَّا غُفِرَ لَهُ مَا بَيْنَهُ وَبَيْنَ الجُمُعَةِ الأُخْرَى

Сәлман Әл-Фәриси радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Әгәр кеше җомга көнне госел коенып, булдыра алган кадәр яхшы итеп чистарынып, сакал-чәчләрен тәртипкә китереп, өендә булган ислемайларны сөртеп,

өеннән чыгып, кешеләрне этми-төртмичә мәчеткә килсә, анда фарыз ителгән кадәр намаз укыса һәм имамны тыңлаганда тын гына утырса, ул кешенең узган җомгадан алып, бүгенге җомгага хәтле кылган гөнаһлары гафу ителер».

٢٨٢

عَنْ عُمَرَ بْنَ الخَطَّابِ: إِنَّمَا يَلْبَسُ هَذِهِ مَنْ لَا خَلَاقَ لَهُ فِي الآخِرَةِ. إِنِّي لَمْ أَكْسُكَهَا لِتَلْبَسَهَا

Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Мәчет ишеге каршында мин ефәк киемнәр күреп алдым һәм: «Йә Аллаһының Расүле! Бу киемнәрне сатып алып, җомга көннәрендә яки яныңа илчеләр килгәндә кисәң, яхшы булыр иде», — дип әйттем. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу киемне бары тик мәңгелек дөньяда өлеше булмаган кешеләр генә кия!» — дип җавап бирде. Күпмедер вакыттан соң Пәйгамбәргә бүләк итеп бик күп ефәк күлмәкләр җибәрделәр. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шуларның берсен Гомәр бине Әл-Хаттабка бүләк итте. Ул: «Йә Аллаһының Расүле! Син миңа шушы киемнәрне бирдең, ә үзең Үтәрид саткан киемнәр хакында әйткәнеңне хәтерлисеңме?!» — диде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәллам: «Мин бу киемне син үзең киеп йөрсен дип бүләк итмәдем», — дип җавап бирде, һәм Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе бу киемне Мәккәдә яшәүче мәҗүси булып калган ир туганына бүләк итте».

٢٨٣

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: لَوْلَا أَنْ أَشُقَّ عَلَى أُمَّتِي أَوْ عَلَى النَّاسِ لَأَمَرْتُهُمْ بِالسِّوَاكِ مَعَ كُلِّ صَلَاةٍ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Әгәр бу минем өммәтемә (яки кешеләргә) авыр булмаса, мин һәрбер намаз алдыннан мисвәк белән теш чистартырга боерыр идем».

٢٨٤

عَن أَنَس: أَكْثَرْتُ عَلَيْكُمْ فِي السِّوَاكِ

Әнәс радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Мин сезгә инде күп тапкыр мисвәк куллану кирәклеге хакында сөйләдем».

٢٨٥

عَنِ ابْنِ عُمَرَ: كُلُّكُمْ رَاعٍ، وَكُلُّكُمْ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ، الإِمَامُ رَاعٍ وَمَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ، وَالرَّجُلُ رَاعٍ فِي أَهْلِهِ وَهُوَ مَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ، وَالمَرْأَةُ رَاعِيَةٌ فِي بَيْتِ زَوْجِهَا وَمَسْئُولَةٌ عَنْ رَعِيَّتِهَا، وَالخَادِمُ رَاعٍ فِي مَالِ سَيِّدِهِ وَمَسْئُولٌ عَنْ رَعِيَّتِهِ

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Сез һәрберегез дә – көтүче һәм үзенә ышанып тапшырылган нәрсә өчен җавап бирә. Хаким үз карамагы астында булганнар өчен җаваплы һәм теге дөньяда алар өчен җавап бирәчәк. Ир кеше үз гаиләсен кайгырта һәм аның өчен җавап тотачак. Хатын-кыз иренең йортын саклый һәм аның өчен җавап бирәчәк, ялчы хуҗасының милкен саклый һәм алар өчен җавап тотачак».

٢٨٦

عَنْ عَائِشَةَ: لَوْ أَنَّكُمْ تَطَهَّرْتُمْ لِيَوْمِكُمْ هَذَا

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Кешеләр, җомга намазына Мәдинә янында һәм Әл-Әвәлидә (Мәдинәдән 4 чакрым ераклыкта) урнашкан өйләреннән, тузанлы юллардан барып, шәһәргә мәчеткә килгәндә, тузан һәм тиргә баткан булалар иде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм минем янда булганда, шуларның берсе Пәйгамбәр янына килде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Шушы көнне коенып килсәгез иде!» — диде».

٢٨٧

عَنْ عَائِشَةَ: لَوِ اغْتَسَلْتُمْ

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Ул вакытта кешеләр бөтен эшне үзләре эшләп көн күрә иделәр. Җомга намазына да алар шул эшләгән киемнәреннән килә иде. Шуңа күрә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Шушы көнне госел коенып килсәгез, яхшы булыр иде!» — дип әйтте».

٢٨٨

عَنْ أَبِي عَبْسٍ: مَنِ اغْبَرَّتْ قَدَمَاهُ فِي سَبِيلِ اللَّهِ حَرَّمَهُ اللَّهُ عَلَى النَّارِ

Әбү Габес радыяллаһу ганһедән: «Аллаһы юлында тузанга баткан аякларны Аллаһы Тәгалә ут кагылудан тыйган».

٢٨٩

عَنْ مُعَاوِيَةَ بْنَ أَبِي سُفْيَانَ: وَهُوَ جَالِسٌ عَلَى المِنْبَرِ، أَذَّنَ المُؤَذِّنُ، قَالَ:
اللَّهُ أَكْبَرُ اللَّهُ أَكْبَرُ، قَالَ مُعَاوِيَةُ: «اللَّهُ أَكْبَرُ اللَّهُ أَكْبَرُ»، قَالَ: أَشْهَدُ أَنْ لَا
إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ، فَقَالَ مُعَاوِيَةُ: «وَأَنَا»، فَقَالَ: أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللَّهِ،

فَقَالَ مُعَاوِيَةُ: «وَأَنَا»، فَلَمَّا أَنْ قَضَى التَّأْذِينَ، قَالَ: يَا أَيُّهَا النَّاسُ، إِنِّي سَمِعْتُ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ عَلَى هَذَا المَجْلِسِ، حِينَ أَذَّنَ المُؤَذِّنُ، يَقُولُ مَا سَمِعْتُمْ مِنِّي مِنْ مَقَالَتِي

Өмәмә бине Сәһел бине Хүнәеф радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бервакыт Могавия бине Әбү Суфьян җомга намазында мөнбәрдә утырып торганда, мөәзин азан әйтә башлаган. Могавия аның артыннан ике тапкыр: «Аллаһү әкбәр!» — дип кабатлаган. Мөәзин: «Аллаһыдан башка илаһ юк!» дип шаһитлык бирәм!» (әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһ) — дигәч, Могавия: «Мин дә!» — дигән. «Мөхәммәднең Аллаһының расүле булуына шаһитлык бирәм!» (әшһәдү әннә Мүхәммәдән расүлуллаһ) — дигәч, тагын: «Мин дә!» — дигән. Азаннан соң ул: «Әй кешеләр! Мин, элек мөәзин азан әйткәндә шушы урында утырган Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сез әле генә миннән ишеткән сүзләрне әйткәнен ишеттем!» — дигән».

٢٩٠

عَنْ سَهْلِ بْنِ سَعْدٍ السَّاعِدِيَّ: مُرِي غُلَامَكِ النَّجَّارَ، أَنْ يَعْمَلَ لِي أَعْوَادًا، أَجْلِسُ عَلَيْهِنَّ إِذَا كَلَّمْتُ النَّاسَ. أَيُّهَا النَّاسُ، إِنَّمَا صَنَعْتُ هَذَا لِتَأْتَمُّوا وَلِتَعَلَّمُوا صَلَاتِي

Сәһел бине Сәгъд Әс-Сәгыйди радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бер көнне бер төркем кешеләр арасында Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетенең мөнбәре нинди агачтан эшләнгән булуы турында бәхәс чыккан. Шуннан соң алар Сәһелдән бу хакта сораганнар һәм ул болай дип әйткән: «Аллаһы белән ант итәм, мин аның нинди агачтан эшләнгәнен бик яхшы беләм. Мин аны урнаштырганнарын да, аңа

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең утырганын да күрдем. Ә аңа кадәр ул бер хатынга: «Синең колың булган балта остасы миңа кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә утырып торырга агачтан берәр нәрсә ясап бирсен әле», — дип әйткән. Шул хатын әмере белән балта остасы тәмәриск дигән агачтан аңа мөнбәр ясап китергән. Пәйгамбәребезнең боерыгы буенча аны монда урнаштырдылар. Мин Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу мөнбәрдә намаз укыганын күрдем. Ул мөнбәрдә килеш тәкбир әйтте һәм рөкүгъ кылды. Шуннан соң, мөнбәрдән төшеп, аның беренче баскычы янында сәҗдә кылды һәм яңадан мөнбәргә менде. Намазын төгәлләгәнче ул шулай эшләде. Намаз беткәч, ул кешеләргә борылды һәм: «Әй, кешеләр, мин моны сез минем үрнәгемә иярсен һәм миннән намаз укырга өйрәнсеннәр өчен эшләдем», — диде».

٢٩١

عَنْ عَمْرو بْن تَغْلِبَ: أَمَّا بَعْدُ فَوَاللَّهِ إِنِّي لَأُعْطِي الرَّجُلَ، وَأَدَعُ الرَّجُلَ، وَالَّذِي أَدَعُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِنَ الَّذِي أُعْطِي، وَلَكِنْ أُعْطِي أَقْوَامًا لِمَا أَرَى فِي قُلُوبِهِمْ مِنَ الجَزَعِ وَالهَلَعِ، وَأَكِلُ أَقْوَامًا إِلَى مَا جَعَلَ اللَّهُ فِي قُلُوبِهِمْ مِنَ الغِنَى وَالخَيْرِ، فِيهِمْ عَمْرُو بْنُ تَغْلِبَ

Гамре бине Тәгълиб радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бер көнне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә акча (яки әсирләр) китерделәр һәм ул әлеге табышны кешеләр арасында бүлә башлады. Кайбер кешегә ул нәрсәдер бирде, кайберләренә бернәрсә дә бирмәде. Шуннан соң аңа бернәрсә дә алмаган кешеләрнең канәгатьсезлек белдерүләре хакында хәбәр килеп иреште. Шул чакта ул, минбәргә менеп: «Аллаһы белән ант итәм, чыннан да, мин кемгәдер нәрсәдер бирәм, ә кемгәдер бирмим. Ләкин мин бернәрсә дә бирелмәгән кешеләрне катырак яратам.

Биргәннәргә килгәндә, мин аларның күңелләрендә сабырсызлану һәм тынычсызлык булганын күрәм, шуңа күрә бүләк бирәм. Ә башкаларны мин Аллаһы Тәгалә алар күңеленә салган байлык һәм нигъмәткә ышандырып калдырам. Алар арасында – Гамре бине Тәгълиб тә бар», — дип әйтте. Гамре бине Тәгълиб: «Аллаһы белән ант итәм, бу сүзләр минем өчен яхшы дөяләргә хуҗа булудан да кадерлерәк иде», — дигән».

٢٩٢

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ: أَيُّهَا النَّاسُ إِلَيَّ، فَثَابُوا إِلَيْهِ، ثُمَّ قَالَ: أَمَّا بَعْدُ، فَإِنَّ هَذَا الْحَيَّ مِنَ الأَنْصَارِ، يَقِلُّونَ وَيَكْثُرُ النَّاسُ، فَمَنْ وَلِيَ شَيْئًا مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ، فَاسْتَطَاعَ أَنْ يَضُرَّ فِيهِ أَحَدًا أَوْ يَنْفَعَ فِيهِ أَحَدًا، فَلْيَقْبَلْ مِنْ مُحْسِنِهِمْ وَيَتَجَاوَزْ عَنْ مُسِيِّهِمْ

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм минбәргә менде, Аллаһыны мактады һәм Аңа рәхмәт әйтте. Аннары: «Әй кешеләр! Минем яныма килегез», — диде. Кешеләр аның янына җыелгач: «Тора-бара әнсарларның саны кимер, ә башка кешеләр күбәер. Мөхәммәд өммәтенең бер өлешенә җитәкче булачак кеше, берәүләргә файда, икенчеләргә зыян китерә алган хәлдә, әнсарлардан яхшы эш эшләүчеләрнең эшләрен кабул итсен, начар эш эшләгәннәрен гафу итсен», — дип сөйләде».

٢٩٣

عَنْ جَابِرِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ: جَاءَ رَجُلٌ وَالنَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَخْطُبُ

النَّاسَ يَوْمَ الجُمُعَةِ، فَقَالَ: أَصَلَّيْتَ يَا فُلَانُ؟ قَالَ: لَا، قَالَ: قُمْ فَارْكَعْ رَكْعَتَيْنِ

Җәбир бине Габдулла радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм җомга вәгазе сөйләгәндә, мәчеткә бер кеше керде. Пәйгамбәр аннан: «Йә фәлән! Намаз укыдыңмы?» — дип сорады. Теге: «Юк», — диде. Пәйгамбәр: «Алайса, бас һәм ике рәкәгать намаз укы!» — дип әйтте».

٢٩٤

عَنِ أَبي هُرَيْرَةَ: إِذَا قُلْتَ لِصَاحِبِكَ يَوْمَ الجُمُعَةِ: أَنْصِتْ، وَالإِمَامُ يَخْطُبُ، فَقَدْ لَغَوْتَ

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Имам җомга вәгазен сөйләгәндә, син үз янында торучыга: «Сөйләшмә, хотбә тыңла!» — дип әйтсәң, үзең артык сүз сөйләшкән буласың».

٢٩٥

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ: فِيهِ سَاعَةٌ، لَا يُوَافِقُهَا عَبْدٌ مُسْلِمٌ، وَهُوَ قَائِمٌ يُصَلِّي، يَسْأَلُ اللَّهَ تَعَالَى شَيْئًا، إِلَّا أَعْطَاهُ إِيَّاهُ وَأَشَارَ بِيَدِهِ يُقَلِّلُهَا

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бу көндә шундый вакыт бар: әгәр Ислам динен тотучы бәндә шул вакытта намаз укыса һәм дога кылып, Аллаһыдан нәрсә булса да сораса, Аллаһы аңа сораганын бирер», — диде һәм ул вакытның бик кыска икәнлеген кулы белән күрсәтте».

# Ике гает китабы

## أَبْوَابُ العِيدَيْنِ

٢٩٩

عَنِ البَرَاءِ: إِنَّ أَوَّلَ مَا نَبْدَأُ مِنْ يَوْمِنَا هَذَا أَنْ نُصَلِّيَ، ثُمَّ نَرْجِعَ، فَنَنْحَرَ
فَمَنْ فَعَلَ فَقَدْ أَصَابَ سُنَّتَنَا

Әл-Бәраэ радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Хакыйкатьтә, бу көнне без иң элек гает намазы укырга, соңыннан кайтып корбан чалырга тиешбез. Шулай эшләгән кеше безнең сөннәтебезгә туры китереп эшләгән була», – дип әйткәнен ишеттем.

٣٠٠

عَنِ البَرَاءِ بْنِ عَازِبٍ: مَنْ صَلَّى صَلاَتَنَا، وَنَسَكَ نُسُكَنَا، فَقَدْ أَصَابَ
النُّسُكَ، وَمَنْ نَسَكَ قَبْلَ الصَّلَاةِ، فَإِنَّهُ قَبْلَ الصَّلَاةِ وَلَا نُسُكَ لَهُ. شَاتُكَ
شَاةُ لَحْمٍ. نَعَمْ وَلَنْ تَجْزِيَ عَنْ أَحَدٍ بَعْدَكَ

Әл-Бәраэ бине Газиб радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Бервакыт Корбан гаете көнендә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм гает намазыннан соң кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать итә һәм: «Кем безнең кебек намаз укый һәм безнең кебек корбан чала – ул дөрес эшли. Кем корбанын намазга кадәр чала, бөтенләй корбан чалмаган булып санала», – дип әйтә. Әбү Бурда бине Нийяр, Әл-Бәраэнең әнисенең абыйсы: «Йә Расүлуллаһ! Мин корбанымны намазга кадәр чалдым, чөнки бүген гает

буласын белдем, кешеләр ашарлар һәм эчәрләр дип, минем корбанымның беренче чалынуын теләдем! Шуңа күрә дә мин үземнең сарыгымны чалдым һәм гает намазына ашап килдем», – дип әйтә. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Синең сарыгың бары иткә генә бара», – дип җавап бирә. Әбү Бурда: «Йә Расүлуллаһ! Безнең әле кечкенә кәҗәбез бар, ул минем өчен ике сарыктан да кадерлерәк. Ул корбанны алыштыра аламы?» – дип сорый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әйе, ләкин синнән соң болай эшләү беркемнән дә кабул ителмәячәк!» – дип әйтә.

٣٠١

عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ: مَا العَمَلُ فِي أَيَّامٍ أَفْضَلَ مِنْهَا فِي هَذِهِ. قَالُوا: وَلَا الجِهَادُ؟ قَالَ: وَلَا الجِهَادُ، إِلَّا رَجُلٌ خَرَجَ يُخَاطِرُ بِنَفْسِهِ وَمَالِهِ، فَلَمْ يَرْجِعْ بِشَيْءٍ

Ибне Габбас радыяллаһу ганһедан тапшырыла: «Изге гамәлләр кылу өчен, шушы ун көннән дә яхшырак көн юк». Кешеләр: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдәме?» – дип сорый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта ул да, үзенең гомере һәм байлыгы белән, үзен һәм якыннарын дошманнан яклап, үзе бер файда да күрмәгән очрактан кала», – дип җавап бирә.

٣٠٢

عَنْ عَائِشَةَ: دَعْهُمْ أَمْنًا بَنِي أَرْفِدَةَ. يَعْنِي مِنَ الأَمْنِ

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Мин Гает көнендә мәчет янында сөңгеләр белән уйнаучы эфиопларны карап торганда, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм мине чит күзләрдән яшереп каплап тора иде. Гомәр аларны туктатырга керешкәч, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Калдыр аларны, уйнасыннар, Әрфид нәселе минем яклавым астында!» – диде.

# Истиска намазы китабы

## كِتابُ الاِسْتِسْقاءِ

٣٠٥

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ: اللَّهُمَّ سَبْعٌ كَسَبْعِ يُوسُفَ

Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Аллаһы! Аларга Йосыф галәйһиссәлам вакытындагы кебек җидееллык корылык җибәр!» – дигән, һәм моннан соң, бик коры ел булып, бөтен нәрсә юкка чыккан. Ә кешеләр хәтта үләксә һәм хайван тиресен ашарга мәҗбүр булганнар. Күккә караган кешегә ачлыктан анда төтен күренә кебек тоелган. Шунда Әбү Суфьян Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килгән дә: «Йә Мөхәммәд! Син Аллаһыга буйсынырга һәм туганнарга карата яхшылык кылырга кушасың, ә синең халкың һәлак була! Аллаһыга безне бу корылык афәтеннән коткаруын сорап дога кыл!» – дигән.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

فَٱرْتَقِبْ يَوْمَ تَأْتِى ٱلسَّمَآءُ بِدُخَانٍ مُّبِينٍ ﴿١٠﴾ يَغْشَى ٱلنَّاسَ ۖ هَٰذَا عَذَابٌ
أَلِيمٌ ﴿١١﴾ رَّبَّنَا ٱكْشِفْ عَنَّا ٱلْعَذَابَ إِنَّا مُؤْمِنُونَ ﴿١٢﴾ أَنَّىٰ لَهُمُ ٱلذِّكْرَىٰ
وَقَدْ جَآءَهُمْ رَسُولٌ مُّبِينٌ ﴿١٣﴾ ثُمَّ تَوَلَّوْا۟ عَنْهُ وَقَالُوا۟ مُعَلَّمٌ مَّجْنُونٌ ﴿١٤﴾
إِنَّا كَاشِفُوا۟ ٱلْعَذَابِ قَلِيلًا ۚ إِنَّكُمْ عَآئِدُونَ ﴿١٥﴾ يَوْمَ نَبْطِشُ ٱلْبَطْشَةَ
ٱلْكُبْرَىٰٓ إِنَّا مُنتَقِمُونَ

**«[Расүлем! Кяферләрдән чиккән газапларың синең кебек рәхмәт пәйгамбәрен дә аларга каршы бәддога кылырлык чиккә җиткерде, инде] Күкнең ап-ачык төтен китерәсе көнен көт! [Бу төтен] Ул [мөшрик] кешеләрне каплап алачак. [Алар әйтәчәкләр] «Бу – тилмерткеч газап! Ий Раббыбыз! Бездән бу газапны ал! Һичшиксез, [ул чакта] без иман китерәбез». [Болай әйтүен әйтәчәкләр, әмма] Аларга үгет алу кайда? Югыйсә [могҗизалары] ап-ачык [булган синең кебек] расүл аларга килгән иде инде. Шуннан соң алар аңардан йөз чөерделәр һәм [кайберләре]: «Өйрәтелгән тиле», – дигәннәр иде. [Шулчак Раббылары аларга болай дип җавап бирде:] «Без газапны [сездән] бераз алабыз, [әмма ул вакытта] сез [көфергә] кайтасыз». [Расүлем! Син] Нык бер тоту белән Безнең [кяферләрне] җәзалаячак көн [Бәдер көне белән Кыямәт көнен көт]! Һичшиксез, Без – [иртәме-соңмы, һичшиксез, аларга] җавап буларак җәза бирүчебез».**

«Әд-Духан / Төтен», 44:10-16

٣٠٦

عَنْ أَنَس بْن مَالِكٍ: اللَّهُمَّ اسْقِنَا، اللَّهُمَّ اسْقِنَا، اللَّهُمَّ اسْقِنَا.

اللَّهُمَّ حَوَالَيْنَا، وَلَا عَلَيْنَا، اللَّهُمَّ عَلَى الآكَامِ وَالجِبَالِ وَالآجَامِ وَالظِّرَابِ وَالأَوْدِيَةِ وَمَنَابِتِ الشَّجَرِ

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Җомга көннәренең берсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хотбә сөйләгән вакытта минбәр каршындагы ишектән бер кеше керә. Бу кеше утырып та тормыйча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яны-

на килеп: «Йә Аллаһының Расүле! Корылык сәбәпле, малларыбыз кырыла, кешеләрнең ашар ризыклары аз калып бара. Аллаһыдан безгә яңгыр бирүен сора!» – дип мөрәҗәгать итә. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кулларын күккә күтәрде һәм: «Йә Аллаһы! Безгә яңгыр җибәр! Йә Аллаһы! Безгә яңгыр җибәр! Йә Аллаһы! Безгә яңгыр җибәр!» – диде. Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе: «Һәм Аллаһы белән ант итәм, бу вакытта без күктә бернинди болыт та күрмәдек. Ә безнең белән Сәʼл тавы арасында болыт килүен күрмәслек бернинди йорт та, башка киртәләр дә юк иде. Шулвакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм артыннан рәвеше белән калканга охшаган болыт килеп чыкты. Ул күкнең яртысын чолгап алгач, тарала башлады. Аннан соң яңгыр коярга тотынды һәм без икенче җомгага кадәр кояш күрмәдек. Киләсе җомгада, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вәгазь сөйләгәндә, шул ук ишектән бер кеше керде һәм, утырып та тормыйча, аңа: «Йә Аллаһының Расүле! Яңгыр аркасында малларыбыз кырыла, юллардан йөрерлек түгел. Аллаһыдан яңгырны туктатуын сора», – дип мөрәҗәгать итә. Шунда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кулын күккә күтәрде һәм: «Йә Аллаһы! Әлеге яңгырны безгә түгел, ә безнең әйләнә-тирәбездәге тау-үзәннәргә яудыр!» – дип дога кылды. Моннан соң яңгыр туктады. Ә без мәчеттән чыкканда, атна буе күренмәгән кояш инде балкый иде», – дигән.

٣٠٧

عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ: اللَّهُمَّ أَغِثْنَا، اللَّهُمَّ أَغِثْنَا، اللَّهُمَّ أَغِثْنَا

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Җомга көннәренең берсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хотбә сөйләгән вакытта берничә кеше, урыннарыннан торып, аңа: «Йә Аллаһының Расүле! Яңгырлар туктап, корылык башланды. Агачлар корып бетеп, кызыл төскә керделәр. Малларыбыз кырыла. Аллаһыдан безгә

яңгыр җибәрүен сорап дога кыл!» – диделәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Аллаһы! Безгә яңгыр җибәр!» – дип ике мәртәбә кабатлады. Аллаһы белән ант итәм, бу вакытта күк йөзендә бер болыт әсәре дә юк иде! Кинәт болытлар пәйда булып, яңгыр коярга тотында. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, минбәрдән төшеп, намаз укытты. Намаз тәмамлангач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм китеп барды, ә яңгырлар киләсе җомгага кадәр туктамады. Киләсе җомгада Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вәгазь сөйләгәндә кешеләр: «Көчле яңгырлар сәбәпле йортларыбыз ишелә, юлларда йөрерлек түгел. Аллаһыдан яңгырның туктавын сора!» – дип мөрәҗәгать иттеләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм елмаеп: «Йә Аллаһы! Әлеге яңгырны безгә түгел, ә безнең әйләнә-тирәбездәге тау-үзәннәргә яудыр!» – дип әйтте. Мәдинәне чолгаган болытлар таралды, яңгырлар Мәдинә читендәге үзәннәрдә ява башлады. Мәдинәгә шул яңгырдан башка бер тамчы да төшмәде, әйтерсең лә, кемдер шәһәр өстендә чатыр тотып торды».

٣٠٨

عَنْ عَائِشَةَ: اللَّهُمَّ صَيِّبًا نَافِعًا

Гайшә радыяллаһу ганһәдән тапшырыла: «Яңгыр күргәч, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Аллаһы! Әлеге яңгыр зыян китермәсен, бәрәкәт кенә китерсен!» – дип әйтә иде».

٣٠٩

عَنِ ابْنِ عَبَّاسٍ: نُصِرْتُ بِالصَّبَا، وَأُهْلِكَتْ عَادٌ بِالدَّبُورِ

Ибне Габбастан тапшырыла: «Көнчыгыш җиле миңа ярдәмгә җибәрелде, ә Гад кавеме көнбатыш җиле белән һәлак ителде».

٣١٠

عَنِ ابْنِ عُمَرَ: اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي شَامِنَا، وَفِي يَمَنِنَا قَالَ: قَالُوا: وَفِي نَجْدِنَا؟ قَالَ: اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي شَامِنَا وَفِي يَمَنِنَا قَالَ: قَالُوا: وَفِي نَجْدِنَا؟ قَالَ: هُنَاكَ الزَّلَازِلُ وَالفِتَنُ، وَبِهَا يَطْلُعُ قَرْنُ الشَّيْطَانِ

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә, Аллаһы, безнең Шам һәм безнең Йәмәндә безгә бәрәкәт-ярдәм бир!» — дип әйткән. Аннан: «Ә безнең Нәҗедтә?» – дип сораганнар. Җавап бирмичә, ул тагын кабатлаган. Аннан тагын: «Ә безнең Нәҗедтә?» — дип сораганнар. Шунда ул: «Анда җир тетрәүләр һәм фетнәләр булачак һәм ул урыннан шәйтанның мөгезе күтәреләчәк», – дип әйткән.

٣١١

عَنِ ابْنِ عُمَرَ: مِفْتَاحُ الغَيْبِ خَمْسٌ لَا يَعْلَمُهَا إِلَّا اللَّهُ: لَا يَعْلَمُ أَحَدٌ مَا يَكُونُ فِي غَدٍ، وَلَا يَعْلَمُ أَحَدٌ مَا يَكُونُ فِي الأَرْحَامِ، وَلَا تَعْلَمُ نَفْسٌ مَاذَا تَكْسِبُ غَدًا، وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ، وَمَا يَدْرِي أَحَدٌ مَتَى يَجِيءُ المَطَرُ

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән тапшырыла: «Яшерен нәрсәнең ачкычына  биш әйбер керә, алар хакында Аллаһыдан башка беркем дә белми: иртәгесе көнне нәрсә буласын, хатынның карынында нәрсә яшеренгәнен, иртәгә нәрсәгә ирешәсен, нинди җирдә үләсен һәм кайчан яңгыр явасын беркем дә белми».

*«Зөбдәтел-Бохари» хәдисләр җыентыгыннан*

# Тәфсир

# Әюб галәйһиссәлам кыйссасы

Әюб галәйһиссәлам чын диндар кеше сыйфатларын һәм хакыйкый сабырлык үрнәкләрен үзендә гәүдәләндергән, исәпсез-хисапсыз байлыкларга ия булган. Аңа караган җирләрнең – чиге, ә көтүлекләрнең саны булмаган. Әмма күпсанлы балалары иң кадерле байлыгы булып торган.

Шул ук вакытта Әюб галәйһиссәлам үзенең кешелекле булуы һәм юмартлыгы белән аерылып торган. Ул үз байлыгын Аллаһы риза булырлык эшләр өчен тотып, барысына – тол хатыннарга яки ятимнәргә, хәерчеләргә киң күңел белән ярдәм иткән. Шул рәвешле Әюб галәйһиссәлам үзенең Раббысына рәхмәтен белдергән һәм Аңа көндезләрен һәм төннәрен гыйбадәт кылган. Аның намазлары ихласлылык һәм Аллаһыга мәхәббәт белән сугарылган булган. Яратучы Зат Үзе үк Әюб галәйһиссәламнең сабырлыгын мактаган! Шуңа күрә җирдәге һәм күктәге фәрештәләр аңа кунакка килгәннәр һәм аңа изге дога кылганнар.

Әмма иблисне көнчелек хисе биләп алган. Ул пәйгамбәрнең юлдан язуын, буйсынучанлык күрсәтмәвен һәм Аллаһының рәхмәтеннән колак кагуын теләгән. Бервакыт ул Аллаһыга шундый үтенеч белән мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһы! Әюб бик күп гыйбадәт кыла, әмма теләсә нинди башка кол да, шундый ук байлыклар бирелсә, гыйбадәтләрне кылыр иде. Ул Сине бүләк ителгән игелекләр өчен мактый. Әмма, әгәр дә Син аңа афәтләр җибәрсәң һәм әлеге байлыклардан аерсаң, аның хакыйкый ниятләре ачык күренәчәк, һәм ул Сиңа каршы килә башлаячак.

Шулай итеп, иблис Аллаһы Тәгаләгә Әюб галәйһиссәламнең ихласлыгын сынарга тәкъдим иткән. Моңа рөхсәт алып, ул үзенә барлык гыйфритләрне (җеннәрне) җыйган һәм аларга Әюб галәйһиссәламнең барлык мал-мөлкәтен таларга яки юкка чыгарырга һәм аны туры юлдан яздырырга әмер биргән. Ул чагында күктән ут ява башлаган һәм ул ут Әюб

галәйһиссәламгә караган барлык көтүлекләрне көтүчеләре белән бергә юк иткән. Шуннан соң шәйтан, бер көтүче кыяфәтенә кереп, күз яшьләре белән Әюб галәйһиссәламгә килгән:

– Күрәсеңме, синең Раббың нәрсә эшләде? Синең барлык көтүлекләрең көтүчеләре белән бергә янды, алар көлгә әйләнде. Бары миңа берүземә генә котылу насыйп булды.

Әюб галәйһиссәлам бар сабырлыгын учына җыеп, Аллаһыга тәвәккәллек кылып болай дип әйткән:

– Күңелсезләнмә! Миндә булган барлык мал-мөлкәтне һәм байлыкны миңа Раббым бирде. Хәзер Ул аларның барысын да алды. Ул – Хак Хуҗа, теләгән вакытта – бүләкли, теләгән чагында – кире ала.

Боларны әйтеп, Әюб галәйһиссәлам гыйбадәт кылуын дәвам иткән. Мәлгунь шәйтан Әюб галәйһиссәламгә шакката һәм кырын эшен ахырына җиткерергә теләп, аның җирләренә, бакчаларына һәм чәчүлекләренә дә зыян китерергә уйлаган. Алар барысы да көчле давыллар һәм су басулар белән юкка чыккан. Игенче кыяфәтенә кереп, шәйтан янә Әюб галәйһиссәлам янына килгән. Беренче мәртәбә килгәндә күргән кебек, ул аны гыйбадәт кылган хәлдә очраткан һәм такмаклап еларга тотынган, әмма тагын шул ук җавапны ишеткән.

Шәйтанның тырышлыклары икенче килүендә дә, аннары да уңыш белән төгәлләнмәгән. Зур югалтуларга да карамастан, Әюб галәйһиссәлам үз Раббысын зикер кылуны дәвам иткән, үзенең язмышына риза булып ныклык һәм сабырлык күрсәткән. Шәйтанның көнчелеге һәм үче тагын да көчәйгән. Ул янә Аллаһыга мөрәҗәгать иткән:

– Ий Аллаһы! Аның барлык мал-мөлкәте һәм байлыгы юкка чыгарылды, әмма аның барлык балалары да исән, димәк анда юкка чыгарылганны кабаттан кайтару өмете яши. Әгәр аны балалары белән сынасаң, Син аның сабырлыгы һәм буйсынучанлыгы ихлас булмавын күрерсең.

Аллаһы Тәгалә шәйтанга боларны эшләргә дә рөхсәт биргән. Мәлгунь шәйтан җил-давыл чакырган һәм Әюб галәйһиссәламнең балалары яшәгән йортларны җимерткән. Алар барысы да җимерекләр астында калып үлгәннәр.

– Ий Әюб! Күрәсең, кылган гыйбадәтләрең синең Раббың өчен берни дә түгел икән, – дип котырта башлаган. – Кара, Ул сиңа ничек ачуланган!

Үз балаларын кызганып, Әюб галәйһиссәлам еларга тотынган. Моны күреп, шәйтан шатланган, әмма шул мизгелдә Әюб галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Минем балаларымны дөньяга җибәрүче – Аллаһы. Ул – аларга тормыш бүләк иткән һәм Ул – тормыштан мәхрүм итүче. Барлык карарлар да бары Аллаһы Тәгаләнеке генә. Ул – Бирүче һәм Ул – Алучы.

Шәйтанның ярсуының, котырынуының чиге булмый: нинди иман, нинди сабырлык, нинди тәвәккәллек соң бу?! Һәм ул янә, Әюб галәйһиссәламне авыру белән сынау өчен Аллаһыга мөрәҗәгать иткән. Аллаһы Тәгалә янә рөхсәт биргән. Әмма Әюб галәйһиссәламнең теленә, йөрәгенә һәм акылына кагылуны тыйган. Шәйтанга монысы да җитәрлек булган. Һәм бервакыт, Әюб галәйһиссәлам гыйбадәт кылганда, сәҗдә вакытында шәйтан аның борынына өргән. Әлеге утка охшаш ләгънәтле сулышны алганнан соң, ул Әюб тәненең барлык өлешләренә дә үтеп кергән. Аның башыннан, күзеннән, теленнән һәм йөрәгеннән кала бар тәне яралар һәм эренле шешләр (үлекләр) белән капланган, ул шешәргә һәм кычытырга тотынган… Көннән-көн Әюб галәйһиссәламнең авыруы көчәйгән.

Якыннары һәм туганнары, хәтта аңа иман китерүчеләр дә, аны ташлап киткәннәр. Янында бары сөекле хатыны Рәхимә генә калган. Ул Әюб галәйһиссәламне бер мизгелгә дә калдырып китмәгән һәм, ирен дәвалау өчен, кулыннан килгәннең барын да эшләгән. Ә бервакыт Рәхимә Әюб галәйһиссәламнән, саулык-сәламәтлеккә ирешү өчен, дога кылырга сораган. Әюб галәйһиссәлам болай дип әйткән:

– Мин иминлектә һәм сәламәт хәлдә ничә ел яшәдем?

– Сиксән ел.

– Ә бу авыру белән мин ничә ел яшәдем?

– Җиде (яки унҗиде) ел.

– Мин иминлектә, рәхәтлектә ничә ел яшәгән булсам, шул ук гомерне авыру хәлемдә дә сабыр итеп үткәрергә, аннары гына шифа сорарга тиешмен.

Авыру артканнан арта барган һәм Әюб галәйһиссәламне шәһәрдән куып чыгарганнар. Кешеләргә күрсәтми генә хатыны Рәхимә аны үз аркасына салып күтәреп чыккан. Башкалар Әюб галәйһиссәламнән йөз чөерсәләр дә, хатыны Рәхимә иреннән баш тартмаган, булдыра алганча аны тәрбия кылган. Әюб галәйһиссәлам, бик авыр хәлдә булуына карамастан, үзенең бар вакытын Аллаһыны зикер итүгә багышлаган. Иртән Рәхимә ризык эзләп шәһәргә китә торган булган, беркем дә аны эшкә алмаган. Аннары, яшәр өчен бернинди мал-мөлкәтсез калганнан соң, төшенкелеккә бирелеп, ул үзенең озын һәм куе чәчләрен кискән һәм аларны бай гаиләдә яшәүче бер кызга саткан.

Рәхимәнең булган акчасына кирәкле азык-төлек сатып алуы хакында шәһәр халкына да билгеле булган. Аның турында гайбәт тарата башлаганнар. Әлеге хәбәрләр Әюб галәйһиссәламгә дә барып җиткән һәм ул болай дип әйткән:

– Әгәр мин бу авырудан терелсәм, мин сине җәзалаячакмын, йөз таяк бирәчәкмен.

Хәбәр ителә ки: Әюб галәйһиссәлам әлеге авыру белән җиде ел дәвамында җәфа чиккән, икенче бер риваять буенча ул унҗиде ел авырган. Әмма шушы вакыт эчендә ул бер тапкыр да үзенең чиреннән зарланмаган. Ул сабырлык күрсәткән һәм Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белдергән.

Бервакыт Әюб галәйһиссәлам янына, хәлен белергә дип, өч кеше килгән. Һәм сөйләшү барышында аларның берсе болай дип әйткән:

– Әюб авыр бәлагә юлыкты. Озак вакыт үтсә дә, аңа Аллаһының рәхмәте ирешмәде инде. Аллаһы Тәгалә аннан йөз чөергәндер.

Әлеге сүзләр Әюб галәйһиссәламне бик тә борчуга салган һәм күңелен төшергән: «Шулкадәр үк көчле афәтме бу? Дин кардәшләрем Аллаһы миннән йөзен чөерде дип уйлый башлаганнар», – дип уйланган. Һәм шул чагында ул Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать иткән. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَأَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُۥٓ أَنِّى مَسَّنِىَ ٱلضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ ٱلرَّٰحِمِينَ ﴿٨٣﴾ فَٱسْتَجَبْنَا لَهُۥ فَكَشَفْنَا مَا بِهِۦ مِن ضُرٍّ ۖ وَءَاتَيْنَٰهُ أَهْلَهُۥ وَمِثْلَهُم مَّعَهُمْ رَحْمَةً مِّنْ عِندِنَا وَذِكْرَىٰ لِلْعَٰبِدِينَ ﴿٨٤﴾

**«[Расүлем!] Әюб галәйһиссәламне дә искә ал! Менә ул, [каты чир белән авырып, еллар буена сабыр иткәннән соң, намазга тора алырлык та көч таба алмагач], Раббысына [дога белән] эндәште: «Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесесең». Без [догасын кабул итеп] аңа җавап бирдек һәм аңа килгән зарарны китәрдек. Хозурыбыздан бер рәхмәт һәм гыйбадәт кылучыларга бер үгет булсын дип, [үлгән балаларын терелтеп, картаеп беткән хатынын яшәртеп] аңа гаиләсен һәм [шулкадәр үк бала, онык биреп] янында булган кадәрен [кабат] биргән идек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83-84

Әюб галәйһиссәламгә Аллаһының әмере килгән:

ٱرْكُضْ بِرِجْلِكَ ۖ هَٰذَا مُغْتَسَلٌۢ بَارِدٌ وَشَرَابٌ ﴿٤٢﴾

**«Аягың белән [җиргә] тип! [Ул әмеребезне үтәгәч, чишмә бәреп чыкты]. Бу салкын су – коеныр һәм эчәр өчен» [дидек]».**

«Сад», 38:42

Әюб галәйһиссәлам Аллаһының әмерен үтәгән. Ул аягы белән типкән һәм җирдән үтә күренә торган су бәреп чыккан. Ул эчәр өчен – салкын, әмма, бер үк вакытта, юыну өчен җылы булган.

Әлеге суны эчеп, ул эчтәге авыруларыннан, аның белән юынып, ул тире авыруларыннан котылган һәм янәдән саулыкка ирешкән. Аңа элекке көче һәм яшьлеге кире кайткан.

Җәбраил галәйһиссәлам аңа чиста һәм кыйммәтле кием кидергән. Аллаһы Тәгалә аңа элекке байлыгын кире кайтарган һәм аны күпләгән балалар белән бүләкләгән (бер риваятьтә Аллаһы аның үлгән балаларын да терелтә, дип килә).

Шулай итеп, барлык бәлаләргә һәм авырлыкларга да карамастан, Әюб галәйһиссәлам Аллаһыга өметен җуймаган, сабыр булган һәм әлеге сынауларны уңышлы үткән, һәм, шуның өчен, аңа байлыгы һәм балалары кайтарылган.

Бер риваятьтә болай дип әйтелгән:

Әюб галәйһиссәлам элекке яшьлек кыяфәтенә кайткач, хатыны Рәхимә бу хакта әле белмәгән. Гадәттәгечә, ул иртән азык-төлек алырга дип шәһәргә чыгып киткән. Күпмедер вакыт узгач, Рәхимә кабаттан әйләнеп кайткан, әмма ирен өйдә очратмаган, һәм күз яшьләре белән болай дип елый башлаган: «Минем авыру ирем белән ни булды? Аны ерткыч җанвар өстерәп алып китте микәнни?» Шул мизгелдә Әюб галәйһиссәлам аннан сораган:

– Ий, хатын, син кемне эзлисең?

– Минем авыру ирем бар иде. Мин аны югалттым.

– Аның исеме ничек?

– Әюб.

– Ә ул нинди кыяфәттә иде?

– Сәламәт булганда ул бик тә сиңа охшаган иде.

– Ий Рәхимә! Әюб мин булам инде ул.

Алар кочаклашканнар һәм Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белдергәннәр. Бергәләп шәһәргә төшкәч, аларның өйләре яңарганын, балалары кабат терелгәнен, байлыклары һәм көтүлекләре кире кайтарылганын күргәннәр.

Ә «Рәхимәгә йөз таяк» турындагы ант белән нишләргә соң? Әюб галәйһиссәлам хатынына яла ягулары хакында аңлаган. Һәм Аллаһы Тәгалә Әюб галәйһиссәламгә кайгыда һәм шатлыкта да тугрылыклы булган тормыш иптәше Рәхимә өчен җәзаны киметә торган юлны күрсәткән. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَخُذْ بِيَدِكَ ضِغْثًا فَٱضْرِب بِّهِۦ وَلَا تَحْنَثْ ۗ إِنَّا وَجَدْنَٰهُ صَابِرًا ۚ نِّعْمَ ٱلْعَبْدُ ۖ إِنَّهُۥٓ أَوَّابٌ ﴿٤٤﴾

**«Кулың белән бер бәйләм ал да шуның белән [хатыныңа] сук һәм антыңны бозма» [дип вәхи иттек]. Һичшиксез, Без аны сабыр итүче буларак [белгән хәлдә] таптык. [Ул] Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде».**

«Сад», 38:44

Ул йөз чыбыкны бер бәйләмгә җыйган һәм җиңелчә генә итеп бер тапкыр әлеге бәйләм белән хатынына кагылып киткән. Шулай итеп үзенең антын үтәгән. Авырлыклар, сынаулар чоры артта калган.

## Елау сәбәбе

Әюб галәйһиссәлам янәдән үзенең мал-мөлкәтен һәм балаларын кире кайтаруга ирешкән төндә, ул таң алдыннан уянган һәм елаган:

– Һәр төнне мин таң алдыннан: «Ий безнең хастабыз! Син ничек?» – дип сораган илаһи тавышны ишеттем. Әмма әлеге тавыш башка ишетелми, шуңа күрә елыйм.

Байлык һәм ярлылык, саулык һәм авыру кебек сынауларга дучар ителгән Әюб галәйһиссәлам барлык авырлыкларны олуг сабырлык белән узган, бар кешелек өчен тайпылышсыз чыдамлык үрнәгенә әверелгән.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَىْءٍ مِّنَ ٱلْخَوْفِ وَٱلْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ ٱلْأَمْوَٰلِ وَٱلْأَنفُسِ وَٱلثَّمَرَٰتِ ۗ وَبَشِّرِ ٱلصَّٰبِرِينَ ﴿١٥٥﴾

**«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

# Нәсыйхәт

# Көнчелек

Һәрберебезнең бурычы – тәкъва булу һәм дә йөрәкләребезне чирләрдән, бозыклыклардан пакь кылу, чөнки йөрәк – кеше тәненең сәйиде, башлыгыдыр. Тән белән ничек теләсә – шулай хакимлек итә, ә тәне исә йөрәккә буйсына. Әгәр йөрәк туры юлда, истикамәттә, изгелектә булса, тәне дә нәкъ шул рәвешле булыр.

Аллаһының расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, тәндә бер ит кисәге бардыр. Әгәр ул яраклы хәлгә килсә, бөтен тән дә яраклы хәлгә килер. Әгәр ул бозылса, бөтен тән дә бозылыр» .

Димәк, иң кадерле, иң дәрәҗәле әгъза – йөрәк. Һәм шуның белән беррәттән иң куркынычы да. Аның белән идарә итү һәм аны яхшыга үзгәртүе җиңел бирелми.

Йөрәге сәбәпле кеше туры юлга килә, Раббысына кире кайта. Әмма йөрәге Аллаһыдан ерак, каты һәм бозык булса, кеше куркыныч астында була һәм күңел афәтләре чирләренә бирелергә мөмкин.

Дөреслектә, йөрәккә иң куркыныч афәтләрнең берсе, йөрәкне бозып, туры юлдан адашуга китерә торган чир – ул көнчелектер! Әйе, көнчелек (хөседлек).

Чынлыкта, көнчелек чире кешене зур авырлыкларга китерә, аның тормыш ямен бетерә, гөнаһлар, бозыклыклар дөньясына китерә. Бу чир нинди генә йөрәккә керсә дә, шул йөрәкне боза. Хәзерге хәлен дә, киләчәген дә авыр хәлгә китерә.

Көнчелек – бик борынгы чир. Көнчелекнең ахыры – Аллаһы Тәгаләгә көферлек, ә башы – яхшылыкны, нигъмәтне теләмәү. Хәтта, галимнәр «көнчелек – Аллаһыга каршы булган беренче гөнаһ», дип әйттеләр. Һәм бу – чыннан да, шулай.

Иблис, Аллаһыга якын булганнардан соң да, җәннәттә яшәгәннән соң да, ләгънәт кылынды һәм җиргә сөрелде. Сәбәбе – көнчелек белән тәкәбберлек түгел идеме? Адәм галәйһиссәламнең улы Кабил туганы Һабилне көнчелеге сәбәпле үтермәдеме?

Пәйгамбәрләр, илчеләр, халыкларына җибәрелгәндә, аларга каршы чыгучылар, имансызлык башлыкларының көнчелекләре сәбәпле пәйгамбәрләргә дошман булмадылармы?

Хәтта намаз укып, уразалар тоткан җирдән мөселманнар арасында кинәт дошманлашып, төрле сүзләр таратып, вөҗдан пычратучыларның сәбәбе көнчелек түгелме?

Аллаһы Раббыбыз изге Китабында болай дип әйтте:

أَمْ يَحْسُدُونَ ٱلنَّاسَ عَلَىٰ مَآ ءَاتَىٰهُمُ ٱللَّهُ مِن فَضْلِهِۦ ۖ فَقَدْ ءَاتَيْنَآ ءَالَ إِبْرَٰهِيمَ ٱلْكِتَٰبَ وَٱلْحِكْمَةَ وَءَاتَيْنَٰهُم مُّلْكًا عَظِيمًا ﴿٥٤﴾

**«Әллә соң алар Аллаһы Үзенең фазылыннан [Расүлуллаһ [салләллаһу галәйһи вә сәлләм] һәм сәхабәләре кебек] кешеләргә биргән [пәйгамбәрлек, Китап һәм өстенлек кебек] нәрсәләрдән көнләшәләрме? Без бит Ибраһим гаиләсенә Китап [Тәүрат, Инҗил һәм Зәбур] вә хикмәт биргән идек, аларга [Йосыф, Давыд һәм Сөләйманга (галәйһимуссәлам) зур хакимлек тә биргән идек».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:54

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне көнчелек чиреннән бик каты кисәтә иде.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелгән хәдистә болай дип әйтелә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Кеше хакында начар уйлаудан сакланыгыз. Начар уйлар – иң ялган сүзләрдер. Бер-берегезне тикшеренеп йөрмәгез, бер-берегезгә җасуслык

кылмагыз (ягъни бер-берегез артыннан шымчылык кылып йөрмәгез). Бер-берегездән көнләшмәгез. Бер-берегезгә нәфрәтле булмагыз. Бер-берегезне борылып ташлап китмәгез. Әй, Аллаһы коллары, бер-берегезгә туганнар булыгыз!»

Шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне начар һәм дә araларны боза торган гамәлләрдән, шул исәптән, көнчелек чиреннән дә тыя иде.

Икенче бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм көнчелек динне дә бетергәнлеген аңлаткан: «Сезгә кадәр яшәгәннәрнең чирләре сезгә әкренләп килеп җитә: ул ике чир көнчелек һәм нәфрәт (бер-береңне күрәлмау). Һәм бу чирләр – кыручылар булып торалар. Ләкин алар чәчне кырмыйлар, ә динне кыралар».

Кешедән көнләшүче үзенең ачуын эчендә тота алмый, ул башкасына начарлык килсен дип тели, аның эче ут кебек янадыр. Шул сәбәпле, ул әкренләп динен дә югалта башлый, гөнаһлары артканнан арта бара. Ахыр чиктә, чәч пеләшкә кырылган кебек, дине дә кырылып бетә. Аллаһы сакласын!

Шулай ук, көнчелек чире бөтен булган әҗерләрне, савапларны, изгелекләрне бетерә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Көнчелектән сакланыгыз. Дөреслектә, утынны ут ашаган кебек, көнчелек тә изгелекләрне ашыйдыр».

Әйе, көнче кеше Кыямәт көнендә зур хәсрәткә очрар, изгелекләрен югалтып бетерер. Галимнәр болай дип әйткәннәр: «Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм тыйган һәм куркыткан чир, көнчелекнең мәгънәсе – башка кешедә Аллаһы биргән нигъмәтнең бетүен теләү». Ягъни, берәү яхшы машина алса «ах, оятсыз, нинди машина алган, бәлагә очрасаң иде иде шул машинаң белән», яки берәр яхшы, изгелекләр кылучы күркәм кешене күрсә «ах, сине, бу бит миннән яхшырак, берәр хәл

булса иде шуның белән», дип теләү.

Әйткәнебезчә, көнчелек – ул Аллаһы биргән нигъмәтне башкада күреп, шул нигъмәтнең юкка чыгуын теләү. Әмма кешедәге әйберне күреп, шул әйбергә яхшы нияттән ымсыну белән беррәттән, шул кешегә начарлык теләмәү көнчелеккә керми. Мәсәлән, кемнеңдер машинасын, йортын, ниндидер сатып алган әйберсен, балаларын күрсә, «эх, минем дә шул әйберләр булса иде» дип теләү, һәм ул кешегә начарлык теләмәү – көнчелек булмый, ә үзара узышу, ымсыну булып санала. Ләкин, ымсыну һәм узышу да бары тик җәннәткә илтә торган гамәлләрдә булырга тиеш. Дөнья әйберләре өчен ымсыну, узышу динебездә ярый торган гамәлләрдән түгел: тыелган гамәлләрдән санала.

Аллаһы Тәгалә «Әл-Мутаффифин» сүрәсендә җәннәт нигъмәтләрен зикер иткәч:

وَفِي ذَٰلِكَ فَلْيَتَنَافَسِ الْمُتَنَافِسُونَ

**«Омтылучылар [гыйбадәтләргә ашыгып] моңа омтылсын»,** – дип әйткән.

«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:26

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәләм болай дип әйткән:

«Ике кешене генә көнләшеп була: беренчесе, әгәр Аллаһы аңа гыйлем-хикмәт биреп, шул хикмәтлелек белән гамәл кылып, башкаларны шуңа өйрәтсә. Ә икенчесе, әгәр Аллаһы Тәгалә берәр кешегә күп байлык биреп, ул кеше байлыгын бары тик хаклык юлында сарыф итсә».

Ягъни, менә шул ике кешедән көнләшү гөнаһ булмас. Ул төр көнләшүне хәтта кайвакытта «ак көнләшү» дип атыйлар.

Әгәр көнләшү чире үтеп керсә, беркемне дә карап тормый: олы яшькә җиткән өлкән кешене дә, зур гыйлем алган галимне, зур дәрәҗәгә ирешкә хөрмәтле кешене дә, наданлыкта булган гади кешене дә. Һәрберсен харап итәргә мөмкин. Аллаһы сакласын! Шуңа күрә көнчелеккә китерә торган

сәбәпләрдән арыныгыз, көнчелеккә илтә торган юллардан сакланыгыз.

## Көнчелектән саклану юллары

Көнләшү – Аллаһыга каршы чыгу дигән сүз. Аллаһы билгеләгән тәкъдиргә, язмышка ризасызлык белдереп, шул язмышка ачу белдерү. Аллаһы Тәгалә кешеләргә бүлеп биргән ризыкны, нигъмәтләрне күрә алмау, нәфрәтле булу. Шул рәвешле көнче кеше Аллаһының гаделлегенә, хикмәтлелегенә каршы чыга.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

أَهُمْ يَقْسِمُونَ رَحْمَتَ رَبِّكَ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُمْ مَعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَرَفَعْنَا بَعْضَهُمْ فَوْقَ بَعْضٍ دَرَجَاتٍ

**«Раббыңның рәхмәтен әллә алар бүләләрме? Дөнья тормышында ризыкларын араларында Без бүлгәләдек һәм берәүләре икенчеләрен хезмәтче итеп алсыннар дип, Без аларның кайберләрен [байлык ягыннан] кайберләреннән дәрәҗәләрдә күтәрдек».**

«Әз-Зухруф / Зиннәтләнү», 43:32

Ризыкны син бүлмисең, ә Аллаһы бүлә. Шуңа күрә көнләшеп янып утыру урынына, Аллаһыга «Раббым, нигъмәтләреңне насыйп ит», дип дога кыл. Боларны белү – көнчелекне бетерә торган сәбәпләрнең берсе.

Көнчелектән саклый торган икенче сәбәпне һәрбер кеше белергә тиештер. Көнче кеше көнләшкәндә көнләшүенең төп корбаны үзе булыр, чөнки көнчелеге сәбәпле аның эчке дөньясы зәгыйфьләнә, тормыш яме югала, ул һәрвакыт төшенкелектә. Әле шуның белән беррәттән дине дә югала, гөнаһлары арта.

Көнчелек беркайчан да үзе генә килми, ул үзенең артыннан әле башка гөнаһларны да ияртеп килә. Кеше көнләшә башласа, көнләшкән кеше-

се хакында гайбәт сөйли, аның хакта яман сүзләр тарата. Башкаларны тикшереп йөри башлый, һәрвакыт артыннан күзәтә, шымчылык кыла, хаталарын, ялгышлыкларын эзли башлый. Кешегә нәсыйхәт кылам дип, аны юри башкалар арасында мыскыллый, тәнкыйтьли башлый. Менә бу гөнаһлар һәммәсе дә көнчелеккә ияреп килгән гөнаһлар. Көнләшкән кеше бу гөнаһлардан имин калмаячак.

Әгәр көнчелек хисләре туа башласа, ул кеше өчен дога кылу, Аллаһыдан шул көнләшкән әйберсе өчен бәрәкәтен сорау кирәк. Әгәр берәр кеше сиңа караганда яхшырак, тәртиплерәк, гыйлемлерәк булып, изгелекләре синекенә караганда күбрәк булса, ул кешегә начарлык кылма, начарлык турында уйлама. Һәм Аллаһы Раббыбыз Үз рәхмәте белән ул чирдән һәммәбезне дә имин кылыр.

Көнчелекне юкка чыгара торган сәбәпләренең тагын берсе – Аллаһы биргәнгә шөкер кылу, канәгать булу. Аллаһы ризыкларына канәгать бул, ризалык белдер. Аллаһы билгеләгән тәкъдиргә, язмышка күңелең тыныч булырга тиеш. Әгәр нәрсә дә булса теләсәк, мохтаҗ булсак, Аллаһыга ялварыйк, дога кылып сорыйк.

Һәм инде соңгы сәбәбе – Аллаһыга тәвәккәлләү, Аллаһыга өметләнү. Кем Аллаһыга тәвәккәлләсә – ярдәмче буларак аңа Аллаһы җитәр.

Аллаһы Раббыбыз безне көнчелек чиреннән сакласын, безне бәла-казалардан имин, шәйтан коткыларыннан ерак кылсын. Әмин.

*Сәлимҗан хәзрәт Домнин,*

*Кабан арты мәчете имамы*

# Кыямәт куркынычлары һәм рисвайлыклары бәяны

Факиһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Хәлил бине Әхмәттән, ул үзенең иснәде белән Гайшә радыяллаһу ганһәдән риваять итә. Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мин, әй Аллаһының Расүле, Кыямәт көнендә дус кеше үзенең дустын зикер итәме, дидем.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Өч урында зикер итмәс: мизан вакытында, җиңел яки авыр булуны белгәнчегә кадәр, гамәл дәфтәрләрен ачкан вакытта, ул дәфтәрләр уң яктан яки сул яктан бирелгәнен белгәнчегә кадәр. Тәмуг утыннан муен чыгып алар хозурына сарылыр, ул муен аларга әйтер: «Өч кешегә җибәрелдем: Аллаһы Тәгалә белән икенче Аллаһыны теләгән кешегә, һәр инкяр итүче тәкәббер кешегә һәм Хисап көненә ышанмаган кешеләрнең барчасына җибәрелдем. Алар хәтта җәһәннәменең тыгызлыгына атканга кадәр сөрелер. Җәһәннәм өчен күпер булучыдыр, кылдан нечкәрәк һәм кылычтан үткенрәк булыр. Кешеләр аның өстеннән ялтыраган яшен яисә искән җил кебек үтәрләр һәм котылган кеше мөселмандыр. Җәрәхәтләнгән, киселгән кеше утка йөзтүбән төшерелер».

Янә факиһ үзенең иснәде белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Расүлебез: «Сурның ике өрүе арасында кырык ел, моннан соң Аллаһы Тәгалә күктән ирләрнең мәние кебек су иңдерер, үлән үскән шикелле үсәрләр», – дигән.

Безгә төрле иснәдләр белән Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән бер ышанычлы кеше үзенең иснәде белән хәбәр бирде. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән, ул Пәйгамбәребездән риваять итә. Расүлебез болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә җирне һәм күкләрне яратудан бушанган заманда сур исемле мөгезне ятатты һәм аны Исрафил галәйһиссәламгә бирде. Ул Исрафил күзе белән Гарешкә караган хәлдә сурны үзенең авы-

зына куяр һәм кайчан әмер кылынуын көтәр. Әбү Һөрайра: «Мин: «Әй Аллаһының Расүле нәрсә ул сур?» – дип сорадым, диде. Расүлуллаһ: «Нурдан булган мөгез», – диде. Мин: «Әй Аллаһының Расүле, ул ничек?» – дип сорадым. Расүлуллаһ: «Әйләнәсе бик зур булучыдыр. Аллаһы белән ант итәмен, мине хаклык белән пәйгамбәр итеп җибәрде, әлбәттә, ул сурның даирәсенең олуглыгы җир һәм күкнең киңлеге кебектер, аңа өч мәртәбә өрелер».

Кайбер риваятьләрдә зикер ителде: «Дөреслектә, ике мәртәбә өрү: беренче мәртәбә – һәлак итү өчен, икенчесе – кубарылу өчендер». Кәгъб риваятендә, ике мәртәбә өрү. Әбү Һөрайра риваятендә өч мәртәбә өрүдер. Беренчесе –куркыту өчен, икенчесе – тавыштан һәлак итү өчен, өченчесе – кубарылу өчендер. Аллаһы Тәгалә Исрафил галәйһиссәламгә беренче мәртәбә өрергә боерыр һәм анда өрер. Җирдә һәм күкләрдә булган кешеләр куркырлар. Моңа Аллаһы Тәгаләнең Сүзе шаһит:

وَيَوْمَ يُنفَخُ فِي الصُّورِ فَفَزِعَ مَن فِي السَّمَاوَاتِ وَمَن فِي الْأَرْضِ إِلَّا مَن شَاءَ اللَّهُ ۚ وَكُلٌّ أَتَوْهُ دَاخِرِينَ﴿٨٧﴾

**«Сурга өрелгән көнне дә [искә ал]. Аллаһы теләгән [кайбер фәрештәләр, шәһитләр һәм Муса [галәйһиссәлам] кебек] кешеләрдән тыш, күкләрдә һәм җирдә булганнар дәһшәткә төшәчәк. [Сурга икенче мәртәбә өрелгәч] Һәркем Аңа түбәнчелекле кешеләр буларак барачак».**

«Ән-Нәмл / Кырмыскалар», 27:87

Балалар карт булып әверелерләр, шәйтаннар качкан хәлдә очарлар. Моңа Аллаһы Тәгаләнең Сүзе шаһит:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمْ ۚ إِنَّ زَلْزَلَةَ السَّاعَةِ شَيْءٌ عَظِيمٌ﴿١﴾

**«Ий кешеләр! Раббыгыздан куркыгыз [да, әмерләрен тотып, тыюларыннан тыелыгыз], чөнки Сәгатьнең зилзиләсе – бик зур нәрсә!»**

«Әл-Хаҗ», 22:1

Җир селкенер. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелгән:

يَوْمَ تَرَوْنَهَا تَذْهَلُ كُلُّ مُرْضِعَةٍ عَمَّا أَرْضَعَتْ وَتَضَعُ كُلُّ ذَاتِ حَمْلٍ حَمْلَهَا وَتَرَى النَّاسَ سُكَارَىٰ وَمَا هُم بِسُكَارَىٰ وَلَٰكِنَّ عَذَابَ اللَّهِ شَدِيدٌ ﴿٢﴾

**«Сезнең аны күрәсе көнне һәрбер имезә торган хатын [куркуыннан] имезгәнен онытыр, һәрбер йөкле хатын [вакытыннан алда] йөген төшерер. [Ий боларны күрүче! Ул көнне] Син кешеләрне исерекләр [кебек] күрерсең, ләкин алар исерек түгелләр. Аллаһының газабы бик каты [булганлыктан, аларның акыллары югалган булыр]».**

«Әл-Хаҗ», 22:2

Аллаһы Тәгалә теләгән кадәр торырлар, моннан соң Аллаһы Тәгалә Исрафилгә боерыр, ул Исрафил һәлак итү өрүен өрер. Күк һәм җир әһелләре һәлак булырлар, ягъни күк һәм җир әһеле үләр, мәгәр Аллаһы Тәгалә теләгән кеше генә кала. Моңа Аллаһы Тәгаләнең Сүзе дәлил:

وَنُفِخَ فِي الصُّورِ فَصَعِقَ مَن فِي السَّمَاوَاتِ وَمَن فِي الْأَرْضِ إِلَّا مَن شَاءَ اللَّهُ

**«Сурга [Исрафил [галәйһиссәлам] тарафыннан] өрелер дә, Аллаһы теләгәннәрдән [Җәбраил, Исрафил, Микаил һәм Газраил беләν Гарешне күтәреп торган фәрештәләр һәм моңа кадәр үлгән кешеләрдән] тыш, күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар [барысы да] үләр».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:68

Искәрмә, ягъни ул кеше белән шәһитләрнең рухларын максат итә. Аллаһы Тәгалә бу искәрмә белән Җәбраил, Микаил, Исрафил, Мәләкүлмәүт, ягъни үлем фәрештәсе (аларның барчасына Аллаһы Тәгаләнең салаваты булса иде) максат итә. Аллаһы Тәгалә үлем фәрештәсенә әйтер: «Минем мәхлүкъларымнан кем калды?» Ләкин Үзе белүчерәктер. Ул үлем фәрештәсе әйтер: «Әй, Аллаһы, Син Терек һәм Үлмәссең. Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Синең Гаршеңне күтәрүчеләр калдылар һәм мин үзем калдым». Аллаһы Тәгалә үлем фәрештәсенә югарыда зикер ителгәннәрнең рухларын алырга боерыр. Кәләби һәм Мөкатилнең риваятьләрендә болай дип зикер ителде. Мөхәммәд бине Кәгъб Әбү Һөрайрә радыяллаһу ганһедән риваять итә. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә: «Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Гарешне күтәрүчеләр үлсен», – дип әйтер. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй үлем фәрештәсе, Минем мәхлүкъларымнан кем калды?» Үлем фәрештәсе әйтер: «Син үлми торган Терексең. Синең зәгыйфь колың үлем фәрештәсе калды». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй үлем фәрештәсе, Минем Сүземне ишетмәдеңме?»

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ

**«Һәрбер җан үлемне татыячак».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Минем мәхлүгымнан булган син дә бер мәхлүкъсың, Мин сине күргән нәрсәң өчен яраттым, инде үл». Ул үлем фәрештәсе үләр.

Икенче хәбәрдә риваять кылынды. Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә ул үлем фәрештәсенә үзенең рухын алу белән боерыр. Ул үлем фәрештәсе җәннәт белән ут арасында булган урынга килер һәм үз-үзенең җанын алыр. Бер тавыш белән кычкырыр, әгәр барча мәхлүкат терек булса, аның тавышыннан үләрләр иде. Дәхи әйтер: «Әгәр җан алу өчен мондый катылык һәм ачылык булганын белгән булса идем, дөреслектә, мөэминнәрнең рухларын алу йөзеннән йомшаграк булыр идем». Һәм мәхлүкатлардан

берсе дә калмас. Аллаһы Тәгалә начар булган дөньяга әйтер: «Кайда падишаһлар, кайда аларның балалары? Кайда җәберләүчеләр һәм кайда җәберләүчеләрнең балалары? Кайда минем малымнан ашый торган бәндәләр, алар Миннән башка гыйбадәт кыла торган булдылар? Соңыннан Аллаһы Тәгалә сорар:

لِّمَنِ الْمُلْكُ الْيَوْمَ

**«Бүген хакимлек кемнеке?»**

«Гафир / Гафу итүче», 40:16

Аңа һичкем җавап бирмәс. Аллаһы Тәгалә Үзе җавап биреп әйтер:

لِلَّهِ الْوَاحِدِ الْقَهَّارِ

**«Бердәнбер һәм Юк итүче булган Аллаһыныкы!»**

«Гафир / Гафу итүче», 40:16

Моннан соң Аллаһы Тәгалә күккә яңгыр яудырырга боерыр, күк ирләр мәние кебек, хәтта һәрнәрсәнең өстендә унике аршын су булганчыга кадәр кырык көн яңгыр яудырыр. Аллаһы Тәгалә бу су белән мәхлүкъларны, яшелчә үләннәрне үстергән кебек, үстерер, хәтта аларның тәннәре камилләнеп җитәр, ничек булса шулай кайтыр.

Моннан соң Аллаһы Тәгалә: «Исрафил һәм Гареш күтәрүчеләр терелсен», – дип әйтер. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән терелерләр. Янә Аллаһы Тәгалә Исрафилгә боерыр, ул сурны алып авызына куяр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә: «Җәбраил һәм Микаил терелсен», – дип әйтер. Аллаһы Тәгаләнең әмере белән тергезерләр, моннан соң Аллаһы Тәгалә җаннарны чакырыр, ул җаннар китерелер һәм Исрафил ул җаннарны сур эчендә кылыр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә Исрафилгә боерыр һәм ун кубарылу өрүен өрер. Җаннар умарта кортлары кебек чыгарлар һәм җир белән күк арасын тутырырлар. Алар җирдә тәннәргә керерләр. Җир

алардан ярылыр, моннан соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Мин аңардан җир ярылган кешенең әүвәлемен». Икенче хәбәрдә: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һәркайчан Җәбраил, Микаил һәм Исрафил галәйһимуссәламне тергезсә, алар Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең каберенә иңәрләр, алар белән бурак һәм җәннәттән киемнәр булыр һәм аңардан җир ярылыр. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбраилгә карап әйтер: «Әй, Җәбраил, бу нинди көн?» Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәр галәйһиссәламгә әйтер: «Бу көн Кыямәт көне, терелү һәм хисапны инкяр итүчеләргә тәхкыйк кылына торган көндер. Бу көн күңелләр кагыла торган көндер». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әй Җәбраил, Аллаһы Тәгалә минем өммәтемә ни кылды?» – дияр. Җәбраил әйтер: «Сине сөендерәмен, чөнки син аннан җир ярылган кешенең әүвәлгесе».

Моннан соң Аллаһы Тәгалә Исрафил галәйһиссәламгә боерыр. Ул сурга өрер, шул вакытта алар торучылар һәм күрүчеләр. Без Әбү Һөрайраның сүзенә кайттык, ул радыяллаһу ганһе әйтте: «Алар җирдән үзләренең Раббылары янына ашыккан хәлдә чыгарлар, ягъни алар каберләреннән яланаяк һәм ялангач тәннәре белән чыгарлар. Моннан соң бер урында җитмеш елга кадәр туктарлар. Аллаһы Тәгалә аларга карамас һәм алар арасында хөкем кылмас, күз яшьләре беткәнчегә кадәр еларлар. Моннан соң кан түгеп еларлар. Аларны елга авызы кебек ясаганга кадәр дәхи иякләргә ирешкәнгә кадәр тирләренә батырлар. Моннан соң мәхшәргә өндәлерләр, моңарга Аллаһы Тәгаләнең Сүзе дәлил:

مُّهْطِعِينَ إِلَى الدَّاعِ

**«Чакыручыга [Исрафилга [галәйһиссәлам] таба ашыга-ашыга [барачаклар]».**

«Әл-Камәр / Ай», 54:8

Әгәр халыклар җеннәр, кешеләр һәм башкалар бөтенесе җыелсалар, алар туктаган вакытта күктән каты тавышны ишетерләр. Бу эш аларны гаҗиз кылыр һәм күк ярылыр дөнья күгенең фәрештәләре җирдә булган кешеләр кебек иңәрләр, үзләренең саф урыннарын алырлар. Аларга кешеләр әйтерләр: «Безнең Раббыбыз сездәме, ягъни сездә Раббыбызның хисап белән әмере бармы?» Фәрештәләр әйтерләр: «Юк, ул килер, ягъни Аллаһы Тәгаләнең әмере хисап белән килер». Моннан соң икенче күкнең әһеле иңәр. Алар дөнья күге әһеленең артында сафта торырлар. Моннан соң өченче күкнең әһеле төшәрләр, хәтта җиде күк фәрештәләре бер-берсеннән ике өлеш микъдарда булып төшәрләр һәм дөнья әһеле тирәсендә торырлар.

Факиһ радыяллаһу ганһе әйтте: «Мөхәммәд бине Фадел үзенең иснәде белән Даххәктән риваять итә. Ул әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә дөнья күгенә боерыр Һәм күктә фәрештәләрдән булган нәрсәне ярыр, алар төшәрләр һәм җирне янә җирдә булган кешеләрне чорнап алырлар. Моннан соң икенчесе анда булган мәхлүкълар. Өченчесе янә анда булган мәхлүкълар. Моннан соң дүртенчесе һәм аңарда булган мәхлүкълар. Моннан соң бишенчесе һәм андагы мәхлүкълар. Моннан соң алтынчысы һәм андагы мәхлүкълар. Моннан соң җиденчесе һәм андагы мәхлүкълар. Хәтта фәрештәләрдә җиде кат булганчыга кадәр. Ул фәрештәләрнең кайберләре кайберләренең эчендә. Җир әһелләре ул сафларның берсенә дә килмәсләр, ягъни ирешмәсләр, мәгәр аның каршында фәрештәләрдән торган җиде саф табарлар. Моңа Аллаһы Тәгаләнең Сүзе дәлилдер:

قَالَ لَمْ أَكُن لِّأَسْجُدَ لِبَشَرٍ خَلَقْتَهُ مِن صَلْصَالٍ مِّنْ حَمَإٍ مَّسْنُونٍ ﴿٣٣﴾

**«[Мәхшәрдә әйтеләчәк] Ий җеннәр һәм кешеләр җәмәгате! Күкләрнең һәм җирнең чикләреннән үтәргә көчегез җитсә, үтегез. Ләкин бер көч булмыйча, үтә алмассыз».**

«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:33

Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَيَوْمَ تَشَقَّقُ السَّمَاءُ بِالْغَمَامِ وَنُزِّلَ الْمَلَائِكَةُ تَنزِيلًا ﴿٢٥﴾

**«[Беренче кат] Күкнең [ап-ак] болыт белән ярылачак һәм [анда булган] фәрештәләрнең [мәхшәр җиренә] иңдереләчәк көнне [хакимлекнең Аллаһыныкы икәне аңлашылачак]».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:25

Әбү Һөрайра Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итте. Расүлебез болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй, кешеләр, һәм җеннәр, дөреслектә, Мин сезне үгетләдем, сезнең гамәлләрегез кәгазьләрегездә, ягъни дәфтәрләрегездә. Берәү изгене тапса, Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтсен. Берәү бу хәердән башканы, әлбәттә, шелтәләмәсен, мәгәр үзен генә шелтәләсен». Моннан соң Аллаһы Тәгалә җәһәннәмгә боерыр, ул җәһәннәмнән озын, күтәренке, караңгы муен сөйләшкән хәлдә чыгар. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Йә, сезгә шәйтанга гыйбадәт кылмауны әмер итмәдемме? Дөреслектә, ул шәйтан сезгә ачык дошмандыр. Миңа гыйбадәт кылу – ул туры юлдыр. Дөреслектә, ул шәйтан сездә булган күп җәмәгатьне аздырды. Йә уйламадыгызмы? Бу урын җәһәннәмдер, сез аңа кайтарылдыгыз. Бу көндә көферлек кыла торган нәрсәгез сәбәпле ул җәһәннәмгә керегез». Моңа Аллаһы Тәгаләнең Сүзе дәлилдер. «Һәр өммәтне курыккан хәлдә күрерсең, һәр таифә үзләренең дәфтәрләренә өндәлер. Аллаһы Тәгалә халык, кошлар, дүрт аяклы хайваннар арасында хөкем кылыр. Хәтта, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сөзә торган куй өчен мөгез иясеннән үч алыр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтер: «Туфрак булыгыз». Моннан соң Аллаһы Тәгалә коллар арасында хөкем итәр». Нәфигъ бине Гомәрдән, ул Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Расүлуллаһ болай дип әйтте: «Кыямәт көнендә кешеләр аналары тудырган кебек ялангач һәм яланаяк кубарылырлар». Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйтте: «Ирләр һәм хатыннармы?»

Расүлебез: «Әйе», – диде. Гайшә радыяллаһу ганһә әйтте: «Ни яманлык, бер-берсенә карарлар». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Гайшәнең җилкәсенә кагылды һәм болай дип әйтте: «Әй, Әбү Кахәфә улының кызы, бу көндә кешеләр караудан мәшгуль булырлар, туктаган хәлдә кырык ел күзләрен күккә акайтырлар, ашамаслар һәм эчмәсләр. Алар җөмләсеннән тир аягына ирешкән кешеләр булыр. Алар җөмләсеннән ул тир ике балтырына ирешкән кеше булыр. Алар җөмләсеннән тире корсагына ирешкән кеше булыр. Алар җөмләсеннән көтеп торуның озаклыгыннан тире авызына җиткән кеше булыр. Моннан соң фәрештәләр Гареш тирәсен чолгаган хәлдә торырлар. Аллаһы Тәгалә кычкыручыга боерыр һәм ул кычкыручы «Фәлән улы Фәлән кайда?» – дип кычкырыр. Кешеләр күтәрелерләр, ягъни кешеләр башларын бу тавышка күтәрерләр, исеме аталыш кеше бу туктаган җирдән чыгар. Шул вакытта барча галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһының алдында торыр. Әйтелер: «Золым ияләре кайда?» Ирләр берәм-берәм чакырылырлар, ул кешенең изгелекләреннән алыныр һәм җәбер кылынган кешесенә бирелер. Бу көндә алтын тәңкә дә, көмеш тәңкә дә булмас, мәгәр изгелекләрдән алыныр авызлыкларыннан кайтарылыр. Ул кешенең изгелекләреннән бирүдә даими булырлар, хәтта аның өчен бер изгелек тә калмас. Аларның авызлыкларыннан алыныр, ул золым кылучыга кайтарып бирелер. Әгәр изгелекләреннән бушанса, ул кешегә әйтелер: «Һәуийәһ исемле анаңа, ягъни җәһәннәмгә кайт, чөнки бу көндә һич җәбер юк». Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә хисапны тиз кылучы, ягъни җәзаны ашыктыручыдыр. Бу көндә якын фәрештә, җибәрелгән пәйгамбәр һәм шәһит кеше калмас, мәгәр калса, хисапның катылыгын күреп котыла алмам, дип уйлар. Мәгәр Аллаһы Тәгалә саклаган кеше генә котылыр.

Мөгаз бине Җәбәл радыяллаһу ганһедән ул Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәр расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Колның ике аягы дүрт

нәрсәдән соралганчыга кадәр даими булыр. Гомерен нәрсә өчен фани кылды, ягъни үткәрде. Тәнен нәрсә черетте. Ул кешенең гыйлеменнән, ул гыйлем белән нинди гамәл кылды. Ул кешенең малыннан, ул малын кайдан тапты һәм нәрсә өчен аны таратты».

Гакрәмә радыяллаһу ганһедән риваять итеlә. Ул әйтте: «Дөреслектә, Кыямәт көнендә ата баласына ябышыр һәм әйтер: «Дөреслектә, мин сине дөньяда тудырдым, сиңа ата булдым». Ул бала сәнә белән хәер әйтер. Ата балага әйтер: «Синең изгелекләреңнән бер мыскал чаклыга мохтаҗ булдым, шаять мин күргән нәрсәдән котылырмын». Аның баласы атасына әйтер: «Мин дә синең кебек үзем өчен куркам һәм минем сиңа бер нәрсәне бирергә көчем җитмидер». Моннан соң хатынына ябышыр һәм хатынына әйтер: «Әй фәлән хатын-кыз, дөреслектә, дөньяда мин сиңа ир булдым». Ул хатын аның бу сүзенә изгелек белән сәнә кылыр. Ул хатынга әйтер: «Дөреслектә, мин синнән бер изгелекне телимен. Син миңа ул изгелекне бүләк итәрсең, шаять, мин син күргән нәрсәдән котылырмын». Ул хатын әйтер: «Моңарга көчем җитмидер. Мин ул нәрсәдән син курыккан кебек, үзем өчен куркам». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Ул нәфес гөнаһларны йөкләр өчен авыр гөнаһны калдырса, шул гөнаһлардан һичбер әйбер йөкләнмәс. Әгәр, чынлап та, ул якыннарыннан булса да, ягъни аны гөнаһлар авыр кылган нәрсәне һичберәү үзенең гөнаһларыннан күтәрмәс».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Расүлебез болай дип әйткән: «Дөреслектә, кяфер үзенең тиренә батар, ягъни бу көн озынлыгыннан тир авызына җитәр. Ул кяфер әйтер: «Ий Раббым! Гәрчә утка булса да, миңа рәхмәт ит».

Әбү Җәгъфәр үзенең иснәде белән Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять итә. Дөреслектә, Расүлебез болай дип әйтте: «Һич Пәйгамбәр булмады, мәгәр булды исә, ул Пәйгамбәр өчен кабул була торган дога булды. Ул Пәйгамбәр догасын дөньяда ашыктырды. Дөреслектә, мин догамны Кыямәт көнендә үземнең өммәтемә шәфәгать өчен сакла-

дым. Аң бул, мин адәм балаларының хуҗасымын. Бу мактану булмас, бәлки үземдә булган нәрсәне бәян итү. Аннан җир ярылган кемсәнең әүвәле мин булырмын, мактану түгелдер. Кыямәт көнендә хәмед әләме минем кулымдадыр. Ул әләм астында Адәм галәйһиссәлам һәм аңардан башка кешеләрдер, бу мактану түгелдер». Моннан соң Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кыямәт көнендә ул Кыямәтнең кайгысы һәм хәсрәте кешеләрдә катыланыр. Ул кешеләр Адәм галәйһиссәламгә килеп әйтерләр: «Әй кешеләрнең атасы, Раббыңа безнең өчен шәфәгать кыл, безне хөкем кылуын сора. Адәм галәйһиссәлам әйтер: «Бу эш хакында минем эшем юк. Дөреслектә, мин үземнең гөнаһым сәбәпле җәннәттән чыгарылдым, бу көндә мине һичнәрсә кайгыртмас, мәгәр үзем генә. Ләкин сезгә Нух галәйһиссәламгә бару лязем булсын, чөнки ул пәйгамбәрләрнең иң беренчеседер». Нух галәйһиссәламгә килеп әйтерләр: «Безнең арабызда хөкем кылсын өчен Раббың каршында безгә шәфәгать кыл». Нух галәйһиссәлам әйтер: «Монда минем эшем юк. Дөреслектә, мин җир әһеленә суга батыру догасын кылдым. Дөреслектә, мине бу көндә берни кайгыртмый, мәгәр үзем өчен генә кайгырамын. Шулай да сез Ибраһим галәйһиссәламгә барыгыз, Аллаһы Тәгалә аны хәлил, ягъни дус кылды». Алар Ибраһим галәйһиссәламгә барып әйттеләр: «Раббың каршында безне шәфәгать кыл, безнең арабызда хөкем кылсын өчен. Ибраһим галәйһиссәлам әйтер: «Монда минем эшем юк. Дөреслектә, мин Исламда өч ялганны ялганладым». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Ул өч нәрсә белән Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең диненнән мөҗәдәлә (бәхәс) кылды. Ул өчнең берсе, йолдызларга бер карау белән карады һәм әйтте: «Дөреслектә, мин авырыймын. Икенчесе, бәлки аны олуглары кылды, диде. Өченчесе, Ибраһим галәйһиссәламнең хатынына әйткән сүзедер: «Дөреслектә, ул хатын минем кыз туганым». Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Бүгенге көндә мин үзем турында кайгырам, мәгәр сез Муса галәйһиссәламгә барыгыз, чөнки Аллаһы Тәгалә

аның белән сөйләште». Муса галәйһиссәламгә килеп әйтерләр: «Безнең арабызда хөкем кылсын өчен Раббың каршында безгә шәфәгать кыл». Муса галәйһиссәлам әйтер: «Монда минем эшем юк, дөреслектә, мин хаксыз кеше үтердем. Дөреслектә, мине бу көндә берни кайгыртмый, мәгәр үзем турында кайгырам. Шулай да сез Гайсә галәйһиссәламгә барыгыз». Алар Гайсә галәйһиссәламгә янына килеп әйтерләр: «Безнең арада хөкем кылсын өчен Раббың каршында безгә шәфәгать кыл». Гайсә галәйһиссәлам әйтер: «Монда минем эшем юк. Дөреслектә, мин һәм анам азгын кешеләргә Аллаһы Тәгаләдән башка ике Аллаһы, дип танылдым. Дөреслектә, мине бу көндә берни кайгыртмый, мәгәр үзем генә. Шулай да беләсезме, әгәр берегезнең малы булып, ул малны янчыкка куйса һәм мөһер басылса, янчыкта булган нәрсәгә мөһере бозылганга кадәр ирешерме?» «Юк», – дип әйтерләр. Гайсә галәйһиссәлам әйтер: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бу көндә ышаныч кылды. Аның әүвәл һәм соңыннан булган гөнаһысын Аллаһы Тәгалә ярлыкады, Аңа барыгыз». Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәллам әйтте: «Кешеләр миңа килерләр һәм мин әйтермен: «Әйе, аларга ирешермен, аларга Аллаһы Тәгалә теләгән һәм разый булган кешегә Аллаһы Тәгалә рөхсәт биргәнчегә кадәр ирешермен. Аллаһы Тәгалә теләгән кеше торыр, һәркайчан Аллаһы Тәгалә халкы арасында хөкем кылуны теләсә, бер кычкыручы: «Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәллам һәм аның өммәте кайда?» – дип кычкырыр. Без иң соңгы һәм иң беренче кешеләрбез, ягъни дөньяда кешеләрнең ахыры, Кыямәт көнендә хисап кылганда кешеләрнең иң беренчеләреннән булырбыз. Мин торырмын һәм минем өммәтем торыр һәм башка өммәтләр безнең өчен юлларын ачарлар. Без тәһарәт әсәрләреннән йөзләребез якты булган хәлдә үтәрбез. Кешеләр безгә әйтерләр: «Бу өммәтнең барчасы да пәйгамбәр булырга якын булдылар». Моннан соң җәннәт ишегенә барырмын һәм аны ачуларын теләрмен. «Бу кем?» — дип әйтелер. Мин әйтермен: «Мин Аллаһының расүле Мөхәммәд». Миңа ачылыр, керер-

мен һәм Аллаһыга сәҗдә кылган хәлдә егылырмын, Аллаһыга шундый хәмедләрне әйтермен, ул хәмедләр белән миннән элек һәм миннән соң да Аллаһы Тәгалә һичкем хәмед әйтмәс. Миңа әйтелер: «Башыңны күтәр һәм әйт, ишетелер. Сора, бирелер. Шәфәгать телә, шәфәгать кылынырсың». Башымны күтәрермен һәм калебендә иманнан тузан чаклы яки арпадан бер мыскал, ягъни ышанудан шәһадәт белән булган кешегә шәфәгать кылырмын».

Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, ул мәчеткә керде һәм анда Кәгъб Әл-Әхбәр кешеләргә хәдис сөйли иде. Гомәр радыяллаһу ганһе Кәгъб радыяллаһу ганһегә әйтте: «Әй Кәгъб, безне куркыт». Кәгъб радыяллаһу ганһе әйтте: «Аллаһы белән ант итәм, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең Ул аларны халык кылганнан бирле басып торучы фәрештәләре бар. Үзләренең аркаларын да бөкмәделәр, ягъни озын кыямда (басып тору) торалар. Икенче төрле фәрештәләр бар, сәҗдә кылалар, хәтта сурга өргәнчегә кадәр башларын күтәрмиләр. Алар бергә әйтерләр: «Әй Аллаһы, Сине пакьләү белән пакьлибез. Без Синең хәмедең белән гыйбадәтне җиренә җиткереп, Синең мәгъбүд булуыңа муафыйк гыйбадәт кылмадык. Үзем аның кулында булган Зат белән ант итеп әйтәм, дөреслектә, Кыямәт көнендә җәһәннәм якынлашыр. Ул җәһәннәм өчен сызгыру һәм ачы аваз булыр. Хәтта һәркайчан якынлашса, шундый сызгыру белән сызгырыр, һичбер пәйгамбәр һәм һичбер шәһит калмас, мәгәр үзенең тезенә чүгәр. Һәр пәйгамбәр, сиддыйк һәм шәһит әйтер: «Әй Аллаһым, Синнән үземне сорамыйм. Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйль һәм Исхак галәйһиссәламне онытыр һәм әйтер: «Әй, Раббым, мин Синең хәлилең Ибраһим. Әй, Ибне Хаттаб, әгәр синең өчен бу көндә җитмеш пәйгамбәрнең гамәле булса, әлбәттә, дөреслектә, котылмассың дип уйлар идем. Кавем елады, кайгырдылар. Гомәр радыяллаһу ганһе моны күргәч әйтте: «Безне сөендер». Кәгъб әйтте: «Сөенегез, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең өч йөз унөч юлы бар. Кыямәт көнендә ул юлларның берсеннән

ихлас кәлимәсе белән кол килмәс, мәгәр килде исә, Аллаһы Тәгалә ул кешене җәннәткә кертер. Аллаһы белән ант итеп әйтәм, әгәр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенең хакыйкатен белсәгез, гамәлдә акрынлык кылыр идегез. Әй, кардәш, мондый көн өчен изге гамәлләр һәм гөнаһлардан саклану белән хәзерлән, чөнки син тиздән Кыямәт көнен күрерсең, синнән гомереңнең көннәреңнән үткән нәрсәгә үкенерсең. Бел, дөреслектә, син үлсәң, тәхкыйк синең Кыямәтең торды».

Могыйра бине Шәгъбә әйткәнчә: «Дөреслектә, сез Кыямәтне «Кыямәт» дип әйтәсез. Сезнең берәвегезнең Кыямәте булмас, мәгәр аның үлүе». Галкамә бине Кайстан зикер ителде. Дөреслектә, ул бер кешенең җеназасында булды, күмгәндә кабер янында торды. Галкамә әйтте: «Бу колның Кыямәте килде». Ул Галкамә моны ни өчен әйтте, чөнки кеше һәр кайчан үлсә, тәхкыйк, ул кеше Кыямәт көненең эшен күрде, чөнки ул кеше җәннәтне, утны һәм фәрештәләрне күрә, аның изге гамәлләрдән бер гамәл дә кылырга көче җитми. Берәүнең урыны Кыямәт көненә хәзер булса, үлем сәбәпле аның гамәле мөһерләнде һәм ул кеше Кыямәт көнендә ни-нәрсә белән үлгән булса, шул нәрсә хозурына торыр. Ни сөенеч шул кешегә, аның ахыры изгелек белән булды».

Әбү Бәкер Вәсытый әйтте: «Дәүләт өчәүдер: тереклек дәүләте, үлгән вакытта дәүләт һәм Кыямәт көнендә дәүләт. Әмма тереклек дәүләте – Аллаһы Тәгаләнең тәгатендә тереклек итү. Әмма ул кешенең үлем хәлендә дәүләте – ул кешенең җаны шәһадәт кәлимәсе белән чыгу. Әмма чын дәүләт – ул Кыямәт көненең сөенеч дәүләтедер. Кабердән чыккан вакытта аңарга җәннәт белән сөендерүче килер».

Йәхъя бине Мәгаз радыяллаһу ганһедән зикер ителә. Дөреслектә, аның мәҗлесендә бу аять укылды:

يَوْمَ نَحْشُرُ الْمُتَّقِينَ إِلَى الرَّحْمَٰنِ وَفْدًا﴿٨٥﴾

**«Безнең тәкъвалык ияләрен [изге гамәлләренә, чалган корбаннарына җавап итеп, алтын иярле дөяләренә атланган хәлдә] җәмәгать буларак Рахманга җыячак көнне [һич онытма]»;**

«Мәрьям», 19:85

وَنَسُوقُ الْمُجْرِمِينَ إِلَىٰ جَهَنَّمَ وِرْدًا ﴿٨٦﴾

**«[Иң зур, инкяр итү гөнаһын кылган] Гөнаһлыларны исә [куып барылган хайваннар кебек] сусаган хәлдә җәһәннәмгә куачакбыз».**

«Мәрьям», 19:86

«Һәм гөнаһ кылучыларны сусаган хәлдә җәһәннәмгә сөрербез». Яхъя бине Мөгаз әйтте: «Әй кешеләр, вакыт биргегез, иртәгә туктый торган җиргә кубарылу белән кубарылырсыз, һәр тарафтан төркем-төркем булып килерсез һәм Аллаһы Тәгалә каршында берәм-берәм туктарсыз. Кылган нәрсәләрегездән бер-бер соралырсыз. Әүлиялар Аллаһыга сөрелерләр, ягъни Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә атланган хәлдә килерләр. Гөнаһлы бәндәләр Аллаһы Тәгаләнең газабына җәяүләп килерләр, җәһәннәмгә бүленеп керерләр».

كَلَّا إِذَا دُكَّتِ الْأَرْضُ دَكًّا دَكًّا ﴿٢١﴾ وَجَاءَ رَبُّكَ وَالْمَلَكُ صَفًّا صَفًّا ﴿٢٢﴾

**«Юк! [Бу гамәлләрегез бер дә яхшы түгел!] Җир тузанга әйләнгәч [һәм өстендә калкып торган берни дә калмагач]. Раббың ирадәсе һәм [һәр кат күктәге] фәрештәләр саф-саф [тезелгән] хәлдә [мәхшәргә] килгәч».**

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:21-22

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан*